ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФӘННӘР АКАДЕМИЯСЕ
Г. ИБРАҺИМОВ исем.
ТЕЛ, ӘДӘБИЯТ ҺӘМ СӘНГАТЬ ИНСТИТУТЫ

**И.И. Сабитова**
**Э.И. Сафина**
**Ф.И. Таһирова**

# ТАТАР ТЕЛЕНЕҢ КЫЕНЛЫКЛАР СҮЗЛЕГЕ

Якынча 1400 сүз

КАЗАН • 2019

**УДК 81′374.823**
**ББК 81.2Тат-4**
**С 12**

*Татарстан Республикасы Фәннәр академиясе*
*Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының*
*Гыйльми советы карарына нигезләнеп басыла*

«2014 – 2020 елларда Татарстан Республикасы дәүләт телләрен һәм Татарстан Республикасындагы башка телләрне саклау, өйрәнү һәм үстерү» дәүләт программасы кысаларында нәшер ителә

**Фәнни редактор**
филология фәннәре кандидаты **Ф.И. Таһирова**

**Рецензентлар:**
филология фәннәре докторы **А.Г. Шәйхулов,**
филология фәннәре докторы **Ә.Ш. Юсупова**

**Сабитова И.И., Сафина Э.И., Таһирова Ф.И.**
С 12 **Татар теленең кыенлыклар сүзлеге**. – Казан: ТӘһСИ, 2019. – 184 б.
ISBN 978-5-93091-293-7

Сүзлек, белешмәлек һәм гамәли кулланма буларак, мәктәп укучылары, татар филологиясен өйрәнүче студентлар, татар теле укытучыларына тәкъдим ителә. Ул шулай ук тел галимнәре, журналистлар һәм язучылар өчен дә файдалы булыр, гомумән, татар телен өйрәнүче һәм татарча сөйләшүче киң катлам укучының кызыксынуын уятыр дип көтелә. Сүзлек нигезе итеп матур әдәбият, газета-журнал, Интернет челтәре кебек төрле чыганаклардан тупланган ялгыш очраклар алынды, мисаллар системалаштырылды, кыенлык тудырган очракларның асылы, төрләре, сәбәпләре, дөрес вариантлары китерелде. Сүзлектә якынча 1400 баш сүз теркәлде.

УДК 81′374.823
ББК 81.2Тат-4

**ISBN 978-5-93091-293-7**

© Сабитова И.И., 2019
© Сафина Э.И., 2019
© Таһирова Ф.И., 2019
© Г. Ибраһимов исем. Тел, әдәбият һәм сәнгать институты, 2019

## КЕРЕШ СҮЗ

Туган телебезнең сафлыгы һәм дөреслеге, югары сөйләм культурасына ирешү турында кайгырту – лингвист галимнәрнең, тел һәм әдәбият укытучыларының турыдан-туры бурычы. Бу аларга белгеч буларак та, үз милләтенең вәкиле буларак та зур җаваплылык өсти. Иҗтимагый тормышта кискен борылышлар, үзгәртеп корулар, зур социаль һәм тарихи вакыйгалар күзәтелгән чорларда әлеге җаваплылык бермә-бер арта, чөнки җәмгыятьтәге үзгәрешләр телдә чагылмый калмый. Мондый чорлар, бер яктан, телнең гомуми үсешенә, алга китешенә этәргеч булып торса, икенче яктан, көндәлек аралашу телендә, сөйләмдә тискәре процесслар һәм күренешләр барлыкка китерә. Бүгенге көндә әдәби тел нормалары төрле яклап басым кичерә. Бер яктан, аңа стихияле сөйләм теле тәэсирендә язма телдә табу саналган тупас сүзләр, жаргоннар, түбән стиль берәмлекләре бәреп керә, стильләр арасындагы чикләр юыла. Икенче яктан, рус һәм башка телләр (күбесенчә инглиз) сүзләренең узус хәленә килеп өлгермичә, үзләштерелмәгән килеш чамасыз еш кулланылуы телне чуарлый, аның балансын боза торган факторларның берсенә әверелә. Башлыча финанс, сәүдә, шоу-бизнес, спорт, сәясәт өлкәләренә караган мондый сүзләрнең урынлы-урынсыз кулланылуы массакүләм мәгълүмат чараларында һәм реклама текстларында аеруча еш күзәтелә, хәтта матур әдәбият теленә дә үтеп керә.

Телдәге мондый тискәре процесслар белгечләр тарафыннан анализланырга һәм, тиешенчә бәяләнеп, аерым проблемаларны чишү юллары күрсәтелергә тиеш. Бу мәсьәләне хәл итүдә махсус сүзлекләрнең дә әһәмияте зур. Мәсәлән, рус телендә кыен очракларны төрле яктан чагылдырган сүзлекләр төзүнең тулы бер тармагы бар. Баш хәрефтән яки юл хәрефеннән, кушып яки аерым язу, төрләндерү яки төрләндермәү һ.б. кыен очракларны чагылдырган махсус сүзлекләр төзелгән. Татар тел белемендә бүгенге көнгә кадәр мондый сүзлекләр юк иде әле. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм сәнгать институтының

лексикография бүлеге хезмәткәрләре әзерләгән әлеге сүзлек – бу өлкәдә беренче тәҗрибә.

Сүзлек өчен материал газета-журналлардан, реклама текстларыннан, радио һәм телевидениедән, Интернет челтәреннән, шулай ук матур әдәбияттан, фәнни хезмәтләрдән һ.б. чыганаклардан тупланды.

Сүзлектә нинди берәмлекләрнең урын алуына, аның нинди принципларга нигезләнеп эшләнүенә килгәндә, беренче чиратта, кыенлык тудырган очракларны билгеләү, ялгышны дөрес варианттан аеру буенча зур аналитик эш башкарылуын ассызыкларга кирәк. Чөнки кайвакыт хата шулкадәр еш кабатлана ки, гади сөйләүчегә хәтта дөрес вариант ялгыш булып тоела башлый. Шуңа күрә һәр очракта хата вариантлар индивидуаль якын килеп анализланды. Соңрак, бер үк принципны бозган очракларның ешлыгыннан чыгып, бер төр хаталар төркемләп, чагыштырып тикшерелде.

Һәр ялгышның статусы хата нидән гыйбарәт, бу төр ялгыш ни өчен барлыкка килгән, татар теле кагыйдәләре нигезендә дөресе ничек булырга тиеш, галимнәр бу мәсьәләгә карата нинди фикердә тора кебек сораулардан чыгып билгеләнде. Ялгыш кулланылыш орфографиягә караган очракта, сүзнең вариантлары диалектларда, сөйләмдә таралу-таралмавы, татар теленең фонетик системасына яраклашу-яраклашмавы, объектив тел күренешләре аркасында барлыкка килүе, яисә белем җитмәү сәбәпле ясалуы, яки автор тарафыннан махсус «дөрес» итеп язылуы тикшерелде. Бу очракта, орфография принципларына, телнең вокализм һәм консонантизм системасындагы үзгәреш, көчеш, чиратлашу кебек күренешләренә туры килү-килмәве кебек мөһим мәсьәләләр күздә тотылып, һәр хата вариантка аерым бәя бирелде. Әлеге аналитик эшнең бер өлеше сүзлектә аерым мәкаләләр эчендә бирелгән җыйнак кына аңлатмалар рәвешендә урын алды. Теоретик фикерләрне дәлилләү өчен иллюстратив материал китерелде. Еш кына мисалларда сүзлекнең шушы мәкаләсендә сүз барган хата гына түгел, башкалар да, ягъни бер үк җөмләдә берьюлы берничә кагыйдә бозылган очраклар да урын алырга мөмкин. Ул хаталар күбесенчә чыганактагыча калдырылды. Беренчедән, аларны төзәтү максаты куелмады, һәм кайбер иң тупас хаталарны төзәткән очракта да, җөмләне барыбер норма кысаларына кертеп булмас иде. Икенчедән, сүзлекнең максаты – игътибарны тел нормаларын бозуга юнәлтү.

Югыйсә барлык сүзлекләрдә, дәреслекләрдә, фәнни хезмәтләрдә дөрес үрнәкләр бирелә, дөрес язу һәм сөйләү кагыйдәләре, стандартлары өйрәтелә, аларны һәркем теге яки бу дәрәҗәдә белергә тиеш. Әмма нормалар бозылу проблемасы да яшәп килә. Тәкъдим ителә торган сүзлекнең үзенчәлеге нәкъ менә шушы мәсьәләне хәл итәргә омтылудан гыйбарәт.

Кыенлык тудырган очраклар телнең төрле тармагына карый. Иң еш очрый торган хата – татар теленә хас булмаган ысул белән яки калып буенча сүз ясау. Бу күренеш, нигездә, чит телләр тәэсирендә туа. Язылышта чит тел орфографиясенә ияреп язу  шулай ук типик хаталарның берсе. Кушма сүзләр һәм охшаш конструкцияләрне кушып, аерым яки сызыкча аша язуга бәйле хаталар да күпчелекне тәшкил итә. Сүзләрне тиешле мәгънәдә, тиешле контекстта һәм стильгә туры китереп кулланмау кебек проблемалар телнең сүз байлыгын җитәрлек дәрәҗәдә белмәү, синоним, омоним, паронимнарның аермасын аңламау, гомумән телнең лексикасын саксыз куллану татар теленең киң мөмкинлекләрен тарайту, чикләү генә түгел, аның чын йөзен бозып күрсәтү дип бәяләнә ала. Адлер Тимергалинның «Кирәксә, кирәкмәсә дә текстка гарәп, фарсы һәм төрек алынмаларын яки очраклы сүзләрне тутыру бу әле татарча булды дигән сүз дә түгел, фәннилек тә түгел, фәкать белдекле булып күренергә тырышу, модага иярү генә» дигән фикере дә әлеге проблемаларның берсен тулысынча ачып бирә. Рус яки башка алынма сүзләрнең язылышына «ялган татарчалык» төсмере бирергә тырышуны, «артык» кушымчаларны теләгәнчә кыскартып, «җитмәгән» кушымчаларны теләгәнчә өстәүне тагын бер шундый ук дәрәҗәдә ямьсез һәм кирәксез күренеш дип карарга кирәк. Без беренче чиратта телнең хәбәрләшү функциясен үтәгән билгеләр системасы, һәр сүзнең исә җәмгыятьтә һәркем танырлык билге – символ булуын истә тотарга тиешбез. Ә һәркем сүзне үзенчә үзгәртеп язса, гомумкабул ителгәнчә сөйләшмәсә, җәмгыятьтә үзенең төп функциясен үтәрлек дәрәҗәдәге гомум уртак тел булмаячак, ул кирегә – үзенең формалашып җитмәгән борынгы чорына атлаячак.

Гади укучы әдәби тел нормалары инде искергән, яңа сүзләр, яңа мәгънәләр куллану, яңача язу, сөйләшү зарур, иске нормалар яраксыз дип әйтергә мөмкин. Әйе, әдәби тел үзгәреп тора, аның нормалары да вакыт үтү белән үзгәрә. Әмма, объектив сәбәпләр булмый торып, тел нормаларын махсус, коры теләк нигезендә

үзгәртү зыян гына китерә. Һәр кагыйдәне бинаның аерым бер кирпече итеп күз алдына китерсәк, норма бозуның һәр очрагы бер кирпечне урыныннан кубарып алып атуга тиң дияргә мөмкин. Шулай икән, бу бина эшкә яраклы, ышанычлы һәм тотрыклы була аламы? Әлбәттә, юк. Димәк, әдәби тел нормаларының үтәлеше – шартлы, буш таләп кенә түгел, ә телнең тотрыклылыгын тәэмин иткән ныклы нигез ул. Гомумән, укымышлы, грамоталы һәр кеше үз теленең саф, сөйләменең дөрес булуын тели. Тәкъдим ителә торган сүзлек кебек кулланмалар исә бу юнәлештә һәрберебез өчен ярдәмлек булып хезмәт итә ала.

Хәзерге татар телендә күзәтелгән кыенлыклар, әлбәттә, сүзлектә чагылдырылган очраклар белән чикләнми, биредә аларның берничә төркеме генә теркәлде һәм аңлатылды. Мондый эш системалы нигездә һәм даими алып барылырга, дәвам ителергә тиеш дип уйлыйбыз.

## СҮЗЛЕКНЕҢ ТӨЗЕЛЕШЕ ТУРЫНДА

Сүзлектә мәкаләләр алфавит тәртибендә урнаштырылды.

Сүзлеккә кертү өчен берәмлекләр сайлаганда кыенлык тудырган очракларның иң еш кабатланганнарына өстенлек бирелде, ягъни очраклы рәвештә җибәрелгән хәреф хаталары түгел, систематик ялгышлар тикшерелде. Ялгыш дип табылган очраклар махсус помета белән күрсәтелде: *ялг.*

Вокабула буларак сүзлектә төрле сүз төркеменә караган берәмлекләр теркәлде һәм алар пометалар белән күрсәтелде:

**КҮПИҖЕКЛЕ** *с. ялг.* ....
**ҺӘР-БЕР** *а. ялг.* ... һ.б.

Сүзлек берәмлеге – вокабула (баш сүз) итеп аерым лексемалар гына алынды, сүзтезмә, гыйбарә кебек катлаулы конструкцияләр алынмады.

Укучыга ялгыш очракның нидән гыйбарәт булуын аңлауны җиңеләйтү өчен, мисалга аны чагылдырган җөмләләр китерелде, һәрберсенең алынган чыганагы күрсәтелде.

**МЕМОРИА́Л** *и.* Зур тарихи вакыйга яки даһи шәхес истәлегенә багышланган архитектура-скульптура ансамбле яки монумент; *ялг.:* **мемориал такта, мемориал үзәк, мемориал комплекс**.... *Кичә Сөйки кичүе янында яр буенда теплоходта һәлак булучылар истәлегенә* ***мемориал*** *комплекс ачылды*. Идел таңнары...

Кыенлык тудырган очраклар гомумиләштерелеп, аның барлыкка килү сәбәпләрен һәм башка үзенчәлекләрен чагылдырган аңлатмалар язылды. Бу аңлатма, гадәттә, иң киң кулланылган бер сүз вокабуласында гына бирелә һәм шул ук типка караган башка очраклар *к.* (карагыз) пометасы белән шуңа җибәрелә. Мәсәлән:

**ГАЗЕТА** *и. вар.* ...

Кайбер алынмалар татар теле тарафыннан өлешчә үзләштерелеп, ***котлет, резин, фанер*** кебек сүзләрдә сүз ахырында ***-а*** сузыгы апокопа кичереп, төшеп кала. Бу әдәби тел өчен норма

булып санала. Аларны чыганак телдәгечә тулы язылышта куллану стилистик вариант булып тора.

**КОТЛЕТА** *и. вар. ...*; *к.* **газета**.

Кыенлык турыдан-туры сүзнең язылышы белән, мәсәлән, кушымчаларның алгы яки арткы рәт, яңгырау яки саңгырау вариантын сайлау белән, бәйле булса, исемнәрдә вокабуладан соң өтер аша тартымлы баш килеш, юнәлеш килеш, күплек сан формалары бирелде. Шул ук рәвешле ялгыш вариантлар да күрсәтелде һәм аларга мисаллар китерелде. Бу ялгышларның телдә таралышын һәм проблеманың тирәнлеген күрсәтү өчен эшләнде.

**ЛАГЕРЬ** *и.* Лагерьга, лагере, лагерена, лагерьлар; *ялг.:* **лагерьгә, лагеренә, лагерьләр; лагергә, лагерләр; лагерга, лагеры, лагерына, лагерлар**. *Хөкем урыны итеп иң куркыныч дәүләт җинаятьчеләре сөрелә торган Рогервик* ***лагеры*** *билгеләнә.* Г. Мөхәммәтшин. *Җәйге* ***лагерга*** *сыер саварга мин төшеп киттем.* «Мәйдан» журналы

Кыенлык охшаш яңгырашлы яки язылышлы пароним сүзләрне яки омонимнарны куллануда булса, аларның мәгънә аермасын күрсәтү өчен икесе дә теркәлде, кыскача аңлатмалары бирелде һәм махсус *чаг.* пометасы белән берсе икенчесенә җибәрелде:

**ЛИБЕРАЛ** *и.* Либерализм карашларындагы кеше ... *чаг.:* **либераль**

**ЛИБЕРАЛЬ** *с.* Либерализмга бәйле; йомшак ... *чаг.:* **либераль** һ.б.

Сүзлектә баш сүз итеп сүзләрнең дөрес варианты да, ялгыш варианты да алынды. Бу махсус рәвештә эшләнде. Беренчедән, төзүчеләрнең максаты – кулланучыларга эзләгән сүзне тизрәк, уңайлырак табу мөмкинлеген тәэмин итү. Икенчедән, гади укучы сүзне эзләгән вакытта аның дөрес вариантын белмәскә дә мөмкин. Сүзнең китерелгән варианты ялгыш булган очракта, ул махсус помета белән китерелә, мәкалә азагында аның дөрес варианты теркәлә.

Вокабула итеп алынган сүз үзе дөрес булып, ә ялгыш аның төрләнешендә, стилистик кулланылышында булса, помета *ялг.:* рәвешендә ике нокта белән бирелә һәм типик хаталарны күрсәткән сүзтезмәләр шуннан соң килә, соңыннан мисал җөмләләр китерелә.

**МАКСАТ** *и.* Теләк, хая, морад; *ялг.:* **максатка ату, максатка тидерү**. *Һәр снайперга* ***максат*** *беркетелгән. --- **Максат** урыныннан күчә, снайпер да күзләре белән күчә.* Татарстан яшьләре; *дөр.:* **цель, мишень, мәлә, тәмек**.

Ягъни *максат* сүзе ялгыш түгел, **максатка ату, максатка тидерү** кебек тезмәләр генә ялгыш булып тора.

Сүзлектә материалны теркәү рәвеше ялгышларның төреннән чыгып хәл ителгәнгә күрә, мәкаләләрнең структурасы да бертөрле генә түгел.

Басым вокабула итеп алынган һәрбер сүзгә, аның дөрес булу-булмавына карамастан, куелды. Кайбер очракта басым ялгыш куллану очрагын дөрес очрактан аеру өчен мәкалә эчендә дә күрсәтелде, мәсәлән:

**ЗАКО́НЧАЛЫК** *и. ялг.* Законлылык, законлы булу, законга сыю. ***Закончалык нигезендә*** *комиссия составына шулай ук районның контроль-хисаплау палатасы рәисе дә керә.* Маяк; *дөр.:* **закон нигезендә, закон кысаларында, законга нигезләнеп, законлы рәвештә**; *чаг.:* **закончалы́к**.

**ЗАКОНЧАЛЫ́К** *и.* Билгеле эзлеклелек, кагыйдә; *чаг.:* **зако́нчалык**.

Сүздә бер генә сузык булган сүзләрдә, билгеле булганча, басым күрсәтелми.

Басымнарның вариантлары булганда, ягъни әйтелешнең икесе дә дөрес булганда, берьюлы ике басым күрсәтү очрагы да булды, мәсәлән:

**БИО-ЙО́ГУ́РТ**...

Сирәк булса да язылышы кыенлык тудырган очраклар да теркәлде, гадәттә, ул алынма сүзләр, аеруча гарәп-фарсы алынмалары, мәсәлән:

**МӘШГҮЛЬ** *хәб. сүз. ялг. Үз дөньябыз белән **мәшгүль** булыйк, Яхшылык бит тормыш бизәге!* К. Фатыйхова-Бәдретдинова. *Анда һәркем үз биографиясе, тормышта ирешкән уңышлары, балалары, оныклары турында, бүген ни белән **мәшгүль** булуын сөйли.* Мәйдан; *дөр.*: **мәшгуль**.

Сүзлек татар телендә сөйләшүчеләр, сөйләмен камилләштерергә теләүчеләр, гомумән телне яратучылар өчен файдалы булыр дип ышанабыз.

## ӘДӘБИЯТ ИСЕМЛЕГЕ


Абдуллина Р.С. Хәзерге татар теленең орфография һәм орфоэпиясе: Югары һәм урта махсус уку йортлары студентлары өчен уку әсбабы. – Казан: Мәгариф, 2009. – 239 б.

Большой энциклопедический словарь. Языкознание / под ред. В.Н. Ярцева. – М.: Дрофа, 1998. – 687 с.

Ганиев Ф.А. Формы инфинитива и их правописание // Татарский язык. Проблемы и исследования. – Казань: Татар. кн. изд-во, 2000. – С. 129–134.

Горбаневский М.В., Караулов Ю.Н., Шаклеин В.М. Не говори шершавым языком: о нарушениях норм литературной речи в электронных и печатных СМИ / М.В. Горбаневский, Ю.Н. Караулов, В.М. Шаклеин; Российский ун-т дружбы народов. – Изд. 3-е, испр. и доп. – М.: Российский ун-т дружбы народов, 2010. – 299 с.

Грамотное деловое общение. Тотальный помощник. – М.: Эксмо, 2019. – 160 с.

Ибраһимов С.М. Сандугач теле кирәк: Синтаксик стилистика: Уку-укыту ярдәмлеге. – Казан: Мәгариф, 2008. – 159 б.

Курбатов Х.Р. Хәзерге татар әдәби теленең стилистик системасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1971. – 192 б.

Сәлимов Х.Х. Авыр орфограммалар сүзлекчәсе. – Алабуга: Алабуга пед. ун-ты нәшр., 2004. – 32 б.

Сәлимов Х.Х. Татар теленең орфографик-орфоэпик сүзлеге. – Казан: Яңалиф, 2004. – 192 б.

Сабитова И.И. Словообразовательная характеристика лексики татарского языка: компьютерно-лингвографический аспект. – Казань: Фикер, 2002. – 143 с.

Скворцов Л.И. Теоретические основы культуры речи. – М.: Наука, 1980. – 352 с.

Розенталь Д.Э. Справочник по правописанию и литературной правке / под ред. И.Б. Голуб. – 21-е изд. – М.: АЙРИС-Пресс, 2017. – 368 с.

Тагирова Ф.И. Лексикографирование и орфографирование сложных слов татарского языка. – Казань: Фикер, 2005. – 138 с.

Тагирова Ф.И. К усовершенствованию орфографии татарского языка на примере парных слов // Актуальные экологические проблемы Республики Татарстан: тез. докл. III респ. науч. конф. – Казань, 1997. – С. 353–354.

Татар әдәби теленең алфавиты һәм орфографиясе. – Казан: Татгосиздат, 1941. – 24 б.

Татар грамматикасы. – Т. I. – М.: Инсан, Казан: Фикер. – 1998. – 512 б.

Татар грамматикасы. – Т. II. – М.: Инсан, Казан: Фикер. – 2002. – 448 б.

Татар грамматикасы. – Т. III. – М.: Инсан, Казан: Фикер. – 1999. – 512 б.

Татар грамматикасы: өч томда. – Т. I. Тулыландырылган 2 нче басма. – Казан: ТӘһСИ, 2015. – 511 б.

Татар грамматикасы: өч томда. – Т. II. Тулыландырылган 2 нче басма. – Казан: ТӘһСИ, 2016. – 432 б.

Татар грамматикасы: өч томда. – Т. III. Тулыландырылган 2 нче басма. – Казан: ТӘһСИ, 2017. – 536 б.

Татар теленең орфографик сүзлеге / төз. А.Х. Нуриева һ.б. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1983. – 279 б.

Татар теленең орфография сүзлеге / Ф.Ә. Ганиев, И.И. Сабитова; Ф.Ә. Ганиев ред. – Казан: Раннур, 2002. – 432 б.

Хаков В.Х. Стилистика һәм сүз сәнгате. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1979. – 158 б.

Хаков В.Х. Татар теле стилистикасы. – Казан: Татар. кит. нәшр., 1980. – 142 б.

Хисамов О.Р. Хәзерге татар орфографиясенең һәм орфоэпиясенең актуаль проблемалары. – Казан: Ихлас, 2012. – 34 б.

Хисамова Ф.М. Татар теле морфологиясе: Югары уку йортлары өчен д-лек. – Казан: Мәгариф, 2006. – 335 б.

Хисамова Ф.М. Татар теленең тарихи грамматикасы. Фонетика. Морфология. – Казан: Татар. кит. нәшр., 2017. – 182 б.

Шакирҗанова Ә.Б. Татар орфографиясенең кыен очраклары һәм укучыларның грамоталылыгын күтәрү юллары. – Казан: Казан ун-ты нәшр., 2004. – 134 б.

Юсупов Р.А. Инсафлының теле саф. – Казан, 1993. – 164 б.

Юсупов Р.А. Әдәп башы – тел. – Казан, 2000. – 218 б.

## ШАРТЛЫ КЫСКАРТЫЛМАЛАР

*а.* – алмашлык
*бот.* – ботаника
*вар.* – вариант
*дөр.* – дөрес
*зоол.* – зоология
*и.* – исем
*инфрм.* – информатика
*к.* – кара
*күпл.* – күплектә
*мәгъ.* – мәгънәсендә
*рәв.* – рәвеш
*с.* – сыйфат
*ф.* – фигыль
*чаг.* – чагыштыр
*ш. ук* –шулай ук
*ялг.* – ялгыш

## ТАТАР АЛФАВИТЫ

| | | | |
|---|---|---|---|
| Аа | Зз | Пп | Чч |
| Әә | Ии | Рр | Шш |
| Бб | Йй | Сс | Щщ |
| Вв | Кк | Тт | ъ |
| Гг | Лл | Уу | Ыы |
| Дд | Мм | Үү | ь |
| Ее | Нн | Фф | Ээ |
| Ёё | ң | Хх | Юю |
| Жж | Оо | Һһ | Яя |
| Җҗ | Өө | Цц | |

**АБСТРА́КЦИЯЛӘҮ** *ф. ялг. Димәк, санны тулаем күрә белә, димәк, баш миенең* ***абстракцияләү*** *куәте зур.* Х. Ширмән. *Әсәрнең идея-художество эчтәлеге нык кына* ***абстракцияләүгә*** *корылган.* А. Әхмәдуллин. *Әмма танып-белү гомумиләштерү-****абстракцияләүдән*** *гайре була алмый.* Ф. Яхин. *Кешенең* ***абстракцияләү*** *сәләте киң колачлы сүзләрне дә тудырган һәм дөньяны танып белүгә хезмәт иткән: яшәү, гомер, белем, батырлык, ирек, көч, горурлык...* Мәдәни җомга; *дөр.:* **абстракцияләштерү**.

**АБЫЗТҮТИ́** *и.* Абызтүтигә, абызтүтие, абызтүтиенә; *ялг.:* **абызтүтисе, абызтүтисенә**.

**АВЕНЮ́** *и.* Авенюга, авенюы, авенюына; *ялг.:* **авенюсы, авенюсына**. *Дөньяның иң кыйммәтле урамнары исемлегенә кереп, ул бары тик Нью-Йоркның Бишенче* ***авенюсы*** *һәм Парижның Елисей кырларыннан гына калыша*. Ватаным Татарстан. *Көньяк Протуберанец – Луиза* ***авенюсы***. Википедия.

Бу тип алынма сүзләрдә **-ю [йу]** авазларын белдергәнгә күрә, аларга кушымчаларның арткы рәт варианты ялгана.

**АВИАМОДЕ́ЛЬ** *и.* Авиамодельгә, авиамоделе, авиамоделенә, авиамодельләр; *ялг.:* **авиамодельга, авиамоделена, авиамодельлар**; *к.* **апрель**.

**АВИАМОДЕЛЬЛӘШТЕРҮ́** *ф. ялг. Аерым алганда, сүз суднолар төзү һәм* ***авиамодельләштерү*** *буенча эшчәнлекне торгызу турында бара*. Мәдәни җомга. ***Авиамодельләштерү*** *түгәрәген Александр Парамонов җитәкли*. Көмеш кыңгырау; *дөр.:* **авиамодельләр ясау**; *к.* **стимуллаштыру**.

**АВТОМАГИСТРА́ЛЬ** *и.* Автомагистральгә, автомагистрале, автомагистраленә, автомагистральләр; *ялг.:* **автомагистральга, автомагистралена, автомагистральлар**; *к.* **апрель**.

**АВТОМОБИ́ЛЬ** *и.* Автомобильгә, автомобиле, автомобиленә, автомобильләр; *ялг.:* **автомобильга, автомобилена, автомобильлар**. *Чистай – Түбән Кама юлының 61 нче чакрымында «Фольксваген Туарег» руленда барган 1979 елгы ир-егет зур тизлектә каршы як юлга чыккан һәм үз юлыннан, әмма «Фольксваген Туарег»га*

*каршы килгән «ВАЗ-2110»* ***автомобилена*** *бәрелгән.* Әлмәт таңнары. *Мисалга, узган якшәмбедә 22 меңләп сатып алучы бирегә килгән, парковка урыннары әлегә 2 мең* ***автомобильга*** *гына исәпләнгәнгә, бу мәсьәләдә кыенлыклар чыккан.* Татар-информ; *к.* **апрель**.

**АВТОРА́ЛЛИ** *и.* Автораллига, авторallie, автораллиена, автораллилар; *ялг.:* **автораллисы, автораллисына, автораллигә, автораллисе, автораллисенә, автораллиләр**. *«Алтын мөнбәр» мөселман киносы фестивале, «Ефәк юлы»* ***автораллиенең*** *дә тәэсире бар, мөгаен, ди Кашапова.* «Азатлык радиосы» сайты. «*Ефәк юл» автораллиеның идея авторы нәкъ менә Якупов.* Intertat.ru; *к.* **бигуди**.

**АВЫ́Л** *и.* Авылга, авылы, авылына, авыллар; *ялг.:* **ауылы, ауылына, ауыллар**. *Коридорның уң ягында* ***ауылның*** *тау ягына караган зур дүрт тәрәзә.* З. Зәйнуллин. *Рәмис бик дөрес язгансың, парны чыгардык, әмма коллык богауын өзәргә,* ***ауыл*** *халкының көченнән вә аңыннан килерме соң?* Матбугат.ру; *к.* **билбау**.

**АГАЙ-ЭНЕЧЕЛЕ́К** *и. ялг.; дөр.:* **агай-энелек**; *к.* **каллиграфчы**.

**АГИТ-БРИГА́ДА** *и. ялг. Резеда фестивальләрдә,* ***агит-бригадаларда*** *катнаша.* Күрше; *дөр.:* **агитбригада**; *к.* **мед-сестра**.

**АГИТ-МА́ССА** *и. ялг. Син «Кайта алмыйм, безнең* ***агит-масса*** *эше бик кызу», – дип җавап бир.* Р. Зарипов. *47 хуҗалыкның җидесе укытучылар гаиләсе булганга, оештыру,* ***агит-масса*** *эшләрен алар киң колач белән алып бардылар.* Казан утлары; *дөр.:* **агитмасса**; *к.* **мед-сестра**.

**АГИТ-ПРОПАГА́НДА** *и. ялг. Көн-төн музыка, көн-төн* ***агит-пропаганда***. Казан утлары; *дөр.:* **агитпропаганда**; *к.* **мед-сестра**.

**АГНО́Э** *и.* Агноэга, агноэсы, агноэсына, агноэлар; *ялг.:* **агнойга, агнойлар, агное, агноена, агноелар, агноэгә, агноэсе, агноэсенә, агноэләр**; *к.* **алоэ**.

**АДАПТА́ЦИЯЛӘҮ** *ф. ялг. Ул тагын ике мәсьәләгә басым ясады: татар телен өйрәнүчеләр өчен әдәби әсәрләрнең текстын* ***адаптацияләү****, җиңелләштерү һәм татар әдипләренең әсәрләрен рус теленә тәрҗемәдә бастырып чыгару.* Фән һәм тел. *«Бу мәсьләне чишкәндә тәрбия эшләренә, яңа шартларга* ***адаптацияләү*** *һәм сәламәт яшәү рәвешен пропагандалауга игътибар юнәлтмичә һичничек тә булдыра алмыйбыз», – диде Марат Бариев.* Казан. Меңьеллык сәхифәсе. *Мигрантларны* ***адаптацияләүгә,***

*аларга тиешле шартлар тудыруга төп игътибарны юнәлтергә кирәк.* Кызыл таң; *дөр.:* **адаптацияләштерү**.

**АДВОКАТЧЫЛЫ́К** *и. ялг.* ***Адвокатчылык*** *вазифасы; дөр.:* **адвокатлык**; *к.* **каллиграфчы**.

**АҖА́У** *и.* Аҗауга, аҗавы, аҗавына, аҗаулар; *ялг.:* **аҗауы, аҗауына**; *к.* **билбау**.

**АКВАРЕ́ЛЬ** *и.* Акварельгә, акварele, акварелена, акварельләр; *ялг.:* **акварельга, акварелена, акварельлар**. *Үзәккә караган мәйданда балаларның кул эшләре – сәйлән, күн, агач эшләнмәләр, тегелгән уенчыклар,* ***акварельдан*** *алып майлы бояуга кадәр кулланып ясалган картиналар каршы алды*. Татар-информ; *к.* **апрель**.

**АККЛИМАТИЗА́ЦИЯЛӘҮ** *ф. ялг. Алманың көньяк сортларын* ***акклиматизацияләү***; *дөр.:* **акклиматизацияләштерү**.

**А́КНЕ** *и.* Акнега, акнесы, акнесына, акнелар; *ялг.:* **акнегә, акнесе, акнесенә, акнеләр**; *к.* **алоэ**.

**АКСЫ́Л-ЗӘҢГӘР** *с. ялг. Безнең аңда кызулык – якты кояш, саргылт-кызыл ут белән, салкынлык исә –* ***аксыл-зәңгәр*** *боз белән бәйләнгән.* Ф. Хатипов; *дөр.:* **аксыл зәңгәр**; *к.* **кызгылт-сары**.

**АКЧАЛАШТЫРУ́** *ф. ялг. Тормыш ритмын да үзгәртеп кенә торалар: әле яңа ел каникуллары оештырып, ун көн эштән биздерәләр, әле ташламаларны* ***акчалаштырабыз*** *дип Гайдар бетергән чиратларга кабат җан өрәләр.* Татарстан яшьләре. *Чөнки 2005 елда ташламаларны* ***акчалаштыру*** *хакындагы закон эшли башлагач, сугыш ветераннарын торак чиратына куймый башлаганнар иде.* Ватаным Татарстан. *Әйтик, программаның аерым бер төбәктә сынау үтүе, «ташламаларны* ***акчалаштыру****», «балык тотуны түләүле итү» кебек уйлап бетермәгән яңалыкларны булдырмаячак, имеш.* Безнең гәҗит; *дөр.:* **акчага алмаштыру, акчага әйләндерү**; *к.* **стимуллаштыру**.

**А́ЛИБИ** *и.* Алибига, алибие, алибиена, алибилар; *ялг.:* **алибисы, алибисына, алибигә, алибисе, алибисенә, алибиләр**. *Полициядә аның* ***алибисын*** *раслаган участковыйның да документларын алмадылар, күршеләрнең иремне яхшы яктан сурәтләгән характеристикаларын да алмадылар*. Самара региональ «Дуслык» һәм Самара шәһәр «Ак бәхет» иҗади-иҗтимагый оешмаларының уртак сайты; *к.* **бигуди**.

**АЛКОГО́ЛЬ** *и.* Алкогольгә, алкоголе, алкоголенә, алкогольләр; *ялг.:* **алкогольга**, **алкоголена, алкогольлар**. *Ләкин героинга*

*бәяләр арту белән наркотик кулланучыларның бер өлеше* ***алкогольга*** *һәм синтетик наркотикларга, шул исәптән азык мәге һәм мәк саламы катнашмасына күчкән.* Татар-информ. *Сыйфатсыз* ***алкогольдан*** *агуланучылар, үлүчеләр санын киметү юнәлешендә ТР дәүләт алкоголь инспекциясенә ТР Сәламәтлек саклау министрлыгы белән берлектә уйлашырга, киңәш-табыш итәргә кирәк, дип саный Премьер*. Рәсми Татарстан; *к.* **апрель**.

**АЛО́Э** *и.* Алоэга, алоэсы, алоэсына, алоэлар; *ялг.:* **алойга, алойлар, алое, алоена, алоелар, алоэгә, алоэсе, алоэсенә, алоэләр**. *Агачсыман* ***алой*** *– безнең илдә киң таралган дару үләне булып исәпләнә.* Минем йорт. *Ярты стакан вакланган* ***алой*** *яфрагына бер стакан шикәр комы яисә бал салып, караңгы урында өч көн тотыгыз.* Сөембикә.

Рус теле аркылы кергән алынмаларның бу төрендә **[-э]** авазы басымлы иҗек артыннан килгәнгә күрә әйтелештә кыскарак әйтелә, ләкин язуда бу чагылмый. Бу типтагы сүзләрдә **[-э]** авазы кушымчага түгел, тамырга карый, шуңа күрә ул кыскармый, татар кушымчалары тулы сүзгә ялгана. Гомумән, күпчелек экзотик атамалар татар фонетикасына яраклаштырылмый, әйтелешендә һәм язылышында чыганак телдәге яңгырашын һәм язылышын саклый. Кушымчаларның арткы рәт варианты ялгана; *к. ш. ук* **атташе**.

**АЛТА́РЬ** *и.* Алтарьга, алтаре, алтарена, алтарьлар; *ялг.:* **алтарьгә, алтаренә, алтарьләр**; *к.* **лагерь**.

**АЛЬТЕРНАТИ́В** *с.* Икенче төрле: **альтернатив юл, альтернатив кандидат**; *ялг.:* **моңа альтернатив юк**; *чаг.:* **альтернатива**; *к.* **игуан**.

**АЛЬТЕРНАТИ́ВА** *и.* Ике яки берничә вариант арасында сайлау мөмкинлеге; башка вариант: **моңа альтернатива юк**; *чаг.:* **альтернатив**.

**АНСА́МБЛЬ** *и.* Ансамбльгә, ансамбле, ансамбленә, ансамбльләр; *ялг.:* **ансамбльга, ансамблена, ансамбльлар**. *Илдус һәм Фәния Абдуллиннар* ***ансамбльга*** *парлап йөри*. Якты юл. *Студент елларында Казан дәүләт университетының «Каз канаты» бию* ***ансамблена*** *йөреп, хәзергә кадәр аңа карата җылы хисләр һәм иҗатташлары белән элемтәләр саклаган сәнгать җанлы якташыбыз, очрашуга кайткач, --- баянда татар көйләреннән тезмә башкарып күрсәткән иде*. Татар-информ; *к.* **апрель**.

**АНТИ-БОЛЬШЕВИ́К** *и. ялг. «Прометей» оешмасы, билгеле булганча, Икенче бөтендөнья сугышына кадәр рус булмаган милләтләрнең **анти-большевик** хәрәкәтләренең координация үзәге булган*. Г. Исхакый; *дөр.:* **антибольшевик**; *к.* **фото-альбом**.

**АНТИ-КАҺАРМА́Н** *и. ялг. Өлкән ханымнан матбугат һәм телевидение аша террорчы һәм **анти-каһарман** ясап бетерделәр*. Шәһри Казан; *дөр.:* **антикаһарман**; *к.* **фото-альбом**.

**АНТИ-КСЕНОФО́БИЯ** *и. ялг. «**Анти-ксенофобия**» берлеге милләтара күрәлмаучанлыкка каршы интернет-сәхифә ачты*. Кәеф ничек? *«**Анти-ксенофобия**» җәмгыятенең Татарстан, Русия президентларына, прокурорга булган мөрәҗәгате уңай хәл ителмәсә, Козлов эшеннән китмәсә, без Чаллыда урам җыеннары уздырачакбыз*. «Азатлык радиосы» сайты; *дөр.:* **антиксенофобия**; *к.* **фото-альбом**.

**АНТИ-РЕКЛА́МА** *и. ялг. Реклама бирүчеләр кайчакта аның кешене туйдырып, **анти-рекламага** әйләнүен генә чамалап бетермиләр*. Татарстан яшьләре; *дөр.:* **антиреклама**; *к.* **фото-альбом**.

**АНТИ-СЕМИТИ́ЗМ** *и. ялг. Хәзерге исламофобия 1930 еллардагы **анти-семитизмны** хәтерләтә*. «Азатлык радиосы» сайты; *дөр.:* **антисемитизм**; *к.* **фото-альбом**.

**АНТИ-ТЕРРО́Р** *и. ялг. Чечня тормышын яктыртучы журналист Иван Сухов **анти-террорга** каршы чаралар туктатылу бик тә мөмкин, дип саный*. Безнең гәҗит; *дөр.:* **антитеррор**; *к.* **фото-альбом**.

**АНТИ-ФАШИ́СТ** *и. ялг. Бакый Гансның коммунист булмаса да, күренекле **анти-фашист** икәненә ышанган иде инде*. Г. Әпсәләмов; *дөр.:* **антифашист**; *к.* **фото-альбом**.

**АНТРЕСО́ЛЬ** *и.* Антресольгә, антресоле, антресоленә, антресольләр; *ялг.:* **антресольга, антресолена, антресольлар**. *Милиционерлар ул яшеренгән фатирга бәреп кергәч, җинаятьче башта **антресольга** кереп качып калмакчы була*. Татарстан яшьләре; *к.* **апрель**.

**АҢКА́У** *и.* Аңкауга, аңкавы, аңкавына, аңкаулар; *ялг.:* **аңкауы, аңкауына**; *к.* **билбау**.

**АПРЕ́ЛЬ** *и.* Апрельгә, апреле, апреленә, апрельләр; *ялг.:* **апрельга, апрелена, апрельлар**. *Кышкы сезон беткәнче дүрт ай буена, төгәлрәге, 15 **апрельга** кадәр Татарстан башкаласына зур йөк машиналарына көндез керү тыела һәм шул хакта шәһәр Башкарма*

*комитетының былтыр ноябрьда чыгарган 8182 нче күрсәтмәсе гамәлдә.* Татар-информ. *Кадрлар хезмәте җитәкчесе сүзләренчә, РФ Президенты тарафыннан дәүләт хезмәткәрләре санын киметү бурычы куелуга бәйле үзгәрешләр үтәлергә тиеш: 2011 елның 1* ***апрелена*** *кадәр 5 процент, аннары тагын 1 ел эчендә 10 процент, 2013 елның 1* ***апрелена*** *кадәр 5 процент.* Рәсми Татарстан.

**-ль** гә тәмамланган алынма сүзләргә һәрвакыт кушымчаларның алгы рәт варианты гына ялгана, чөнки алынмалардагы палаталь **[л]** авазы татар теленең үз авазына бик якын тора.

Күп очракта кушымчаларның алгы һәм арткы рәт вариантларын ялгаганда җибәрелгән ялгышлар татар телендә тартыкларның палаталь һәм веляр вариантлары арасындагы аерманың бик аз булуына бәйле (*к.* Татар грамматикасы, Т. I, 2015: 47 б.).

**АПТЕ́КАРЬ** *и.* Аптекарьга, аптекаре, аптекарена, аптекарьлар; *ялг.:* **аптекарьгә, аптекаренә, аптекарьләр**; *к.* **лагерь**.

**АРКА́У** *и.* Аркауга, аркавы, аркавына, аркаулар; *ялг.:* **аркауы, аркауына**; *к.* **билбау**.

**АРМАТУ́Р** *и. вар.* ***Арматур*** *цехларында яки заводында челтәр яки каркас рәвешендәге эре элементлар җитештерелә.* Төзү материаллары. *Берзаман барыбызның да карашы Әхәт кулындагы алтмыш-җитмеш сантиметр зурлыктагы* ***арматур*** *таякка төште*. Шәһри Казан. *Предприятиедә шулай ук* ***арматур*** *челтәрләрне эретеп ябыштыру җайланмасы да урнаштырылды*. Шәһри Чаллы; *к.* **газета**.

**АРТЕ́ЛЬ** *и.* Артельгә, артеле, артеленә, артельләр; *ялг.:* **артельга, артелена, артельлар**. *Әниемне килүгә товар вагоннарыннан известка бушатырга куйдылар, ә кесәсендә йөрәк авырулы булуы турында язуы табылгач, бәхетенә каршы,* ***артельга*** *оекбашлар бәйләргә күчерделәр, ул өчәр норма биреп эшли иде.* Язмыштан узмыш юк; *к.* **апрель**.

**АРТИ́КЛЬ** *и.* Артикльгә, артикле, артикленә, артикльләр; *ялг.:* **артикльга**, **артиклена, артикльлар**; *к.* **апрель**.

**АРХИПА́СТЫРЬ** *и.* Архипастырьга, архипастыре, архипастырена, архипастырьлар; *ялг.:* **архипастырьгә, архипастыренә, архипастырьләр**; *к.* **лагерь**.

**АРЧИ́** *и.* Арчига, арчие, арчиена; *ялг.:* **арчисе, арчисенә**.

**АСРА́У** I *и.* Асрауга, асравы, асравына, асраулар; *ялг.:* **асрауы, асрауына**; *к.* **билбау**.

**АСРА́У** II *ф.* Асравы; *ялг.:* **асрауы**. *Нишләп аның дуңгыз **асрауы** безгә комачауласын?* Безнең гәҗит; *к.* **билбау**.

**АССИГНОВА́НИЕ** *и.* Ассигнованиегә, ассигнованиесе, ассигнованиесенә, ассигнованиеләр; *ялг.:* **ассигнованиега, ассигнованиесы, ассигнованиесына, ассигнованиелар**. *2011–2015 елларга планлаштырылган бюджет **ассигнованиеларының** гомумкүләме 168,5 миллиард чамасы тәшкил итте.* Шәһри Казан; *к.* **звание**.

**АССИГНОВА́НИЯ** *и. ялг. Бюджет **ассигнованияләрен** 720 млнга арттыру карары дәүләт социаль ярдәмен дәгъвалаучы кешеләр саны үсү сәбәпле кабул ителгән.* Татар-информ. *Югары Чагадай авылында бюджет **ассигнованияләре** һәм башка чыганаклар хисабына социаль объектлар төзү артачак.* Татарстан Республикасы Дәүләт Советы мәгълүмат бюллетене; *дөр.:* **ассигнование**; *к.* **предприятия**.

**АССОРТИ́** *и.* Ассортига, ассортие, ассортиена, ассортилар; *ялг.:* **ассортисы, ассортисына, ассортигә, ассортисенә, ассортиләр**; *к.* **бигуди**.

**АТА́У** I *и.* Атауга, атавы, атавына, атаулар; *ялг.:* **атауы, атауына**. *Административ максатларда Мальдив Җөмһүриятенең 26 табигый **атауы** 19 административ атауга бүленә.* Википедия. *Утраулар океаннан бик аз биеклектә торалар: архипелагның иң биек ноктасы – Адду көньяк **атауында** – 2,4 м*. Википедия; *к.* **билбау**.

**АТА́У** II *ф.* Атавы; *ялг.:* **атауы**. *Мәсьәлә язучының үзен кем дип **атауында** түгел, аның нинди әсәр язуында.* М. Кәбиров. *Алтын Урданың үзендә тудырылган чыганаклардан андагы халыкларның үзләрен үзе «татар» дип **атауы** билгеле түгел*. Безнең гәҗит; *к.* **билбау**.

**АТЕЛЬЕ́** *и.* Ательега, ательесы, ательесына, ательелар; *ялг.:* **ательегә, ательесе, ательесенә, ательеләр**.

**-ье** га тәмамланган алынма сүзләрнең әйтелеше **[’йэ]** булганга күрә, аларга кушымчаларның арткы рәт варианты ялгана; *к. ш. ук* **атташе**.

**АТО́ЛЛ** *и.* Атоллга, атоллы, атоллына, атоллар; *ялг.:* **атолга, атолы, атолына, атолллар, атоллалар**. *Тропик диңгезләрдә сайлыкта тереклек итүче мәрҗән полипларының күпчелек төрләре рифларның, **атоллалар** һәм утрауларның нигезен тәшкил итә.* Биология. *Бу чагыштырмача зур сан, Һинд Океанында күп*

*утраулар һәм* ***атоллардан*** *торган илнең халык саны шул ук халык санын алу буенча 269000 икәнен исәпкә ал[а]*. Википедия; *к.* **металл**.

**АТТАШЕ́** *и.* Атташега, атташесы, атташесына, атташелар; *ялг.:* **атташегә, атташесе, атташесенә, атташеләр**. *Алар әйтмәсә дә, кыз сәер төрек* ***атташесенә*** *бер күрүдә гашыйк булган иде.* Р. Батулла. *«Өстәвенә ул бик тыйнак иде», – ди Ярославль хоккей клубының пресс-****атташесе*** *Владимир Малков*. Шәһри Казан.

Фонетик яктан үзләштерелмәгән алынмаларда нигез ахырындагы **е** [**э]** итеп укылганга күрә, аларга кушамчаларның арткы рәт варианты ялгана.

**А́У** *и.* Ауга, авы, авына, аулар; *ялг.:* **ауы, ауына**. *Милләтпәрвәр буларак, ул бөркет* ***ауы*** *белән мавыгучы татарны сурәтли.* Татар-информ; *к.* **билбау**.

**АХИРИ́** *и.* Ахиригә, ахирие, ахириенә; *ялг.:* **ахирисе, ахирисенә**.

**АЧЫ́К-АЛТЫН** *с. ялг. Бәлки, бу ерак түр стенада нәкъ мебель төсендәге* ***ачык-алтын*** *тонлы зур гобелен эленеп торудан шулай тоелгандыр*. Р. Мирхәйдәров; *дөр.:* **ачык алтын**; *к.* **ачык-кызыл**.

**АЧЫ́К-ҖЕТЕ** *с. ялг. Кеше күп җыелган урыннарга (сәүдә үзәге, аэропорт, вокзал...) барасыгыз булса, балагызга күзгә ташланып торган* ***ачык-җете*** *төстәге киемнәр кигертегез; киеменә исем-фамилиясе күрсәтелгән билге тегеп куегыз; аны телефоныгызга гына булса да төшереп алыгыз*. Сөембикә; *дөр.:* **ачык җете**; *к.* **ачык-көр**.

**АЧЫ́К-ИРКЕН** *с. ялг. Алга таба* ***ачык-иркен*** *сөйләшү китте*. Р. Батулла; *дөр.:* **ачык, иркен**; *к.* **ачык-көр**.

**АЧЫ́К-КӨЛӘЧ** *с. ялг. Мидхәтнең Әнисәсе – җиңел гәүдәле,* ***ачык-көләч*** *хатын – җил-җил атлап, өстәлгә самовар китереп утырта, кош теле, бал, каймак, коймак куя.* Р. Мулланурова; *дөр.:* **ачык, көләч**; *к.* **ачык-көр**.

**АЧЫ́К-КӨР** *с. ялг. Коръәне Кәримне* ***ачык-көр*** *тавыш белән моңлы-аһәңле итеп уку – ул үзе бөек бәхет*. Р. Батулла. – *Хәзер, хәзер, – диде Кави ага, гадәтенчә ашыкмыйча, хәрбиләрчә* ***ачык-көр*** *тавыш белән*. И. Салахов; *дөр.:* **ачык, көр**.

Сызыкча аша язылган сүзләр парлы сүзләр дип кабул ителә, аларның компонентлары бер-берсенә карата тезүле мөнәсәбәттә тора. Тикшерү өчен алар арасында *һәм* теркәгече куеп карарга

мөмкин. Мәгънәгә зыян китермичә *һәм* теркәгече куела икән – бу парлы сүз була, шуңа күрә сызыкча аша языла. Мәгънәгә зыян китермичә бу компонентларны шулай ук аерып – өтер аша да язарга мөмкин. Бу очракта исә алар парлы сүз түгел, җөмләнең тиңдәш кисәкләре булып тора. Мәсәлән, ***ачык-көр тавыш*** «бер үк вакытта ачык та, көр дә» мәгънәсендә; ***ачык, көр тавыш белән***. Туры, конкрет мәгънәсендә килгән кайбер очракларда алар бер үк предметның төрле сыйфатларын белдереп киләләр һәм өтер аша да язылмыйлар, мәсәлән, ***куе озын чәч, ачык кечкенә ишек***. Ләкин *ачык* сүзенең төсләрне белдергән сүзләр белән язылышы башка кагыйдәгә буйсына; *чаг.:* **ачык-кызыл**.

**АЧЫ́К-КЫЗГЫЛТ** *с. ялг.* ***Ачык-кызгылт*** *төсе ошамады. Шуңа караңгырак төскә буярга кушкан идем.* Р. Вәлиев; *дөр.:* **кызгылт** яки **ачык кызыл**; *к.* **куе-яшькелт**.

***Ачык*** компонентының төсне белдергән сүзләр белән язылышы турында *к.* **ачык-кызыл**.

**АЧЫ́К-КЫЗЫЛ** *с. ялг. Гаяз алан-йолан каранып алды һәм бер үк вакытта уттай* ***ачык-кызыл*** *да «ата-яшел» дә булган бер ранетка алмасын өзеп җиңенә сыпырып тешләп алды.* Р. Гаязетдин. *Ләкин төнлә бу урынны танырлык түгел, караңгыда зур* ***ачык-кызыл*** *чәчәкләр аткан кактуслар бөтенләй башкача күренә икән.* Р. Мирхәйдәров; *дөр.:* **ачык кызыл**.

Бу төр очракларда **ачык** сүзе төсне белдергән сүз белән килеп, аны ачыклап килә, аңа «шул төснең җитәрлек куе, интенсив булмаганы, сыеграк төсмере» мәгънәсен бирә. Шундый ук типтагы ***бик матур, артык озын*** һ.б.ш. очраклардагы кебек аерым языла, чөнки алар арасында төзүле бәйләнеш юк. Төс атамалары белән килеп, аларның интенсивлык дәрәҗәсен, куелыгын һ.б.ш. белдергән ***куе, кара, коңгырт*** сүзләренең язылышы шул ук закончалыкка буйсына. Сыйфатларның ***-гылт/-гелт, -кылт/-келт, -су, -сыман*** кебек формантлар белән ясалган кимлек дәрәҗәсе шундый ук функцияне үти, төп төсне атаган сыйфатны ачыклап килә һәм шул ук закончалыкка буйсынып, аның белән аерым языла.

Ә компонентлар ике аерым төсне белдерсә, икесе дә сыйфатның бер үк дәрәҗәсендә булса, ягъни икесе дә әлеге төсләрнең бер үк – я тулы, я ким – интенсивлыгын белдерсә, бу компонентлар арасында тезүле бәйләнеш була һәм алар сызыкча аша языла: мәс., ***яшькелт-алтынсу***, ***кызыллы-яшелле*** һ.б.ш.

**АЧЫ́К-САРЫ** *с. ялг. Омск, Томск һәм Төмән өлкәләрендә **ачык-сары** һәм кызыллы-сарылы кар яуган дип хәбәр итә Россиянең гадәттән тыш хәлләр министрлыгы.* «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе сайты; *дөр.:* **ачык сары**; *к.* **ачык-кызыл**.

**АЧЫ́К-СОРЫ** *с. ялг. Color Oerlay ны тамгалагыз, анда **ачык-соры** төс сайлагыз.* Фотошоп дәресләре; *дөр.:* **ачык соры**; *к.* **ачык-кызыл**.

**АЧЫ́К-ЯКТЫ** *с. ялг. Ак яулык, алсу күлмәк киеп, ачык йөз белән атлап барган мөселман кызын күргәч, җәмәгать исламның кара киемнәргә төренеп йөрергә кушмавын, киресенчә, **ачык-якты** булырга дәшүен аңлар, әйләнә-тирәдәге кешеләргә ярдәмгә ашыгучы, ачык йөзле мөселман егетләрен күреп, башкалар динебез турында да яхшыны гына уйлар иде.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар; *дөр.:* **ачык якты**; *к.* **ачык-көр**.

**АЧЫ́К-ЯШЕЛ** *с. ялг. Бер генә мизгелгә үләннәр **ачык-яшел** төскә керә, чыпчыклар чыркылдашканы ишетелә башлый...* Ә. Дусайлы; *дөр.:* **ачык яшел**; *к.* **ачык-кызыл**.

**АЭРОЗО́ЛЬ** *и.* Аэрозольгә, аэрозоле, аэрозоленә, аэрозольләр; *ялг.:* **аэрозольга, аэрозолена, аэрозольлар**. ***Аэрозольга** әйләнгән тозлы су тамчылары җил белән атмосферага күтәрелгәч, үз тирәләренә диңгездән күтәрелгән башка су парларын җыялар.* Безнең гәҗит; *к.* **апрель**.

**АЭРОМОБИ́ЛЬ** *и.* Аэромобильгә, аэромобиле, аэромобиленә, аэромобильләр; *ялг.:* **аэромобильга, аэромобилена, аэромобильлар**; *к.* **апрель**.

**АЯ́КӨСТЕ** *рәв. ялг. Кешеләр урыннарыннан сикереп тордылар, **аякөсте** килеш алкышлауларын дәвам иттерделәр.* Г. Әпсәләмов. *Бүтән офицерлар минем ише сержант халкы белән алай тәкәллефләнеп тормый, **аякөсте** торып кына сөйләшәләр иде.* В. Нуруллин. *Шуңа да Хәлим **аякөсте** кала бирде.* Ф. Яхин; *дөр.:* **аягөсте**; *к.* **ишекалды**.

**АЯ́КҮРӘ** *рәв. ялг. Тын да алмый **аякүрә** баскан халык алдында хәрби киемдәге егетләр аларны сәхнәгә алып менәләр.* Туган як. *Гөлсирин Абдуллина, Азат Абитов, Айсылу Габдинова, Рәнис Габбазовны Уфа тамашачысы **аякүрә** кул чабып озатты!* Саба таңнары. *Тамашачыларның бер өлеше таралмыйча **аякүрә** басып карады.* Бөтендөнья татар конгрессы; *дөр.:* **аягүрә**; *к.* **ишекалды**.

**АЯТЕЛКӨРСИ́** *и.* Аятелкөрсигә, аятелкөрсие, аятелкөрсиенә; *ялг.:* **аятелкөрсисе**, **аятелкөрсисенә**; *к.* **көрси**.

**ӘБИ́** *и.* Әбигә, әбисе, әбисенә; *ялг.:* **әбие, әбиенә**. *Ник яраткан дигәндә, Әркәнәй карчык бөтен авылга кендек **әбие** булган, бөтен авылда балаларның беренче авазларын ул ишеткән.* Г. Бәширов. *Мәчет төзелешендә актив катнашкан, тәрәвих намазларын калдырмаска тырышкан җитмешнең өстенә чыккан авыл **әбиенә** кул күтәрергә кем җөрьәт иткән?* Татарстан яшьләре.

Татар теленә ике сузык аваз рәттән килү хас булмаганга, сузык авазларга тәмамланган сүзләргә традиция буенча тартык авазга башланган кушымчалар ялгана, мәсәлән, III зат тартым кушымчасының ***-сы/-се*** варианты (*к.* Татар грамматикасы, Т. I, 2015: 145 б.). Әмма **[*и*]** авазына тәмамланган сүзләрне төрләндергәндә аларга асемантик тартыксыз варианты, ягъни ***-е*** кушымчасы кушыла (гомуми кагыйдәгә буйсынмаган сүзләр: *әби**се**, әти**се**, әни**се***). Ләкин чынлыкта бу кагыйдәдән чыгарма да түгел, чөнки бу очракта ***-е*** **[йэ]** кушымчасындагы **[й]** авазы ике сузыкны аеру функциясен үти. Аннан соң килгән кушымчаларның да алгы рәт варианты ялгана.

**ӘВӘ́Л** *рәв. ялг. Ә бит **әвәл** заманнарда бабайларыбыз кайда гына төпләнергә уйлаганда, беренче эш итеп мәчет торгызган.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар. ***Әвәл** заманда, Атабыз Адәм Хава анабыз белән тормыш итә башлагач, моны Аллаһы Тәгалә үз янына чакыртып ала, агач сука, биш үгез, озын чыбыркы бирә һәм әйтә: «Бар дөнья буйлап җир сөр».* Татар әдипләре; *дөр.:* **әүвәл**.

**ӘҖНӘБИ́** *и.* Әҗнәбигә, әҗнәбие, әҗнәбиенә; *ялг.:* **әҗнәбисе**, **әҗнәбисенә**; *к.* **көрси**.

**ӘЛЛӘ́-КАЙ** *а. ялг.; дөр.:* **әллә кай**; *к.* **әллә-кайда**.

**ӘЛЛӘ́-КАЙДА** *а. ялг. Җен-пәриләр дә **әллә-кайда** түгелдер, шушы алабута астында гына утырадыр*. Ф. Йосыпов; *дөр.:* **әллә кайда**.

***Әллә*** кисәкчәсе, башка сүз төркемнәре белән килеп, аларга билгесезлек төсмере өсти, һәрвакыт аерым языла, чөнки үзе генә дә мөстәкыйль сүз буларак кулланыла. Мәсәлән, ***кайтасыз әллә?*** Шул ук закончалыкка ***теләсә кем, теләсә кайсы, ничек тә, шул хәтле*** кебек конструкцияләр дә буйсына.

**ӘЛЛӘ́-КАЙДАГЫ** *а. ялг. Уллары Халим **әллә-кайдагы**, Себер дигән җирдә капитан чинында хезмәт итә*. Л. Таналин; *дөр.:* **әллә кайдагы**; *к.* **әллә-кайда**.

**ӘЛЛӘ́-КАЙДАН** *а. ялг. Шуңа өстәп **әллә-кайдан** күңел кайтаргыч улау тавыш килә башлады.* В. Исламетдин; *дөр.:* **әллә кайдан**; *к.* **әллә-кайда**.

**ӘЛЛӘ́-КАЙСЫ** *а. ялг.; дөр.:* **әллә кайсы**; *к.* **әллә-кайда**.

**ӘЛЛӘ́-КАЙЧАН** *а. ялг. Анда да бөтенләй уйламаган-көтмәгән, **әллә-кайчан** консервировать ителгән скважинадан нефть бәреп чыккан.* М. Хәсәнов. --- *яңа редактор үзе Татмедиада эшләгән вакытта «Гаилә һәм мәктәп» журналына беренче санны чыгарырга «булышканда» үзенең **әллә-кайчан** «Татарстан яшьләренә» язган бер мәкаләсен бераз үзгәртеп тыккан иде.* Матбугат.ру; *дөр.:* **әллә кайчан**; *к.* **әллә-кайда**.

**ӘЛЛӘ́-КАЙЧАНГЫ** *а. ялг.; дөр.:* **әллә кайчангы**; *к.* **әллә-кайда**.

**ӘЛЛӘ́-КАЙЧАННАН** *а. ялг.; дөр.:* **әллә кайчаннан**; *к.* **әллә-кайда**.

**ӘЛЛӘ́-КАЯ** *а. ялг. Ыграк суга башлаган идек, чикләвекнең төше изелеп бетеп, кабыклары **әллә-кая** очты.* Көмеш кыңгырау; *дөр.:* **әллә кая**; *к.* **әллә-кайда**.

**ӘЛЛӘ́-КАЯН** *а. ялг. Үзеңнең җырыңны **әллә-каян** танып аласың.* Саба таңнары. *Сагышлы, тормышында кайгы булган кешене **әллә-каян** танып була икән ул ---.* Теләче Информ; *дөр.:* **әллә каян**; *к.* **әллә-кайда**.

**ӘЛЛӘ́-КЕМ** *а. ялг. Хәзерге ирем төскә-биткә **әллә-кем** булмаса да, акыллы, тормыш итә белүче кеше.* Татарстан яшьләре. *Аның каравы киләчәктә алардан менә дигән төзүчеләр, ташчылар, эретеп ябыштыручылар, слесарьлар, тагын **әллә-кемнәр** --- чыгачак.* Матбугат.ру; *дөр.:* **әллә кем**; *к.* **әллә-кайда**.

**ӘЛЛӘ́-НӘРСӘ** *а. ялг. Мондый вакытта күзеңә ут түгел **әллә-нәрсә** күренер!* И. Хуҗин. *Егерме еллап, кояш нурларын чагылдырып, ул көзге өстәлемдә тора, ялгыш кына төшереп җибәргәнем дә, югалтканым да юк үзен. Югыйсә **әллә-нәрсәләр** югалып бетте.* Казан утлары. *Монысында быелгы уңыш: бәрәңге, кәбестә, --- казлар, тагын **әллә-нәрсәләр** саттылар.* Безнең Чирмешән; *дөр.:* **әллә нәрсә**; *к.* **әллә-кайда**.

**ӘЛЛӘ́-НИ** *а. ялг. Баш рольне башкарырга алынган актер Тукайга **әллә-ни** ошамаса да, башкасы булмаганлыктан, режиссёр бу җаваплы рольне Мират Борһановка ышанып тапшырды.* Р. Батулла. *Ләкин даими кырын караганга, җәберләп торганга*

*,ул **әллә-ни** үсеп китә алмаган*. Ватаным Татарстан. *Әмма мәктәпләрдә ел саен сентябрь аенда үткәрелә торган «медосмотр» нәтиҗәләре **әллә-ни** куандырмый*. Татарстан яшьләре; *дөр.:* **әллә ни**; *к.* **әллә-кайда**.

**ӘЛЛӘ́-НИК** *а. ялг.; дөр.:* **әллә ник**; *к.* **әллә-кайда**.

**ӘЛЛӘ́-НИКАДӘР** *а. ялг. Аның агачтан төшәсе килгәнен аңлаганга кадәр, **әллә-никадәр** кеше фотосурәткә төшереп китә*. Көмеш кыңгырау. *«Мәгърифәт»нең киләчәк хыялларында **әллә-никадәр** конкурслар, фикер алышулар ниятләнгән иде бит*. Безнең гәҗит. *Корабльдә **әллә-никадәр** милләт кешесе бер, дус команда булып яшәгәннәр*. Безнең Чирмешән; *дөр.:* **әллә никадәр**; *к.* **әллә-кайда**.

**ӘЛЛӘ́-НИКАДӘРЛЕ** *а. ялг. Кичәгә **әллә-никадәрле** кеше килде*. Йолдыз; *дөр.:* **әллә никадәрле**; *к.* **әллә-кайда**.

**ӘЛЛӘ́-НИНДИ** *а. ялг. Шуңа өстәп **әллә-нинди** ис килә – начар, хастаханә исе*. В. Исламетдин. – *Сөйләячәксең, барысын да хәтереңә төшерәчәксең, – диде ул, урта бармагын тырпайтып, – синең ише надан авыл хатыннарын гына түгел, **әллә-нинди** һавалы интеллигентларны да аз сындырмадык без!* Казан утлары; *дөр.:* **әллә нинди**; *к.* **әллә-кайда**.

**ӘЛЛӘ́-НИХӘТЛЕ** *а. ялг. дөр.:* **әллә нихәтле**; *к.* **әллә-кайда**.

**ӘЛЛӘ́-НИЧАКЛЫ** *а. ялг. дөр.:* **әллә ничаклы**; *к.* **әллә-кайда**.

**ӘЛЛӘ́-НИЧӘ** *а. ялг. Гөлнара дигән исем хикмәтлеме икән, **әллә-ничә** Гөлнараны беләм, барысы да тәвәккәл, булдыклы, курку белмәс кыю затлар!* Сөембикә. *Әле дә хәтерлим, әнием бәрәңге алган вакытта, **әллә-ничә** тапкыр су колонкасы янына барды: шайтан көчле бит*. Шәһри Казан. *Нәкъ менә авылларда җитештерелә торган продукциянең бәяләрен тезгенләп, Россия хөкүмәте узган елларда **әллә-ничә** тапкырлар баскан тырмага янә бер баса түгелме?* Ватаным Татарстан; *дөр.:* **әллә ничә**; *к.* **әллә-кайда**.

**ӘЛЛӘ́-НИЧӘМӘ** *а. ялг. **Әллә-ничәмә** мәртәбә килде теге егет*. Хезмәт даны; *дөр.:* **әллә ничә, ничәмә-ничә**; *к.* **әллә-кайда**.

**ӘЛЛӘ́-НИЧЕК** *а. ялг. – Карасам – сез савыккансыз икән, ә минем бүген кичәге сменадан соң ял көне, – дип, кош шикелле сайрады Антонина һәм Алик шунда ук **әллә-ничек** кәефләнде ---*. В. Исламетдин. *Тик урамга чыгып, бер челем кабызып, аны тәмам суырып бетергәч, үз-үземнән көлеп, **әллә-ничек** сөенеп тә куйдым*. Казан утлары; *дөр.:* **әллә ничек**; *к.* **әллә-кайда**.

**ӘЛЛӘ́-НИШЛӘП** *а. ялг. Алар белән пәрә-пәрә ызгышучы әбиләрне күреп, йөрәгем **әллә-нишләп** китте.* Безнең гәҗит; *дөр.:* **әллә нишләп**; *к.* **әллә-кайда**.

**ӘЛЛӘ́-НИШЛӘТҮ** *ф. ялг.; дөр.:* **әллә нишләтү**; *к.* **әллә-кайда**.

**ӘЛЛӘ́-НИШЛӘҮ** *ф. ялг.; дөр.:* **әллә нишләү**; *к.* **әллә-кайда**.

**ӘНИ́** *и.* Әнигә, әнисе, әнисенә; *ялг.:* **эние, эниенә**. *Хәтта **эние**безне дә, әгәр ул менә шушындый булса, үзебез чакырып алып күрсәтергә кыймас идек, уңайсызланыр идек, оялыр идек.* Ә. Еники; *к.* **әби**.

**ӘТИ́** *и.* Әтигә, әтисе, әтисенә; *ялг.:* **этие, этиенә**. *Кызы күз яшьләре белән томаланган матур соры күзләрен **этиенә** төбәде.* Л. Ибраһим-Вәлиди; *к.* **әби**.

**ӘТИ́-ӘНИ** *и.* Әти-әнигә, әти-әнисе, әти-әнисенә; *ялг.:* **эти-эние, эти-эниенә**. *Бүгенге башкорт татармын дисә, ул **этиенә-эниенә** хыянәт итә.* «Азатлык радиосы» сайты; *к.* **әби**.

**ӘҮӘ́Л** *рәв. ялг. Евдокия **әүәл** артыгы белән диндар иде, ә үзе галим Павлин белән буталды ---.* М. Хәбибуллин. *Үз-үзен ипкә китерергә тырышучылар иң **әүәл** үз күңелендә дөреслеккә омтылганнар.* М. Галиев. *Игътибар иң **әүәл** күкрәкчә-трусик ише әйберләргә юнәтелде ---.* Ф. Бәллүр; *дөр.:* **әүвәл**.

**ӘХЛА́К** *и.* 1) Әхлакка, әхлагы, әхлагына; *ялг.:* **әхлакъ**, **әхлакъка**. *Без, егетләр дә, **әхлакъ** сагына басып, Иркәне шелтәли башладык.* Р. Батулла. *Беренчедән, бу аларның **әхлакъларына** кагыла: призывник җинаять кылмаган, аңа карата суд карары чыгарылмаган булырга тиеш.* Әлки хәбәрләре. *Бүгенге көрәштә бары тик үзләренең милли **әхлакълары** булган халыклар гына мөстәкыйль булып, көрәшеп җиңә алалар*. Әдипләр. Әхмәт Дусайлының шәхси порталы.

2) Әдәп, тәрбия; *ялг.:* **әхлак чыгымнары, әхлак бурычы**.

Русча ***моральный ущерб, моральный долг*** һ.б.ш. сүзтезмәләрне ялгыш тәрҗемә итү нәтиҗәсендә барлыкка килгән. Әдәп турында сүз бармый, шуңа күрә ***әхлак*** сүзе урынсыз. Бу контекстта исә ***зыян*** турында сүз бара, ***чыгымнар*** сүзе шулай ук урынсыз кулланылган, чөнки ул «сарыф ителгән акча» мәгънәсен белдерә; *дөр.:* **берәүнең шәхесенә китерелгән зыян, берәүнең дәрәҗәсенә китерелгән зыян**.

**ӘХЛАКЫ́Й** *с. ялг.: Без өлкән буын алдындагы **әхлакый** бурычыбызны үтәп кенә калмаска, ә киләчәккә озак сроклы, нәтиҗәле,*

*яңа пенсия системасы төзергә тиешбез, – диде премьер*. Татарстан яшьләре; *дөр.:* **мораль бурыч, күңел бурычы, вөждан кушуы, намус кушканча** һ.б.ш.; *к.* **әхлак**.

**ӘХТӘРИ́** *и.* Әхтәригә, әхтәрие, әхтәриенә; *ялг.:* **әхтәрисе**, **әхтәрисенә**; *к.* **көрси**.

**БАВЫ́Р** *и.* Бавырга, бавыры, бавырына, бавырлар; *ялг.:* **бауыры, бауырына, бауырлар**. *Кырлай авылында туган, Булган казакъ җирендә. Сөйгән башкорт* ***бауырын*** *да, Җырлаган Русь илен дә.* Казан утлары; *к.* **билбау**.

**БАВЫРСА́К** *и.* Бавырсакка, бавырсагы, бавырсагына, бавырсаклар; *ялг.:* **бауырсагы, бауырсагына, бауырсаклар**. *Сәйлән белән чигелгән милли бизәкләр, җәймәләр һәм паласлар, киез итекләр һәм идән киезләре, чәкчәк һәм бал,* ***бауырсак*** *һәм пәрәмәчләр янында халык аеруча күп булды*. Саба таңнары; *к.* **билбау**.

**БАЙ** *с. ялг.:* **баерак**. *Усал телләр мине аннан талантлырак, фантазиягә* ***баерак*** *дип йөртсәләр дә, беркайчан да мин аннан өстенлек дәгъваламадым ---.* А. Гыйләҗев. *Бу таләпне алар рус попларының, татар муллалары белән чагыштырганда, күпкә* ***баерак*** *булуы белән дәлилләр*. А. Тимергалин. *Ә инде тематика ягыннан совет чоры драматургиясенең үзенә кадәрге чорга караганда* ***баерак*** *һәм төрлерәк булуын күрербез*. А. Әхмәдуллин; *дөр.:* **байрак**.

Бу сыйфатның чагыштыру дәрәҗәсе ***бай***- тамырына ***-рак*** кушымчасы кушылып ясала. ***Баерак*** формасында исә *[**байырак**] **бай*** + *-**(ы)рак*** тамырга да, кушымчага да карамаган артык **[ы]** авазы барлыкка килә. Бу күренеш татар телендә берничә тартыкның рәттән килә алмавы белән бәйле. Мондый авазны өстәү эпентеза дип атала. Ләкин ул күп очракта сөйләмдә генә була, язуда чагылырга тиеш түгел (*к.* Татар грамматикасы, Т. I, 2015: 40, 145 б.).

**БАЛЛ** *и.* Баллга, баллы, баллына, баллар; *ялг.:* **балга, балы, балына, баллар**. *Бүген иртәгә тарих белән физикадан ЕГЭ* ***баллары*** *билгеле була, Алла боерса.* Матбугат.ру. *«Яндекс. Пробки» сервисы Казанда 10* ***баллы*** *бөкеләр хасил булуын күрсәтә*. Татар-информ. *Математикадан керү* ***балы*** *10 процентка киметеләчәк.* «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе сайты. *Анда бюджет урыннарына конкурс бер урынга 20 кеше тәшкил иткән, ә БДИ буенча керү* ***балы*** *– 200*. Татар-информ; *к.* **металл**.

**БАНДЕРО́ЛЬ** *и.* Бандерольгә, бандероле, бандероленә, бандерольләр; *ялг.:* **бандерольга, бандеролена, бандерольлар**. *Татар халкы үсеше программасын әзерләү өчен, татарлар яшәгән төбәкләргә региональ программалар әзерләү буенча аның структурасы, инструкциясе һәм тиешле фәнни әдәбият җибәрелде, әмма нәтиҗәдә бер генә регион программа төзеп җибәрде, алдарак әйтелгән әсбаплар салынган 32* ***бандерольның*** *яртысы кире кайтты*. Татар-информ; *к.* **апрель**.

**БАНИ́** *и.* Банига, бание, баниена; *ялг.:* **банисы**, **банисына**; *к.* **көрси**.

**БА́НКА** *и. ялг.* **банкасы, банкага, банкалар**. *Патшага хезмәт итү өчен кирәк булган акчаны бай үзе турыдан-туры казна* ***банкасына*** *кертә бара.* Н. Яһудин; *дөр.:* **банк**, **банкы, банкка, банклар**; *к.* **страза**.

**БА́РРЕЛЬ** *и.* Баррельгә, барреле, барреленә, баррельләр; *ялг.:* **баррельга, баррелена, баррельлар**; *к.* **апрель**.

**БА́У** *и.* Бауга, бавы, бавына, баулар; *ялг.:* **бауы, бауына**. *Әнә бит – егет бармакларында изге тәсбих* ***бауы*** *уйнатып килә.* Г. Гыйльманов. – ***Бауыгызны*** *төшереп җибәрдегез, – диде ул, китә башлаган көләч иргә ягымлы елмаеп, – Алыгыз, кирәге чыгар*. М. Кәбиров. *Киптерү өчен фатир буйлап кер* ***бауы*** *суздык.* Сәяхәтнамә; *к.* **билбау**.

**БАХШИ́** *и.* Бахшига, бахшие, бахшиена; *ялг.:* **бахшисы, бахшисына**; *к.* **көрси**.

**БӘБИ́** *и.* Бәбигә, бәбие, бәбиенә; *ялг.:* **бәбисе, бәбисенә**. *Берәү тели саулык – туар* ***бәбисенә****.* Ватаным Татарстан. *Миранда Парижга 2 мартта ук ире Орландо Блум һәм* ***бәбисе*** *белән бергә килеп җиткән булган*. Intertat.ru; *к.* **әби**.

**БӘДӘВИ́** *и.* Бәдәвигә, бәдәвие, бәдәвиенә; *ялг.:* **бәдәвисе**, **бәдәвисенә**; *к.* **көрси**.

**БӘТИ́** *и.* Бәтигә, бәтие, бәтиенә; *ялг.:* **бәтисе, бәтисенә**. *Куй – сарыкның дала токымы, күбендә кара төстә,* ***бәтисеннән*** *каракуль (кара куй) җитештерәләр.* В. Ильясов; *к.* **әби**.

**БЕЛӘ́Ү** *и.* Беләүгә, беләве, беләвенә, беләүләр; *ялг.:* **беләүе, беләүенә**; *к.* **билбау**.

**БЕРИ́ЛЛ** *и.* Бериллга, бериллы, бериллына, бериллар; *ялг.:* **берилга, берилы, берилына, берилллар**; *к.* **металл**.

**БИ** *и.* Бигә, бие, биенә, биләр; *ялг.:* **бисе, бисенә**; *к.* **әби**.

**БИБЛИОГРА́ФИЯЛӘҮ** *ф. ялг. Р. Таһировның «Татар телендә басылган матур әдәбият, аның тарихы һәм тәнкыйть библиографиясе» дигән белешмәсе татар әдәбиятын* ***библиографияләүдә*** *беренче тәҗрибә булып тора.* Ә. Кәримуллин; *дөр.:* **библиография төзү, библиография җыю, библиография итеп бирү**; *к.* **стимуллаштыру**.

**БИБЛИОТЕ́КАРЬ** *и.* Библиотекарьга, библиотекаре, библиотекарена, библиотекарьлар; *ялг.:* **библиотекарьгә, библиотекаренә, библиотекарьләр**; *к.* **лагерь**.

**БИГУДИ́** *и.* Бигудига, бигудие, бигудиена, бигудилар; *ялг.:* **бигудигә, бигудисе, бигудисенә, бигудиләр, бигудисы, бигудисына**. *Барып керсәм, ни күрим, өендә башына* ***бигудиләр*** *тезгән бөтенләй башка хатын сөрмәләр тартып, бизәнеп утыра.* Ф. Баттал.

**-и** гә тәмамланган рус һәм Европа алынмалары татар сүзләре белән аналогия буенча III зат тартым кушымчасының **-е** вариантын кабул итә. Ләкин аннан соң килгән кушымчаларда яки башка категорияләр белән төрләндергәндә, русчадагы **[и]** авазының үзенчәлекләренә бәйле рәвештә, арткы рәт кушымчалары ялгана; *к. ш. ук* **эби**.

**БИКИ́НИ** *и.* Бикинига, бикиние, бикиниена, бикинилар; *ялг.:* **бикинисы, бикинисына, бикинигә, бикинисе, бикинисенә, бикиниләр**; *к.* **бигуди**.

**БИЛӘ́Ү** *и.* Биләүгә, биләве, биләвенә, биләүләр; *ялг.:* **биләүе, биләүенә**. *Россия Федерациясе Җир йөзендә киң мәйдан* ***биләүе*** *белән генә зур ил түгел, ә регионнарында яшәүче киң күңелле, ачык җанлы халкы белән дә бай.* Туган як; *к.* **билбау**.

**БИЛБА́У** *и.* Билбауга, билбавы, билбавына, билбаулар; *ялг.:* **билбауы, билбауына**. *Нәкъ әнә шунда инде Гунтерның туенда булган алдау ачыла да: туй вакытында кешегә күрсәтми торган плащ ярдәмендә пәһлеван кыз Брюнхильданы җиңгән Зигфрид сиздермичә генә яшь киленнең йөзеген һәм* ***билбауын*** *алган икән*. Ф. Урманчеев.

Сүз һәм иҗек арасында ***-у/-ү*** хәрефләре **[w]** фонемасын белдерә: ***тау, дәү, яуда*** (*к.* Татар грамматикасы, Т. I, 2015: 22–23, 45–49, 146 б.). Ике сузык арасында, ягъни интервокаль позициядә, **[w]** авазы үзгәрә (чөнки өч сузык рәттән килү татар теленә хас түгел) һәм язуда ***в*** хәрефе белән белдерелә.

**БИМЕТА́ЛЛ** *и.* Биметаллга, биметаллы, биметаллына, биметаллар; *ялг.:* **биметалы, биметалына, биметалллар**; *к.* **металл**.

**БИНО́КЛЬ** *и.* Биноклегә, бинокле, бинокленә, бинокльләр; *ялг.:* **биноклыга, биноклена, бинокльлар**. *Карап торырга **бинокльны** хәтерләткән әлеге җайланма лазер нуры ярдәмендә 999 метрдан ук транспортның 250 км/сәг кадәр тизлеген һәм ераклыгын терки, транспорт чарасын фотофиксация ярдәмендә таный.* Татар-информ; *к.* **апрель**.

**БИО-БИБЛИОГРА́ФИК** *с. ялг. Р. Фәхретдин «Асар» дигән **био-библиографик** җыентыгында Ш. Зәки турында мәгълүмат бирә һәм аның биш шигырен бастыра.* Татар әдәби теле тарихы. *Рашат Габдерәшит улы **био-библиографик** сүзлек өчен сигез йөзгә якын язучы, журналист турында мәгълүмат туплады.* Ш. Асылгәрәев; *дөр.:* **биобиблиографик**; *к.* **фото-альбом**.

**БИО-ИННОВА́ЦИЯ** *и. ялг. Алга таба Татарстан башлыгы һәм Саксония Премьер-министры кортежы Дрезденның **Био-инновация** үзәгенә юл алды.* «Рәсми Татарстан» порталы; *дөр.:* **биоинновация**; *к.* **фото-альбом**.

**БИО-ЙО́ГУ́РТ** *и. ялг. --- биредә сыр, ит һәм ит деликатеслары, какланган, киптерелгән, ысланган һәм тере балык, **био-йогурт**, каймак, май, чүпрәсез пешерелгән ипи, күптөрле чәй нигъмәтләрен авыз итәргә һәм үзең белән алып китәргә була иде.* Әлмәт таңнары; *дөр.:* **биойогырт**; *к.* **фото-альбом**.

**БИО-КЕФИ́Р** *и. ялг. **Био-кефирда** гадәти сөт кислоталарыннан тыш, бифидобактерияләр бар ---.* Сөембикә; *дөр.:* **биокефир**; *к.* **фото-альбом**.

**БИО-КОНТРО́ЛЬ** *и. ялг. Riccо – **био-контроль** сыйфат стандарты булган сәүдә маркалы соуслар булып санала*. Шәһри Казан; *дөр.:* **биоконтроль**; *к.* **фото-альбом**.

**БИО-МӘГЪЛҮМА́Т** *и. ялг. Бүгенге көндә ил табышының чирегеннән артык өлеше югары технологияләр өлкәсенә, ягъни **био-мәгълүмат** технологияләренә туры килә.* Шәһри Казан; *дөр.:* **биомәгълүмат**; *к.* **фото-альбом**.

**БИО-ӨСТӘМӘ́** *и. ялг. Бактың исә, әлеге хатын берничә ел дәвамында иреннән, балаларыннан яшереп, **био-өстәмәләр** кулланган икән.* Intertat.ru; *дөр.:* **биоөстәмә**; *к.* **фото-альбом**.

**БИО-ТӘЭСИ́Р** *и. ялг. Әлеге ике металл кеше организмына төрле **био-тәэсир** ясый*. Яшел Үзән; *дөр.:* **биотәэсир**; *к.* **фото-альбом**.

**БИО-ТО́К** *и. ялг. Земфира Якуповна сүзен әйтеп бетермичә, **био-токлар** аша фикерен тапшырырга теләгәндәй, күзлегенең*

*калын пыялалары аша аңа текәлде.* Н. Әхмәдиев; *дөр.:* **биоток**; *к.* **фото-альбом**.

**БИО-ТУАЛЕ́Т** *и. ялг. Совет районы матбугат үзәге хәбәр итүенчә, парк территориясенә, шулай ук стационар **био-туалетлар** да куелган*. Казан мэриясенең рәсми порталы. *Бауман урамында төнлә шәм яндырып эзләсәң дә бәдрәфләр табып булмый, **био-туалетлар** да куелмаган*. Кәеф ничек?; *дөр.:* **биотуалет**; *к.* **фото-альбом**.

**БИО-ФАБРИКА** *и. ялг. Аларны махсус **био-фабрикаларда** үстерәләр.* Кәеф ничек?; *дөр.:* **биофабрика**; *к.* **фото-альбом**.

**БИО-ХИ́МИК** *с. ялг. Авыруларның **био-химик** составын тикшереп, дәвалау турында хыялландым.* Татар-Ислам. Бөтенрәсәй мөселманнарының мәгълүмат агентлыгы; *дөр.:* **биохимик**; *к.* **фото-альбом**.

**БИО-ХИ́МИЯ** *и. ялг. 1979 елда мин Чечен-Ингушетия дәүләт университетының **био-химия** факультетына читтән торып укырга кердем*. Татар-Ислам. Бөтенрәсәй мөселманнарының мәгълүмат агентлыгы; *дөр.:* **биохимия**; *к.* **фото-альбом**.

**БИО-ЭНЕ́РГИЯ** *и. ялг. Кеше аура каналлары буенча **био-энергиясен** чит кешегә, әйләнә-тирәгә тапшыра һәм кирәкле энергияне читтән алмый, үзе барлыкка китерә.* Кәеф ничек?; *дөр.:* **биоэнергия**; *к.* **фото-альбом**.

**БИО-ЯГУЛЫ́К** *и. ялг. Соңгы арада нефть һәм газ бәяләренең артып китүе альтернатив башка энергия чыганакларын эзләргә мәҗбүр итте, шул исәптән **био-ягулыкка** килеп терәлделәр.* «Азатлык радиосы» сайты; *дөр.:* **биоягулык**; *к.* **фото-альбом**.

**БИРӘНИ́** *с. ялг. Авыл йокыга талгач, Алып Бәргән атын иярләде, этен чакырып алды да бая әби сөйләгән **бирәни** затны эзли чыгып китте*. Р. Батулла; *дөр.:* **бирән ...-ы/-е**, **туймас**; *к.* **мәгълүмати**.

**БИТЛӘ́Ү** *и.* Битләүгә, битләве, битләвенә, битләүләр; *ялг.:* **битләүе, битләүенә**. *Үзлегеннән өйрәнгән рәссам Ра Поллет соңгы 25 елын япа-ялгызы Нью-Мексико штатының төньягында урнашкан тау **битләүендә** искиткеч мәгарәләр ясауга багышлаган.* Сабантуй; *к.* **билбау**.

**БЛА́НКА** *и. ялг.* **бланка, бланкасы, бланкага, бланкалар**. *Менә монда кирәкле **бланкаларның** һәммәсе бар, пичәтләре дә сугылган.* Һ. Такташ. *«Дело» белән танышканлыгы турында махсус бланкага кул куйдырдылар*. М. Хәсәнов. *Бу эшне тормышка*

*ашыру барышында җирле совет органнары иптәш Хәйретдиновка һәрьяклап булышлык күрсәтергә тиеш. Үз күзләренә үзе ышанмыйча, Миңнулла командировка* ***бланкасына*** *язылган әлеге сүзләрне тагын бер кат укып чыкты*. В. Нуруллин; *дөр.:* **бланк, бланкы, бланкка, бланклар**; *к.* **страза**.

**БЛАНМАНЖЕ́** *и.* Бланманжега, бланманжесы, бланманжесына, бланманжелар; *ялг.:* **бланманжегә, бланманжесе, бланманжесенә, бланманжеләр**; *к.* **атташе**.

**БЛИЦИНТЕРВЬЮ́** *и.* Блицинтервьюга, блицинтервьюы, блицинтервьюына; *ялг.:* **блицинтервьюсы, блицинтервьюсына**; *к.* **авеню**.

**БОГА́У** *и.* Богауга, богавы, богавына, богаулар; *ялг.:* **богауы, богауына**. *Рәмис бик дөрес язгансың, парны чыгардык, әмма коллык* ***богауын*** *өзәргә, ауыл халкының көченнән вә аңыннан килерме соң?* Матбугат.ру; *к.* **билбау**.

**БОЗА́У** *и.* Бозауга, бозавы, бозавына, бозаулар; *ялг.:* **бозауы, бозауына**. *Барган идем шуңа бозауны юллап, самагун урынына ике шешә аракы бирәм, тик* ***бозауымны*** *кире бирегез дип.* З. Зәйнуллин. *Әлбәттә, булган сөтнең күпмесендер* ***бозауына*** *эчерергә яисә сөт җыючыга тапшырырга мөмкин*. А. Гыйльми. *Сыерыбыз бар, танабыз, быелгы* ***бозауыбыз*** *бар*. Л. Таналин; *к.* **билбау**.

**БОЗЛЫ́К** *и.* Котыптагы яки таулардагы зур боз массасы. *Әмма күп кенә мәктәп спорт мәйданчыкларында хоккей уйнау өчен* ***бозлыклар*** *булдырылмады*. Татарстан яшьләре.

Бу мәгънәдә ***боз мәйданчыгы***, ***шугалак***, ***каток*** сүзләре кулланылырга тиеш.

**БОМБОУБЕ́ЖИЩЕ** *и.* Бомбоубежищега, бомбоубежищесы, бомбоубежищесына, бомбоубежищелар; *ялг.:* **бомбоубежищегә, бомбоубежищесе, бомбоубежищесенә, бомбоубежищеләр**; *к.* **атташе**.

**БОРА́У** *и.* Борауга, боравы, боравына, бораулар; *ялг.:* **бораушы, бораушна**; *к.* **билбау**.

**БӨРКӘ́Ү** *и.* Бөркәүгә, бөркәве, бөркәвенә, бөркәүләр; *ялг.:* **бөркәүе, бөркәүенә**; *к.* **билбау**.

**БӨТИ́** *и.* Бөтигә, бөтие, бөтиенә; *ялг.:* **бөтисе, бөтисенә**; *к.* **әби**.

**БРИ́ДЖИ** *и.* Бриджига, бриджие, бриджиена, бриджилар; *ялг.:* **бриджисы, бриджисына, бриджигә, бриджисе, бриджисенә, бриджиләр**; *к.* **бигуди**; *к. ш. ук* **шорты**.

**БРОНЬ** *и.* Броньга, броне, бронена, броньнар; *ялг.:* **броньгә, броненә, броньнәр**. *Ә син, Солтаньяр Заһитович, ул* ***броньнән*** *оялма, кирәксез кешегә бирмиләр аны.* З. Мурсиев. *Аны, тракторист булганы өчен, бронь биреп, менә бер ел инде хәрби хезмәттән азат итеп торалар иде. Кәшфи бу хәләттән риза иде,* ***броньне*** *юккабарга, килде-киттегә генә бирмиләр*. Казан утлары. *Виза алганнан соң кайбер туристлар кунакханә һәм авиабилет* ***броньнәрен*** *алдыра яисә датасын үзгәртә.* Кызыл таң. *Кемгә ничек ярагандыр, анысын белмим, әмма ул фронтка бармады – сугыш беткәнче* ***броньдә*** *утырды*. Кызыл таң; *к.* **пристань**.

**БРОШЬ** *и.* Брошька, броше, брошена, брошьлар; *ялг.:* **брошькә, брошенә, брошьләр**; *к.* **повесть**.

**БУ́БИ** *и.* Бубига, бубие, бубиена, бубилар; *ялг.:* **бубисы, бубисына, бубигә, бубисе, бубисенә, бубиләр**; *к.* **бигуди**; *к. ш. ук* **шорты**.

**БУКЛЕ́** *и.* Буклега, буклесы, буклесына, буклелар; *ялг.:* **буклегә, буклесе, буклесенә, буклеләр**; *к.* **атташе**.

**БУМАЗИ́** *и.* Бумазига, бумазие, бумазиена, бумазилар; *ялг.:* **бумазисы, бумазисына, бумазигә, бумазисе, бумазисенә, бумазиләр**; *к.* **бигуди**.

**БУССО́ЛЬ** *и.* Буссольгә, буссоле, буссоленә, буссольләр; *ялг.:* **буссольга**, **буссолена, буссольлар**. – *Ничек инде ул алай! – дип, Степанишин* ***буссольга*** *килепябышты.* И. Хуҗин. – *Хәзер, туган, тикшереп карыйбыз, – дип, Равил приборны яңа салынган юл буенча борды һәм,* ***буссольның*** *угына карап, – шулай булыр дип уйлаган идем аны, – диде.* И. Хуҗин; *к.* **апрель**.

**БУ́ТСЫ** *и.* Бутсыга, бутсые, бутсыена, бутсылар; *ялг.:* **бутс, бутсысы, бутсысына, бутслар, бутсалар**. *Уен кырыннан пычрак алып кермәс өчен, керә торган урында* ***бутсларны*** *юу өчен махсус югычлар куелган*. Шәһри Казан. *Европа чемпионаты тәмамлангач, бер спорт киеме компаниясе иң яхшы бомбардирларга эксклюзив* ***бутсалар*** *эшләргә тәкъдим итте*. Сабантуй; *к.* **шорты**.

**БУ́ШЕЛЬ** *и.* Бушельгә, бушеле, бушеленә, бушельләр; *ялг.:* **бушельга, бушелена, бушельлар**; *к.* **апрель**.

**БУЫНТЫ́КАЯКЛЫЛАР** *и. күпл. зоол. ялг.* Умырткасыз хайваннар тибы. *Алар арасында бигрәк тә --- дүртнурлы мәрҗәннәр, җилкәаяклылар, инәтирелеләр, мүкчәләр, түшаяклы һәм башаяклы моллюсклар, төрле төрдәге* ***буынтыкаяклылар*** *зур үсеш*

*алалар*. Фән һәм тел. *Бу хәйлә **буынтыкаяклыларда**, сөйрәлүчеләр һәм амфибияләрдә киң таралган, ә менә имезүчеләр арасында бу алымга сумкалы опоссумнар һәм янутлар гына өйрәнгән*. «Гыйлем» проекты; *дөр.:* **буынтыгаяклылар**; *к.* **ишекалды**.

**БУЯ́У** *и.* Буяуга, буявы, буявына, буяулар; *ялг.:* **буяуы, буяуына**. *Хәреф урынына асылташлар Тезә-тезә килә язасы. Бу җиһанның чиксез төс-**буяуы** Сеңә барсын язган юлларга*. Ф. Дәүләтгәрәева. *Өстемдә – әти-әни иләп имән каерысының кызыл **буяуына** манылган тиредән тегелгән тун* ---. Туганайлар. *Авыру кичкә кадәр аякларын гәзит **буяуыннан** юып маташкан*. «Азатлык радиосы» сайты; *к.* **билбау**.

**БЮДЖЕТЛАШТЫРУ́** *ф. ялг. – Бездә һәр муниципаль берәмлекне **бюджетлаштыру** исәпләнгән, – диде Татарстан Президенты*. Татарстан; *дөр.:* **бюджетка кертү, бюджетка салу, бюджетта карау; бюджет исәбенә тоту, бюджеттан финанслау** һ.б.ш.; *к.* **стимуллаштыру**.

**БЮЛЛЕТЕ́НЬ** *и.* Бюллетеньга, бюллетене, бюллетенена, бюллетеньнар; *ялг.:* **бюллетеньгә, бюллетененә, бюллетеньнәр**. *Әлфия апа, син шушы илле ел гомер буена бирәр тапкыр, тамагым авырта дигән булып, **бюллетеньгә** чыкканың булдымы?* Р. Батулла. ***Бюллетеньдә** бер генә кандидат*. М. Маликова. *Сайлау участогына бара идек тә, **бюллетеньне** ачып та карамыйча, кызыл әрҗәгә салып кына җибәрә идек*. Ә. Еники. *Иртә белән Әминә барлык күрсәткечләрне ярыш **бюллетененә** тутыра һәм **бюллетеньнәрне** һәр агрегатка җитәрлек итеп машинада бастыра*. Р. Зарипов; *к.* **пристань**.

**ВАДИ́** *и.* Вадига, вадие, вадиена; *ялг.:* **вадисы, вадисына**; *к.* **көрси**.

**ВАЗИФАИ́** *с. ялг. Ул дәүләт оешмасындагы **вазифаи** түрәнең шәхси эшмәкәрлек белән шөгыльләнүе, аңа өстенлекләр бирүе, ташламалар ясавын да РФ Җинаять кодексының 289 нчы маддәсе кысаларына эләгүен искә алыр*. Безнең гәҗит. ***Вазифаи** җинаять кылган өчен төрле дәрәҗәдәге җитәкчеләр хөкем ителде, хөкем карарлары законлы көченә керде*. Биектау. ***Вазифаи** затларга штраф күләме 2000 сумнан – 5000 сумга, ә юридик затларга 20 меңнән – 50 мең сумга кадәр*. Безнең Чирмешән. *Шулай да эш судка бары җитә, хөкем ителүче **вазифаи** вәкаләтләрен усал нияттә кулланган дип табыла*. Безнең гәҗит; *дөр.:* **дәүләт**

**хезмәтендәге, дәүләт оешмасында хезмәт иткән**; **башкарган вазифа белән бәйле**; *к.* **мәгълүмати**.

**ВАЛИ́** *и.* Валигә, валие, валиләр; *ялг.:* **валисе, валисенә**. *Бер шәһәр **валисенең** хозурына угрылык төһмәте белән ике кешене тотып китерделәр.* К. Насыйри; *к.* **көрси**.

**ВАНИ́ЛЬ** *и.* Ванильгә, ваниле, ваниленә, ванильләр; *ялг.:* **ванильга, ванилена, ванильлар**; *к.* **апрель**.

**ВАРЕ́НЬЕ** *и.* Вареньега, вареньесы, вареньесына, вареньелар; *ялг.:* **вареньегә, вареньесе, вареньесенә, вареньеләр**. *Әллә кай арада пешереп өлгергән кура җиләге берлән чия, җиләк **вареньеләре** китереп чәйгә утыртты.* Г. Исхакый. *Разиянын өе үзенең зур көзгеләре, кыйммәтле йомшак урындыклары, мең төрле ут белән уйнап янган зур люстралары, кыйммәтле паласлары, киң яфраклы көньяк гөлләре белән ничаклы хәйран итсә, өстәлдәге майлар, баллар, **вареньеләр**, кечкенә бәлешләр, алмалар, әфлисуннар, яңа гына табадан чыгып килгән пәрәмәчләр аның ашау дәртен кайнаттылар.* Г. Ибраһимов; *к.* **ателье**.

**ВАРЬЕТЕ́** *и.* Варьетега, варьетесы, варьетесына, варьетелар; *ялг.:* **варьетегә, варьетесе, варьетесенә, варьететеләр**; *к.* **атташе**.

**ВӘЛИ́** *и.* Вәлигә, вәлие, вәлиенә, вәлиләр; *ялг.:* **вәлисе**, **вәлисенә**. *Сабикъ Айдин вилаяте **вәлисе** Җәлал бәк; почта вә телеграф назыйры.* Г. Камал. *Бу аятьтә хатын-кызларга әйтми, чөнки беренче мәртәбә кияүгә чыккан кызларны вәли, атасы яки абыйсы бирә. Һәм менә бу Аллаһының әмере кыз кешегә түгел, ә аның **вәлисенә**, атасына яки абыйсына, кызларыгызны мөшрик һәм динсез егетләргә бирмәгез, ди!* Дога китабы; *к.* **көрси**.

**ВӘХИ́** *и.* Вәхигә, вәхие, вәхиенә, вәхиләр; *ялг.:* **вәхисе**, **вәхисенә**; *к.* **көрси**.

**ВЕ́ДОМОСТЬ** *и.* Ведомостька, ведомосте, ведомостена, ведомостьлар; *ялг.:* **ведомостькә**, **ведомостенә, ведомостьләр**. *Чек алу өчен, **ведомостьне** кассага алып барырга кирәк икән.* Д. Булатова. *Егет **ведомостькә** кул куеп акча алды да санап карады – монда ике шешәгә дә җитми бит.* Ф. Хәбибуллин. *Ахырда хезмәткәрләрнең бухгалтерия **ведомостендә** язылган хезмәт хакларын шушы төбәктәге яшәү минимумы белән чагыштыралар.* Татарстан яшьләре; *к.* **повесть**.

**ВЕ́КСЕЛЬ** *и.* Вексельгә, векселе, векселенә, вексельләр; *ялг.:* **вексельга, векселена, вексельлар**; *к.* **апрель**.

**ВЕ́НЗЕЛЬ** *и.* Вензельгә, вензеле, вензеленә, вензельләр; *ялг.:* **вензельга, вензелена, вензельлар**; *к.* **апрель**.

**ВЕ́НТИЛЬ** *и.* Вентильгә, вентиле, вентиленә, вентильләр; *ялг.:* **вентильга, вентилена, вентильлар**; *к.* **апрель**.

**ВЕРМИШЕ́ЛЬ** *и.* Вермишельгә, вермишеле, вермишеленә, вермишельләр; *ялг.:* **вермишельга, вермишелена, вермишельлар**; *к.* **апрель**.

**ВЕРФЬ** *и.* Верфькә, верфе, верфенә, верфьләр; *ялг.:* **верфька, верфена, верфьлар**. ***Верфьта*** *эшләнеп бетмәгән линкор корпусы тора иде*. Ә. Галиев. *Петр I Воронеж каласында диңгез кораблары төзү өчен бик зур* ***верфьлар*** *оештырган*. З. Зәйнуллин.

**ВЕСТИБЮ́ЛЬ** *и.* Вестибюльгә, вестибюле, вестибюленә, вестибюльләр; *ялг.:* **вестибюльга, вестибюлена, вестибюльлар**. *Хәзерге вакытта төзүчеләр* ***вестибюльда*** *эшлиләр, тоннельләрдә рельс юлларын сыныйлар*. Казан мэриясенең рәсми порталы; *к.* **апрель**.

**ВЕ́ЧЕ** *и.* Вечега, вечесы, вечесына, вечелар; *ялг.*: **вечегә, вечесе, вечесенә, вечеләр**; *к.* **атташе**.

**ВИГО́НЬ** *и.* Вигоньга, вигоне, вигонена, вигоньнар; *ялг.:* **вигоньгә, вигоненә, вигоньнәр**; *к.* **пристань**.

**ВИДЕОКАФЕ́** *и.* Видеокафега, видеокафесы, видеокафесына, видеокафелар; *ялг.:* **видеокафегә; видеокафесе; видеокафесенә, видеокафеләр**; *к.* **атташе***; к. ш. ук* **фото-альбом**.

**ВИОЛОНЧЕ́ЛЬ** *и.* Виолончельгә, виолончеле, виолончеленә, виолончельләр; *ялг.:* **виолончельга, виолончелена, виолончельлар**; *к.* **апрель**.

**ВИОЛОНЧЕЛЬЧЕ́** *и.* Виолончельчегә, виолончельчесе, виолончельчесенә, виолончельчеләр; *ялг.:* **виолончельчы, виолончельчысы**, **виолончельчысына, виолончельчылар**. *Минем СССР-ның халык артистлары – опера җырчысы Галина Вишневская һәм аның ире* ***виолончельчы****, дирижер Мстислав Ростропович (мәрхүм инде) кебек дөньяга танылган ышанычлы танышларым бар.* Ватаным Татарстан. *Аның сүзләренчә, быел, дүртьеллык конкурс циклының беренчесендә, пианистлар, скрипкачылар,* ***виолончельчылар*** *һәм вокалчылар (соло) ярыша ---*. Татар-информ; *к.* **апрель**.

**ВИ́СКИ** *и.* Вискига, виские, вискиена, вискилар; *ялг.:* **вискисы, вискисына, вискигә, вискисе, вискисенә, вискиләр**. – ***Вискине*** *шул килеш кенә эчәсезме, әллә су кушып китерергәме?* – *ди*. Мәдәни җомга; *к.* **бигуди**.

**ВИЦЕ-КОРО́ЛЬ** *и.* Вице-корольгә, вице-короле, вице-короленә, вице-корольләр; *ялг.:* **вице-корольга, вице-королена, вице-корольлар**; *к.* **апрель**.

**ВИЦЕ-ПРЕДСЕДА́ТЕЛЬ** *и.* Вице-председательгә, вице-председателе, вице-председателенә, вице-председательләр; *ялг.:* **вице-председательга, вице-председателена, вице-председательлар**; *к.* **апрель**.

**ВЛАСТЬ** *и.* Властька, власте, властена, властьлар; *ялг.:* **властькә, властенә, властьләр**. *Әйе, совет* ***властенә*** *нәфрәт аның канында бар.* Р. Батулла. *Алар Совет* ***властенең*** *милли сәясәтеннән татарлар, гомумән барлык мөселманнар өчен азатлык яулауны максат иткәннәр.* Фән һәм тел. *Совет* ***властенә*** *каршы көрәшкән хәрбиләрнең, сәясәтчеләрнең эшенә икенче күзлектән карый башладылар хәзер.* Татарстан яшьләре; *к.* **повесть**.

**ВОДЕВИ́ЛЬ** *и.* Водевильгә, водевиле, водевиленә, водевильләр; *ялг.:* **водевильгә, водевилена, водевильлар**. *Бу спектакльдә* ***водевильга*** *хас җиңеллек, шул ук вакытта драматик финал да бар.* 2013 Универсиадасы блогы; *к.* **апрель**.

**ВОКА́Л** *и.* Җыр сәнгате; *ялг.:* **вокал ансамбль, вокал дуэт, вокал сәнгать**. «***Вокал ансамбльләр***» *номинациясендә кече төркемдә чыгыш ясаучылар булмады.* Ютазы таңнары. *Мөрәледән Халидә Газизова («Әйткән идең»), Кыснадан Рәшит Шәвәлиевнең «Илкәем», Шушмабаштан Нурия Һадиеваның «Ике аккош»,* ***вокал дуэт*** *(Фирая Батыршина, Әнисә Хәтмиева) --- башкаруындагы җырларга өлкәннәрнең үткән гомере, яшьлеге, күңел дәрьясындагы шатлык-куанычлары, сагыш-моңнары сыйган.* Татар-информ. *Ул район һәм республика күләмендә «****Вокал сәнгать****», «Авторлык һәм бард җырлары», «Хореографик сәнгать», «Театр сәнгате» номинацияләрендә уза.* Кайбыч таңнары; *чаг.:* **вокаль**.

**ВОКА́ЛЬ** *с.* Җырга, җырлауга бәйле: **вокаль ансамбль, вокаль дуэт, вокаль сәнгать**; *чаг.:* **вокал**.

**Вокал/вокаль** тибындагы сүзләр, беренчедән, төрле сүз төркемнәренә карый, икенчедән, ясалыш ысулы төрле – беренчесе әзер килеш алынган, икенчесе русчадан алынган **вокальный** сүзенең кушымчасы кыскарып ясалган, өченчедән, җөмләдә **вокал** – ия яки тәмамлык, **вокаль** – аергыч функциясен үти. **Вокал** исемен аергыч функциясендә куллану өчен, ул изафә тезмәсендә булырга тиеш: **вокал сәнгате** – *ис.* + *ис.*; **вокаль сәнгать** сүзтезмәсендә – *сф.* + *ис.*

Күп очракта кушымчаларның алгы һәм арткы рәт вариантларын ялгаганда җибәрелгән ялгышлар татар телендә тартыкларның палаталь һәм веляр вариантлары арасындагы аерманың бик аз булуына бәйле (*к*. Татар грамматикасы, Т. I, 2015: 47 б.).

**ВО́ЛОСТЬ** *и.* Волостька, волосте, волостена, волостьлар; *ялг.:* **волостькә, волостенә, волостьләр**. *Ата-бабаларыгыз яшәгән торак пункты кайсы губерна, өяз,* ***волостькә*** *каравын ачыклагач, архив чыганакларына мөрәҗәгать итәргә мөмкин*. Кызыл таң. *Шунда менә шул* ***волостькә*** *бер фельдшер булган, күбесенчә теге имче, өшкерүче, дини картлар-карчыклар дәвалаганнар халыкны*. Татар электрон китапханәсе; *к.* **повесть**.

**ВОССТА́НИЕ** *и.* Восстаниегә, восстаниесе, восстаниесенә, восстаниеләр; *ялг.:* **восстаниега, восстаниесы, восстаниесына, восстаниелар**. *Нәкъ менә Батырша күтәрелеше (****восстаниесы****) 1755 елда ул вакытта бик көчле, татар-мөселманнарны чукындыру эшләрен туктата, ислам динен, милләтебезне юкка чыгарудан саклап калу мөмкинлеге бирә!* Татар әдипләре; *к.* **звание**.

**ВОССТА́НИЯ** *и. ялг. Ямашевның революцион эшчәнлегенең иң нык тамыр җәйгән вакыты Казандагы 1905 елгы октябрь вакыйгаларына һәм Казан эшчеләренең октябрь стачкасы бастырылганнан соң киң колач белән кораллы* ***восстаниягә*** *хәзерлек барган көннәргә туры килә ---*. Р. Зарипова; *дөр.:* **восстание**; *к.* **предприятия**.

**ВУА́ЛЬ** *и.* Вуальгә, вуале, вуаленә, вуальләр; *ялг.:* **вуальга, вуалена, вуальлар**; *к.* **апрель**.

**ВУЛЬГАРЧЫЛЫ́К** *и. ялг. Шул рәвешле, халык мәкальләрен ликвидацияләүгә чакырулар Марр теориясе нигезендә аерым «сыйнфый» сүзләр эзләп, шуларга бәйләнү,* ***вульгарчылык****, схематизм һәм шул ук феодализм чорының калдыгы булган догмачылык, нәкылчелек, тәкълитчелек булып, бу чирләр белән, мәкальләрдән бигрәк, ул иптәшләр үзләре чирләгән булулары аңлашыла*. Н. Исәнбәт; *дөр.:* **вульгарлык**; *к.* **каллиграфчы**.

**ГА́ВАНЬ** *и.* Гаваньга, гаване, гаванена, гаваньнар; *ялг.:* **гаваньгә, гаваненә, гаваньнәр**. *Алар фантастик бер* ***гаваньдә*** *бөялеп калган, мәңге шушында бер-берсенә терәлешеп таркалырга хөкем ителгән нindидер гарип корабларны хәтерләтәләр иде*. Р. Зәйдулла. *1628 елның 10 августында «Васа» паруслы корабы Стокгольм* ***гаваненда*** *беренче рейсы вакытында су төбенә китә.*

Татарстан яшьләре. *2013 елда Бөтендөнья җәйге универсиада алдыннан һава **гаванен** яңадан үзгәртәләр*. Кама ягы; *к.* **пристань**.

**ГАЗЕ́ТА** *и. вар. Беркөнне ул, **газеталарны** укыгач, бик озак нидер исәпләде.* А. Алиш. ***Газетаның** үз хәбәрчесе булып эшләгән елларымда бер зур түрәдән интервью алдым*. А. Хәсәнов. *Бу хакта күптән түгел **газетада** язганнар иде.* А. Тимергалин.

Кайбер алынмалар татар теле тарафыннан өлешчә үзләштерелеп, ***котлет, резин, фанер*** кебек сүзләрдә сүз ахырында ***-а*** сузыгы апокопа кичереп төшеп кала. Бу әдәби тел өчен норма булып санала. Аларны чыганак телдәгечә тулы язылышта куллану стилистик вариант булып тора.

**ГАЗИ́** *и.* Газига, газие, газиена, газилар; *ялг.:* **газигә**, **газиенә, газиләр; газисы**, **газисына**. *Тик берзаманны аның хәле бетә башлады. **Газиләр** аны яу кырыннан читкә алып чыкты*. В. Имамов; *к.* **көрси**.

**ГАЗЛАШТЫРУ́** *ф. ялг. **Газлаштыру** документларын эшләткәч, тиешле бәясен илтеп түләгәч, чиратым килеп җиткәнче көттерсәләр-көттерсеннәр, әмма җилеккә үтмичә генә зәңгәр ягулыкка мичемне-плитәмне тоташтырып китсеннәр иде*. Ф. Яхин. *Авылны **газлаштыру** бара, беренче чират октябрь аена билгеләнгән, түләве 50гә – 50 процент*. М. Миначев. – *Теләсәгез нәрсә эшләгез, әмма бәяне шуннан да арттырмагыз, – диде ул илне **газлаштыру** мәсьәләсенә багышланган җыелышта губернаторларга*. Татарстан яшьләре; *дөр.:* **газ кертү**; *к.* **стимуллаштыру**.

**ГАЗЛАШТЫРЫЛУ́** *ф. ялг. Шушы чорда районның барлык авылларына заманча юллар, елгалар аша тимер-бетон күперләр төзелде, район тулысынча **газлаштырылды**, социаль-мәдәни объектларның киң челтәре барлыкка килде.* Г. Мөхәммәтшин. *Авылыбыз бер ел арасында газлаштырылды*. Гасырлар авазы. *Бүген Татарстан авылларының 95,1 проценты **газлаштырылды***. Татарстан яшьләре; *дөр.:* **газ кертелү**; *к.* **стимуллаштыру**.

**ГАЛИФЕ́** *и.* Галифега, галифесы, галифесына, галифелар; *ялг.:* **галифегә, галифесе, галифесенә, галифеләр**. *Аның өстендә яңа тегелгән күк сукнодан френч, **галифесе**, матур гына туфлиләр белән кара, тезенә кадәр күтәреп кигән оеклары, дөрестән дә, аны комиссарларга охшатып тора*. Һ. Такташ. *Тегеләй-болай гына түгел, бер орден, дүртләп медальне бик яхшы офицерский френчкә тагып, билне яссы, ике эләктермәле офицер каешы белән буып,*

*бик яхшы хром итекләр, кызыл кантлы зәңгәр* ***галифеләр****, союзниклар армиясе офицерлары кия торган яшькелт соры кыйммәтле шинельләр киеп кайтты*. М. Мәһдиев. *Артист* ***галифенең*** *ни икәнен аңлатыр өчен кесәләрен әйләндереп күрсәтергә мәҗбүр була*. Р. Батулла; *к.* **атташе**.

Сүзнең фонетик яктан үзләштерелгән варианты ***гәләфи*** сүзендә сузыклар алгы рәт булганга, кушымчаларның да алгы рәт варианты ялгана; *к.* **туфли**.

**ГАЛЛ** *и.* Галлга, галлы, галлына, галлар; *ялг.:* **галы, галына**, **галллар**; *к.* **металл**.

**ГАЛУ́ШКИ** *и.* Галушкига, галушкие, галушкиена, галушкилар; *ялг.:* **галушкасы, галушкисына, галушкигә, галушкисе, галушкисенә, галушкиләр**; *к.* **бигуди**; *к. ш. ук* **шорты**.

**ГАНТЕ́ЛЬ** *и.* Гантельгә, гантеле, гантеленә, гантельләр; *ялг.:* **гантельга, гантелена, гантельлар**. *Бер башын стенадагы ыргакка эләктереп куйган ике генә пружиналы эспандрны уң кулы белән үзенә тарткалады, бер килограммлы* ***гантельны*** *учына кысып, хәрәкәтләр ясады.* Казан утлары; *к.* **апрель**.

**ГАСТРО́ЛЬ** *и.* Гастрольгә, гастроле, гастроленә, гастрольләр; *ялг.:* **гастрольга, гастролена, гастрольлар**. *Без ул елны Ташкентка* ***гастрольга*** *барган идек*. Р. Батулла. *Менә артистлар* ***гастрольга*** *чыгалар, әмма барасы урынын үзләре сайлап, алдан сөйләшеп, теләк белдереп куялар.* Татар заманы. *Г. Камал исемендәге Татар дәүләт академия театры исеменнән тәбрик итәргә килгән Хәлим Җәләй, моннан 5 ел элек Бохараевның «Тимер борчак» әсәре белән 10 көн Лондонда* ***гастрольда*** *булып кайткан идек, нишләптер, тагын Лондонга барасы килә, тагын пьеса язсын әле, дип коллектив һәм җитәкчелек әйтеп җибәрде диде.* Татар-информ; *к.* **апрель**.

**ГА́У** *и.* Гауга, гавы, гавына, гаулар; *ялг.:* **гауы, гауына**; *к.* **билбау**.

**ГӘЛӘФИ́** *и.* Гәләфигә, гәләфие, гәләфиенә; *ялг.:* **гәләфисе, гәләфисенә**.

Татар теле тарафыннан тулысынча үзләштерелгән көнчыгыш, көнбатыш һәм рус алынмаларында да, татар сүзләрендәге кебек, нигездәге алгы рәт сузыкларына ияреп, тартым кушымчасының ***-е*** варианты һәм башка алгы рәт кушымчалары ялгана; *к. ш. ук* **әби**; *чаг.:* **көрси**.

**ГЕЛЬ** *и.* Гельгә, геле, геленә, гельләр; *ялг.:* **гельга, гелена, гельлар**. *Өстәвенә кремны-****гельмы*** *балаларда аллергия ките-*

*реп чыгарды: тәннәрендә бөрчек-бөрчек кызыл таплар барлыкка килде.* Татарстан яшьләре. *Әмма зэклар вакланып тормаганнар – **гельны** эчкәннәр.* Татарстан яшьләре; *к.* **апрель**.

**ГЕНЕРА́Л** *и.* Югары хәрби дәрәҗә; *ялг.:* **генерал план, генерал идея**. *Шәһәрнең **генерал планы** буенча биредә юллар челтәрен үстерү, Ленин дамбасын һәм йөзмә күперне төзекләндерү каралган.* «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе сайты. ***Генерал планда** шулай ук экологик шартлар тудыруга игътибар бирелгән.* «Азатлык радиосы» сайты; *чаг.:* **генераль**; *к.* **вокаль**.

**ГЕНЕРА́ЛЬ** *с.* Төп, гомуми: **генераль план, генераль идея**; *чаг.:* **генерал**; *к.* **вокаль**.

**ГЕНЕРИРЛӘ́У** *ф. ялг. Р. Миңнеханов белдергәнчә, сәнәгатьтә кулланучылар өчен электр энергиясенә бәяләрнең нык үсүе энергетика ресурсларын челтәрдән сатып алуга караганда предприятиеләрнең үзләренең **генерирлау** җиһазларын төзүенең отышлырак булуына китерде.* Ватаным Татарстан. *Шунысын да искәртик, 4 майда «Татэнерго» һәм «Урыссу ГРЭСы» территориаль **генерирлау** компаниясе арасында инвестицион меморандумга кул куелган иде.* Татар-информ; *дөр.:* **генерацияләү, эшләп чыгару, тудыру** һ.б.; *к.* **реагирлау**.

**ГЕО-СӘЯСИ́** *с. ялг. Чөнки һәркемгә мәгълүм, глобальләштерү дигәндә, хәзерге дөнья белән идарә итүчеләр төрки дөньяның берләшүен, **гео-сәяси** дөньяда аның үзенә лаек урынын биләвен һич тә күздә тотмый.* «Азатлык радиосы» сайты; *дөр.:* **геосәяси**; *к.* **фото-альбом**.

**ГЕТРЫ** *и.* Гетрыга, гетрые, гетрыена, гетрылар; *ялг.:* **гетрысы, гетрысына, гетра, гетрасына, гетралар, гетрлар**. --- *залга юнгштурм костюмы – өстенә күн тужурка, аягына **гетрлар** кигән Фатих Хөсни килеп керде дә ишек төбендә тукталып калды.* Казан утлары. *Үземә һәм кызыма – шарф, башлык, бияләйләр, улыма – свитер, **гетра**, оекбаш-бияләйләр бәйләдем.* Туган як; *к.* **шорты**.

**ГИБРИ́Д** *и.* Гибридка, гибриды, гибридына, гибридлар; *ялг.:* **гибритка, гибриты, гибритына, гибритлар**. *Өйдә үстерү өчен иртә өлгерә торган, үзлегеннән серкәләнүче сорт һәм **гибритлар** кулай.* Акчарлак.

Рус һәм рус теле аркылы кергән алынмаларның сүз азагындагы **[д]** авазы, сөйләмдә саңгыраулашу кичерсә дә, язылышын үзгәртми,

парадигмасының барлык формаларында ***-д*** аркылы языла. Ялгыш язылу очраклары кайбер гарәп алынмаларындагы саңгыраулашу күренеше белән ялган аналогия нигезендә барлыкка килә. Әйтелештәге саңгыраулашуны чагылдыру өчен кушымчаларның саңгырау варианты ялгана. Шул ук закончалык ***-г*** (гонг, гонгы, гонгына), ***-б*** (клуб, клубы, клубка) хәрефләренең язылышына да кагыла.

**ГИД** *и*. Гидка, гиды, гидына, гидлар; *ялг.:* **гитка, гиты, гитына, гитлар**; *к*. **гибрид**.

**ГИДРИ́Д** *и*. Гидридка, гидриды, гидридына, гидридлар; *ялг.:* **гидридта, гидриты, гидритына, гидритлар**; *к*. **гибрид**.

**ГЛАЗУ́РЬ** *и.* Глазурьга, глазуре, глазурена, глазурьлар; *ялг.:* **глазурьгә, глазуренә, глазурьләр**; *к.* **лагерь**.

**ГОЛЛА́НД** *и*. Голландка, голланды, голландына, голландлар; *ялг.:* **голлантка, голланты, голлантына, голлантлар**; *к*. **гибрид**.

**ГО́ЛЬФЫ** *и*. Гольфыга, гольфые, гольфыена, гольфылар; *ялг.:* **гольфа, гольфасы, гольфасына, гольфалар**. *Мин аякка ак **гольфа,** кулга ак перчаткалар киям*. Р. Сәгъди. *Кыз кроссовкаларын да салып тормыйча керпе янына кереп басты, аның йомры тез астына чаклы тартылган ак **гольфасына** су сеңде*. Камил Кәримов. *Әнә кәүсәсе дә нәкъ аның көрән **гольфысын** хәтерләтә*. Казан утлары; *к*. **шорты**

**ГОМУМЕВРО́ПА** *с. ялг. Төрле тарихи, менталь һәм икътисади сәбәпләр аркасында безнең республика да бу зур **гомумевропа** җирлегенең бер өлеше булып тора.* И. Габидуллин. *Алда әйтелеп үткәнчә, Г. Девишев **гомумевропа** театр сәнгатенең реалистик традицияләрендә тәрбияләнгән режиссер буларак, күбрәк чит ил һәм рус драматургиясе әсәрләрен сәхнәләштерә*. Гасырлар авазы. *Әгәр Россия 2010 елдан башлап **гомумевропа** мәгариф системасына аяк басарга тели икән (бу теләк рәсми рәвештә белдерелгән һәм килешүгә кул куелган), бу лицейлар шул эшнең авангарды булып тора.* Ватаным Татарстан; *дөр.:* **гомумъевропа**.

**ГО́СПИТАЛЬ** *и.* Госпитальгә, госпитале, госпиталенә, госпитальләр; *ялг.:* **госпитальга, госпиталена, госпитальлар**. ***Госпитальда*** *ятканда полковник Риза Ишморатка «За взятие Берлина» медале бирә*. Р. Батулла. *Зәңгәр экраннардан күреп, яратып үз иткәннәр салдылар мине Ватан сугышы ветераннарының **госпиталена***. Ислам – татарлар һәм мөселманнар. *Бер айлар чамасы узгачтын гына, инде **госпитальдан** терелеп чыккач кына Прищепага хат килеп төшә ---*. Р. Мөхәммәдиев; *к.* **апрель**.

**ГОФРЕ́** *и.* Гофрега, гофресы, гофресына, гофрелар; *ялг.:* **гофрегә, гофресе, гофресенә, гофреләр**; *к.* **атташе**.

**ГӨРҖИ́** *и.* Гөрҗигә, гөрҗие, гөрҗиенә; *ялг.:* **гөрҗисе, гөрҗисенә**; *к.* **әби**.

**ГӨРЗИ́** *и.* Гөрзигә, гөрзие, гөрзиенә, гөрзиләр; *ялг.:* **гөрзисе, гөрзисенә**. *Шуларның балаларының тырышлыгы аркасында гына бүгенге көндә милләтемез, милли барлыгымызга каршы җәһәннәм зобаниларының **гөрзисе** (чукмары) берлә коралланган большевикларга каршы да милли барлыгымызны саклап киләмез.* Г. Исхакый. *Нәнкир аның кабыргасына **гөрзисе** белән төртә.* Р. Батулла. *Менә кем икән ул Сак белән Сокны аерып торучы! – дип Алып Бәргән **гөрзисен** алып, фил каршысына басты*. Р. Батулла; *к.* **көрси**.

**ГРАДУИРЛА́У** *ф. ялг.* ***Термометрны градуирлау; кешелекнең үсеш этапларын градуирлау***; *дөр.:* **градация ясау, градация үткәрү, градацияләү, градуировка ясау**; *к.* **реагирлау**.

**ГРАЖДАНИ́** *с. ялг. Физик затның **граждани** хокукын сәләте аның шәхси законы белән билгеләнә.* Гаилә кодексы. *Үз шәхси законы буенча **граждани** хокуктан файдалану сәләтенә ия булмаган физик зат, --- үзенең хокуктан файдалану сәләте булмавын сәбәп итәргә хокуклы түгел ---*. Гаилә кодексы; *дөр.:* **гражданлык ...-ы/-е, граждан ...-ы/-е, гражданнар ...-ы/-е**; *к.* **мәгълүмати**.

**ГРАНД** *и.* Дворян; берәр өлкәдә иң танылган кеше; бөек, олы; *ялг.:* **гранд оту, яшь галимнәргә грандлар бирү**. --- ***гранд отып*** *алынган тракторны ягулык белән тәэмин итү һ.б. бик күп сорауларны яудырдылар гына борискинолылар*. Әлки хәбәрләре; *дөр.:* **грандка, гранды, грандына, грандлар**; *к.* **гибрид**; *чаг.* **грант**.

**ГРАН-ПРИ́** *и.* Гран-прига, гран-прие, гран-приена, гран-прилар; *ялг.:* **гран-присы, гран-присына, гран-пригә, гран-присе, гран-присенә, гран-приләр**. *Алар арасында традицион булган «Ел студенты» **Гран-присы**, «Ел спортсмены», «Ел чит ил студенты», «Елның иҗади шәхесе» кебекләре бар.* Белем.ру. *Татар матбугаты төркеменең **гран-присына** Әдилә Галимова лаек булды*. Матбугат.ру; *к.* **бигуди**.

**ГРАНТ** *и. ялг.:* **испан гранты, балет грантлары, грант-отель, грант-дама**; *дөр.:* **грантка, гранты, грантына, грантлар**; *чаг.* **гранд**.

**ГРАФФИ́ТИ** *и.* Граффитига, граффитие, граффитиена, граффитилар; *ялг.:* **граффитисы, граффитисына**, **граффитигә, граффитисе, граффитисенә, граффитиләр**; *к.* **бигуди**.

**ГРИЛЬ** *и.* Грильгә, гриле, грилена, грильләр; *ялг.:* **грильга, грилена, грильлар**. ***Грильда** яшелчә белән кыздырылган сөмбаш балыгы яки консервланган диңгез продуктлары һәм җиләк-җимеш белән әзерләнгән шашлыкларны күз алдына китергәч үк, авыз сулары килә*. Шәһри Казан; *к.* **апрель**.

**ГРИ́ФЕЛЬ** *и.* Грифельгә, грифеле, грифеленә, грифельләр; *ялг.:* **грифельга, грифелена, грифельлар**; *к.* **апрель**.

**ГУА́ШЬ** *и.* Гуашька, гуаше, гуашена, гуашьлар; *ялг.:* **гуашькә, гуашенә, гуашьләр**; *к.* **повесть**.

**ГУМАНО́ИД** *и.* Гуманоидка, гуманоиды, гуманоидына, гуманоидлар; *ялг.:* **гуманоитка, гуманоиты, гуманоитына, гуманоитлар**; *к.* **гибрид**.

**ГУ́ППИ** *и.* Гуппига, гуппие, гуппиена, гуппилар; *ялг.:* **гупписы, гупписына, гуппигә, гупписе, гупписенә, гуппиләр**; *к.* **бигуди**.

**ГУРА́МИ** *и.* Гурамига, гурамие, гурамиена, гурамилар; *ялг.:* **гурамисы, гурамисына, гурамигә, гурамисе, гурамисенә, гурамиләр**; *к.* **бигуди**.

**ДАВЫ́Л** *и.* Давылга, давылы, давылына, давыллар; *ялг.:* **дауылы, дауылына, дауыллар**; *к.* **билбау**.

**ДА́КТИЛЬ** *и.* Дактильгә, дактиле, дактиленә, дактильләр; *ялг.:* **дактильга, дактилена, дактильлар**; *к.* **апрель**.

**ДА́У** *и.* Дауга, давы, давына, даулар; *ялг.:* **дауы, дауына**; *к.* **билбау**.

**ДӘВЕ́Р** *и.* Дәвергә, дәвере, дәверенә, дәверләр; *ялг.:* **дәүере, дәүеренә, дәүерләр**; *к.* **билбау**.

**ДӘ́Ү ӘНИ** *и.* Дәү әнигә, дәү әнисе, дәү әнисенә; *ялг.:* **дәү әние, дәү әниенә**. *Кышкы каникуллар вакытында Дамир **дәү әниенә** махсус килде*. И. Хуҗин. *Музыкаль гаиләдә үсә – **дәү әние** бик матур җырлаган, әти-әниләре дә иҗатны яратканнар: әнисе җырлаган, әтисе баянда һәм гитарада уйнаган*. «Күрше» (web-сайт); *к.* **әби**.

**ДӘ́Ү ӘТИ** *и.* Дәү әтигә, дәү әтисе, дәү әтисенә; *ялг.:* **дәү әтие, дәү әтиенә**. *Шуңа күрә аның оныгы сайты өчен модельне таба алмагач, ул беришиксез **дәү әтиенә** шалтыраткан*. «Күрше» (web-сайт); *к.* **әби**.

**ДӘҮКӘДИ́** *и.* Дәүкәдигә, дәүкәдие, дәүкәдиенә; *ялг.:* **дәүкәдисе**, **дәүкәдисенә**; *к.* **көрси**.

**ДӘҮЛӘТИ́ 1.** *с. ялг. Димәк, Тукай бәйрәмнәренең иң зурысы, иң күркәме, **дәүләти** статус бирелеп, Җаекта да уздырылырга тиеш булып чыга түгелме соң?* Разил Вәлиев. ***Дәүләти** һәм шәхси автомәктәпләр арасында сез кимчелек таба алмаган бик яхшылары бармы?* Сабантуй. *РФ кануннары безгә сүз ирегенгарантияли, **дәүләти** һәм ирекле матбугатка бүлми*. Безнең гәҗит; *дөр.:* **дәүләт ...-ы/-е**; **дәүләткә караган, дәүләт карамагандагы, дәүләт дәрәҗәсендәге, дәүләт күләмендәге** һ.б.ш.; *к.* **мәгълүмати**.

**2.** *рәв. мәгъ. ялг. Билгеләнгән бурычларны чишүгә республика җитәкчелегенең **дәүләти** якын килүе күренеп тора*. Казан. Меңьеллык сәхифәсе. *Без татар телен **дәүләти** гамәлгә кую буенча Дәүләт программасы, тиешле Канун да кабул иттек*. Разил Вәлиев; *дөр.:* **дәүләтчә, дәүләт күләмендә, дәүләт мәнфәгатен күздә тотып** һ.б.ш.; *к.* **мәгълүмати**.

**ДӘҮЛӘТ-ХОКУКЫ́Й** *с. ялг. Шуңа бәйле рәвештә без ТР Президентының **Дәүләт-хокукый** департаменты белән хезмәттәшлек итәчәкбез*. Ватаным Татарстан. *Безнең парламент эшчәнлеге республикадагы дәүләт сәясәтенең төп юнәлешләрен гамәлгә ашыруга, аның **дәүләт-хокукый**, социаль-икътисади һәм рухи-мәдәни үсешен законнар белән тәэмин итүгә юнәлтелгән*. Кызыл таң; *дөр.:* **дәүләт-хокук ...-ы/-е, дәүләт һәм хокук ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ДВИ́ГАТЕЛЬ** *и.* Двигательгә, двигателе, двигателенә, двигательләр; *ялг.:* **двигательга, двигателена, двигательлар**. *Һәм реактив **двигательга** тиешле басым биреп бер үкертеп алгач, тимер рычагны үзенә таба тартты*. Р. Мөхәммәдиев; *к.* **апрель**.

**ДЕГИДРИРЛА́У** *ф. ялг. Органик кушылмалардан водород **дегидрирлау***; *дөр.:* **дегидрацияләү**; *к.* **реагирлау**.

**ДЕКА́БРЬ** *и.* Декабрьгә, декабре, декабренә, декабрьләр; *ялг.:* **декабрьга, декабрена, декабрьлар**. *Әйтик, агымдагы елның 23 ноябреннан 13 **декабрена** кадәр Азнакай шәһәрендәге санаторий-профилакторийга бушлайга путёвкалар бар*. Минзәлә. *1 октябрьдан башланып 31 **декабрьга** кадәр дәвам итәчәк көзге чакырылышта Татарстаннан 4 меңнән артык яшь кеше хәрби кием киячәк.* Татарстан яшьләре. ***Декабрьда** интернат мәктәптә укыган 35 баланы цирк бинасында үткәрелгән полиция Яңа ел

*чыршысына, 19 баланы «Щелкунчик» балетын карарга алып баруны оештырдылар, «Макдоналдс»тан бүләкләр бирделәр.* Арча хәбәрләре; *к.* **январь**.

**ДЕ́КЕЛЬ** *и.* Декельгә, декеле, декеленә, декельләр; *ялг.:* **декельга, декелена, декельлар**; *чаг.:* **апрель**.

**ДЕКОЛЬТЕ́** *и.* Декольтега, декольтесы, декольтесына, декольтелар; *ялг.:* **декольтегә, декольтесе, декольтесенә, декольтеләр**. *Ул килгәч, баллон онытылды, Илназ алдында* ***декольтесе*** *тулы күкрәкләрен, күз төшсә, оялырлык итеп ачкан күлмәктән дулкынлануын яшерә алмаган әсәренгән хатын гына калган иде.* Н. Көбәш. *Әйтегез әле, каештан чак кына киңрәк булган кыска итәкләр, кендекне ачып йөргән кыска топиклар, тирән* ***декольтеле*** *кичке күлмәкләр яки пляж бикинилары – болар барысы да татар киемнәреме әллә?* «Умма» информацион-аналитик порталы; *к.* **атташе**.

**ДЕМОКРАТЧЫЛЫ́К** *и. ялг. Ләкин бишенче елгы революция дулкыннары Тукайны иске мәдрәсә калыбыннан чыгаралар: Тукайда* ***демократчылык*** *карашлары үсә бара.* Габдулла Тукайга багышланган Интернет-портал; *дөр.:* **демократлык, демократ булу, демократизм, демократиялелек**; *к.* **каллиграфчы**.

**ДЕПОНИРЛА́У** *ф. ялг. Акчаны* ***депонирлау***; *дөр.:* **депонентка салу**; *к.* **реагирлау**.

**ДЕТА́ЛЬ** *и.* Детальгә, детале, деталенә, детальләр; *ялг.:* **детальга, деталена, детальлар**. *Романда бу* ***детальга*** *шактый еш игътибар ителә.* А. Садыйкова. *Автоинспекторлар бу автомобильдә утырып барган бер генә кеше дә куркынычсызлык каешын эләктермәгән булган, дип әһәмиятле* ***детальга*** *игътибарны юнәлтә.* Татар-информ; *к.* **апрель**.

**ДЕФИЛЕ́** *и.* Дефилега, дефилесы, дефилесына, дефилелар; *ялг.:* **дефилегә, дефилесе, дефилесенә, дефилеләр**. *– Сезгә нинди бурыч куелган иде? – Көнбатыш юнәлештә чигенү бурычы. – Туплану пункты? – Күлләр* ***дефилесендә****, моннан егерме километрда.* Г. Әпсәләмов. *Һәр нәрсә үз урынында булуын кызларның эчке киемнәр* ***дефилесендә*** *ачык күренде.* Ватаным Татарстан; *к.* **атташе**.

**ДЖАКУ́ЗИ** *и.* Джакузига, джакузие, джакузиена, джакузилар; *ялг.:* **джакузигә, джакузисе, джакузисенә, джакузисы, джакузисына, джакузиләр**; *к.* **бигуди**.

**ДЖЕРСИ́** *и.* Джерсига, джерсие, джерсиена, джерсилар; *ялг.:* **джерсисы, джерсисына, джерсигә, джерсисе, джерсисенә, джерсиләр**; *к.* **бигуди**.

**ДЖО́УЛЬ** *и.* Джоульгә, джоуле, джоуленә, джоульләр; *ялг.:* **джоульга, джоулена, джоульлар**; *к.* **апрель**.

**ДЖУ́НГЛИ** *и.* Джунглига, джунглие, джунглиена, джунглилар; *ялг.:* **джунглисы, джунглисына, джунглигә, джунглисе, джунглисенә, джунглиләр**. *Нәрсә, комбайнга бишек асып, уракка чыгарга суматра **джунглиләре** түгелдер бит монда?* А. Хәлим. *Димәк, кешелек җәмгыятендә яшәсә дә, бу зат үтә алмаслык **джунглидәге** «Маугли» дәрәҗәсеннән дә түбәнгә тәгәрәгән.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар; *к.* **бигуди**.

**ДИА́ГНОЗЛАУ** *ф. ялг.; дөр.:* **диагноз кую, диагнозын билгеләү, диагнозын ачыклау; диагностика ясау**; *к.* **стимуллаштыру**.

**ДИ́ЗЕЛЬ** *и.* Дизельгә, дизеле, дизеленә, дизельләр; *ялг.:* **дизельга, дизелена, дизельлар**; *к.* **апрель**.

**ДИО́Д** *и.* Диодка, диоды, диодына, диодлар; *ялг.:* **диотка, диоты, диотына, диотлар**; *к.* **гибрид**.

**ДИРИЖА́БЛЬ** *и.* Дирижабльгә, дирижабле, дирижабленә, дирижабльләр; *ялг.:* **дирижабльга, дирижаблена, дирижабльлар**. *6 июль – **дирижабльнең** беренче трансатлантик очышы*. Википедия; *к.* **апрель**.

**ДИСПА́НСЕРЛАШТЫРУ** *ф. ялг. Россиянең Гадәттән тыш хәлләр министры Сергей Шойгу балаларга елына ике тапкыр **диспансерлаштыру** үткәрергә тәкъдим итте.* Сабантуй. *Быелдан Россиядә мәҗбүри **диспансерлаштыру** (авыруларны ачыклау һәм алдан кисәтү максатыннан үткәрелгән медицина тикшерүләре) кертелде*. Шәһри Казан. *РФ Сәламәтлек саклау һәм социаль үсеш министрлыгы 2006–2008 еллардагы **диспансерлаштыру** кампаниясенә нәтиҗәләр ясады.* Татарстан яшьләре; *дөр.:* **диспансеризацияләү**, **диспансеризация үткәрү**; *к.* **стимуллаштыру**.

**ДИСПЕ́ТЧЕРЛАШТЫРУ** *ф. ялг. 2013 елда башланган котельныйларны **диспетчерлаштыру** агымдагы елда тәмамланырга тиеш*. Ютазы таңы. *Күп фатирлы йортларны **диспетчерлаштыру** киләсе адым булачак, бу реаль вакыт режимында районның рәсми сайтында коммуналь хезмәтләрнең сыйфатын тикшереп*

*барырга мөмкинлек бирәчәк.* Татар-информ. *Татарстанда шулай ук балаларны уку йортларына илтә торган мәктәп автобусларын* ***диспетчерлаштыру*** *гамәлгә кертелде.* «Рәсми Татарстан» порталы; *дөр.:* **диспетчеризацияләү**.

**ДИФФЕРЕ́НЦИЯЛӘҮ** *ф. ялг. Планнарны* ***дифференцияләү****; сатып алу бәяләрен* ***дифференцияләү****; дөр.:* **дифференциацияләү**; *к.* **реагирлау**.

**ДОКЛА́Д** *и.* Докладка, доклады, докладына, докладлар; *ялг.:* **доклатка, доклаты, доклатына, доклатлар**. *Шулай итеп, бәйрәм* ***доклатын*** *төгәлләтеп тә куйдылар.* Г. Галиева; *к.* **гибрид**.

**ДОНЕСЕ́НИЕ** *и.* Донесениегә, донесениесе, донесениесенә, донесениеләр; *ялг.:* **донесениега, донесениесы, донесениесына, донесениелар**. *Районның башында утыручы «зур әзиләр», кичен конспиратив квартирга җыелышып, резидент җибәргән яшерен* ***донесениены*** *укыганнар ---.* Җ. Юныс; *к.* **звание**.

**ДОНЕСЕ́НИЯ** *и. ялг. Госпитальдә үлгәннән соң,* ***донесениягә*** *карандаш белән язганнар, ә менә кайсы зиратка алып киткәннәре турында бернинди язуда да юк.* Безнең гәҗит; *дөр.:* **донесение**; *к.* **предприятия**.

**ДОСЬЕ́** *и.* Досьега, досьесы, досьесына, досьелар; *ялг.*: **досьегә, досьесе, досьесенә, досьеләр**; *к.* **ателье**.

**ДӨ́М-КАРА** *с. ялг. – Сез авыл халкы дигәч тә, аларны* ***дөм-кара*** *наданнар дип уйламагыз инде, – диде ул сак кына.* Х. Ширмән. *Миңа шунысы гына үкенеч: мәгърифәтсез,* ***дөм-кара*** *авыл муллалары гарәпчә «Исме агзам», «Әзкәрессала» кебек дини китаплар, догалыклар бастыралар.* Габдулла Тукайга багышланган Интернет-портал; *дөр.:* **дөм кара**; *к.* **чем-кара**.

**ДӨ́М-КАРАҢГЫ** *с. ялг. Ә ай юк, айның соңгы көннәре, тиз генә чыкмаячак, шуңа күрә төне дә* ***дөм-караңгы****.* Ә. Еники. *Шул гына: җир астындагы күк* ***дөм-караңгы****, ә кояш, йолдызлар капкара икән!* Г. Гыйльманов. *Бу дөнья аның өчен тумыштан ук* ***дөм-караңгы*** *булган дип һич уйламассың.* Р. Мөхәммәдиев; *дөр.:* **дөм караңгы**; *к.* **чем-кара**.

**ДӨ́М-СУКЫР** *с. ялг. Саба районы хакимияте башлыгы Рәис Миңнеханов Оет авылында япа-ялгыз гомер кичерүче,* ***дөм-сукыр*** *гармунчы Вәгыйзь Хафизовка өр-яңа тальян бүләк итте.* Татарстан яшьләре. *Ул бичара чәчәк авыруыннан* ***дөм-сукыр*** *кала.* Туганайлар; *дөр.:* **дөм сукыр**; *к.* **чем-кара**.

**ДӨРЕ́С** *с. ялг.:* **дөресерәк**. ***Дөресерәге,*** *ул алай ук кыйммәт булыр дип уйламаган, белгән булса, әлбәттә, җитәрлек алып килер иде...* Җ. Юныс. *Аллаһудан да* ***дөресерәк*** *сөйләүче бармы? Әлбәттә, юк!* Ф. Яхин. *Зилә Булатовна бөтенләй башка нәрсә турында,* ***дөресерәге,*** *--- үз чәчләрен нинди төскә кертәчәген, нинди фирма буяуын кулланачагын, нинди прическа һәм кемнән ясатачагын кузаллап, фикерләп утыру белән мәшгуль иде инде.* Л. Ибраһим-Вәлиди; *дөр.:* **дөресрәк**; *к.* **бай**.

**ДРЕЛЬ** *и.* Дрельгә, дреле, дреленә, дрельләр; *ялг.:* **дрельга, дрелена, дрельлар**; *к.* **апрель**.

**ДУХИ́** *и.* Духига, духие, духиена, духилар; *ялг.:* **духисы, духисына, духигә, духисе, духисенә, духиләр**; *к.* **бигуди**.

**ДУЭ́ЛЬ** *и.* Дуэльгә, дуэле, дуэленә, дуэльләр; *ялг.:* **дуэльга, дуэлена, дуэльлар**. *Ә инде Бөтен Рәсәй режиссёрларының 1 нче корылтаен татар кешесенә алып барырга бирү – патша сатрапларын ачыктан-ачык* ***дуэльга*** *чакыру сыман кабул итмичә мөмкин түгел*. Ә. Хәбибуллин. *Шуннан соң ул күп булса тугыз ай яши,* ***дуэльда*** *һәлак була.* Габдулла Тукайга багышланган Интернет-портал; *к.* **апрель**.

**ДУЭЛЬЧЕ́** *и.* Дуэльчегә, дуэльчесе, дуэльчесенә, дуэльләр; *ялг.:* **дуэльчыга, дуэльчысы, дуэльчысына, дуэльлар**. *Бу мәсьәлә өч* ***дуэльчының*** *каршылыгын күрсәтә һәм шул көрәштә көчсезнең җиңүен аңларга ярдәм итә*. Р. Һади; *к.* **апрель**.

**ДЮРА́ЛЬ** *и.* Дюральгә, дюрале, дюраленә, дюральләр; *ялг.:* **дюральга, дюралена, дюральлар**; *к.* **апрель**.

**ЕВРОВИ́ДЕНИЕ** *и.* Евровидениегә, Евровидениесе, Евровидениесенә, Евровидениеләр; *ялг.:* **Евровидениега, Евровидениесы, Евровидениесына, Евровидениелар**. *Шул ук атнада «Буран әбиләре»нең* ***Евровидениега*** *барасы билгеле булды һәм без үзебезнең Татарстаннан шундый әбиләрне эзләдек*. Безнең гәҗит. *Ул балалар* ***Евровидениесы-2013*** *конкурсында алган хис-кичерешләре белән уртаклашачак*. Татар-информ; *к.* **звание**.

**ЕВРОВИ́ДЕНИЯ** *и. ялг. Ә мин исә «Яңа ел* ***Евровидениясе»*** *оештырдым*. Ялкын; *дөр.:* **Евровидение**; *к.* **предприятия**.

**Е́ГЕРЬ** *и.* Егерьга, егере, егерена, егерьлар; *ялг.:* **егерьгә, егеренә, егерьләр**. *Җиде кешем белән бөтен бер взвод немец* ***егерьләрен*** *турап кайтканнан соң гына менә шул тәрене биргәннәр иде...* Т. Гыйззәт. *Яңадан исерек* ***егерьләр,*** *автоматлардан*

*ата-ата, аягүрә басып, атакага килделәр.* Г. Әпсәләмов. *Кузгалыр алдыннан Каратаев җирән мыеклы **егерьгә** шыпырт кына төртеп алды*. М. Галиев; *к.* **лагерь**.

**Е́РЕСЬ** *и.* Ереська, ересе, ересена, ересьлар; *ялг.:* ереськә, ересе, ересенә, ересьләр; *к.* **повесть**.

**ЖА́ЛОВАНЬЕ** *и.* Жалованьега, жалованьесы, жалованьесына, жалованьелар; *ялг.:* **жалованьегә, жалованьесе, жалованьесенә, жалованьеләр**. *Аның ала торган **жалованьесеннән** 30 процент бала тәрбиясенә бирергә хөкем иткәннәр һәм, суд кәгазен ярты елдан соң төшереп, бу иптәшнең **жалованьесеннән** 50 процент тотып кала башлаганнар.* Һ. Такташ. --- *Шура журналы редакторы Риза казыйга аена 130 сум бирә иде. Моны күпләр министрлар **жалованьесе** дип йөртә торганнар иде* ---. Л. Хәмидуллин; *к.* **ателье**.

**ЖАЛЮЗИ́** *и.* Жалюзига, жалюзие, жалюзиена, жалюзилар; *ялг.:* **жалюзисы, жалюзисына, жалюзигә, жалюзисе, жалюзисенә, жалюзиләр**. *Артык купшылыкны яратмаган кешеләр өчен, **жалюзине** хәтерләтүче, өстәмә бау белән күтәртеп куярга мөмкин булган, җыйнак пәрдәләр тәкъдим ителә.* Кәеф ничек?; *к.* **бигуди**.

**ЖЕНЬШЕ́НЬ** *и.* Женьшеньга, женьшенена, женьшеньнар; *ялг.:* **женьшеньгә, женьшене, женьшененә, женьшеньнәр**. *Аю мае бутап, сөт җылытып эчте, мәтрүшкәле-җиләкле чәй ясады, аю тамырын – **женьшеньне** – төнәтергә куйды.* Х. Ширмән. *Әлбәттә, урман-тауларында юлбарыслар яшәгән, «алтын тамыр» **женьшеньнәр** үскән Уссури төбәге табигый тыюлык булып санала.* Казан утлары; *к.* **пристань**.

**ЖЮРИ́** *и.* Жюрига, жюрие, жюриена, жюрилар; *ялг.:* **жюрисы, жюрисына, жюригә, жюрисе, жюрисенә, жюриләр**. *Байтак очракта **жюригә** төп үзенчәлекләрне, ярыш кагыйдәләрен, бигрәк тә татарча көрәшү кагыйдәләрен белеп җиткермәгән иптәшләр билгеләнә.* Х. Туфан. *Министрлыкның матбугат хезмәте белгече Алия Шарапова сүзләренчә, «XXI гасыр туризмы» дип аталган бәйгенең **жюриендә** татарлар да булган.* Н. Алан. *Чараның иң яхшы мәзәген сөйләүче исеменә «супер керәшен» такымы, **жюринең** махсус бүләгенә КАИ тулай торагы җыелма такымы – «Кара малай» лаек дип табылды*. Р. Шакир; *к.* **бигуди**.

**ҖАВАПЧЫЛЫ́К** *и. ялг. Шуңа да канәгатьлелек хисен түгел, ә халык алдында **җавапчылык** тойгысын күбрәк тоям.* Ватаным Татарстан. --- *Русия кануннары балаларны хәтәррәк җинаять өчен*

*дә җавапка тартмый, ә мөһим документ югалтучы өлкәннәргә, явыз нияте расланмаса, ачык авызлык күрсәткәненә күрә кырыс **җавапчылык** каралган!* Татарстан яшьләре; *дөр.:* **җаваплылык**; *к.* **каллиграфчы**.

**ҖАНДА́У** *и.* Җандауга, җандавы, җандавына, җандаулар; *ялг.:* җандауы, *к.* **билбау**.

**ҖАНИ́** *и.* Җанига, җание, җаниена, җанилар; *ялг.:* **җанигә, җаниенә, җанисенә, җанисы**, **җанисына**; *к.* **көрси**.

**ҖӘДИ́** *и.* Җәдигә, җәдие, җәдиенә, җәдиләр; *ялг.:* **җәдисе**, **җәдисенә**; *к.* **көрси**.

**ҖӘЙЛӘ́Ү** *и.* Җәйләүгә, җәйләве, җәйләвенә, җәйләүләр; *ялг.:* **җәйләүе, җәйләүенә**. *Чәршәмбе көнне Казанның «Сөләйман» мәчете каршында эшләүче мөселман **җәйләүеннән** кызлар елаша-елаша таралышты*. «Азатлык радиосы» сайты. *Быел да Биектау районының «Костёр» лагеренда гадәттәгечә «Дуслык» туган тел **җәйләүе** эшли*. Бөтендөнья татар конгрессы. *Русия төбәкләреннән һәм Татарстаннан 150 бала «Дуслык» **җәйләүендә** татарча өйрәнде*. «Азатлык радиосы» сайты; *к.* **билбау**.

**ҖӘМГЫЯВИ́** *с. ялг. Глобальләшү дәверендә, бер яктан, традицион диннәр экзотерик догматлардан арынып һәм кешелек эзотерик гыйлемлек үзләштерүгә яраклашкан **җәмгыяви** структура буларак үзгәреш кичерер дип фаразларга нигез бар.* Р. Сафин; *дөр.:* **иҗтимагый, социаль, җәмгыятьтәге, җәмгыятьтәге ...-ы/-е**; *к.* **мәгълүмати**.

**ҖӘ́Ү** *и.* Җәүгә, җәве, җәвенә, җәүләр; *ялг.:* **җәүе, җәүенә**; *к.* **билбау**.

**ҖӘҮҺӘРИ́** *с. ялг. Әлеге ханымнарда халкыбызның **җәүһәри**, мираси, мәгърифәти уңганлыгы, зыялылыгы буыннардан-буыннарга күчеп баруы милләтебезнең акыллы киләчәгенә олы ышаныч тудыра*. Ислам – татарлар һәм мөселманнар; *дөр.:* **җәүһәр кебек, җәүһәрдәй**; *к.* **мәгълүмати**.

**ҖЕТЕ́-ЗӘҢГӘР** *с. ялг. **Җете-зәңгәр** күк йөзендә әйләнә-тулгана, салмак кына дирижабль оча.* А. Толстой; *дөр.:* **җете зәңгәр**; *к.* **чем-кара**.

**ҖЕТЕ́-КЫЗЫЛ** *с. ялг. Мәхмүт хәзер генә соңгы вакытта үзендә булган кайбер үзгәрешләрнең сәбәбен аңлады: тылсымны бик тиз башкаруы да, тылсым нурының гел **җете-кызыл** булуы да менә ни өчен икән!* Ялкын. *Эре-эре, кан төсендәге **җете-***

***кызыл**, сагыш төсендәге сары чәчәкләр.* Шәһри Казан. *Аның баш өстендә күпереп аккан кан дәрьясын хәтерләткән **җете-кызыл** күк.* Әдипләр. Әхмәт Дусайлының шәхси порталы; *дөр.:* **җете кызыл**; *к.* **чем-кара**.

**ҖЕТЕ́-САРЫ** *с. ялг. Узган атнада ул **җете-сары** төстәге өряңа «Лада Калина» машинасына утырып, Себер якларында ике мең чакрым җилдереп кайтты.* Безнең гәҗит; *дөр.:* **җете сары**; *чаг.:* **чем-кара**.

**ҖЕТЕ́-ЯШЕЛ** *с. ялг. Беренче саф **җете-яшел** үләннәргә сөенеп баскыч төбендә бер утырып алды да яңадан тышка чыгаруны да сорамады.* Идел; *дөр.:* **җете яшел**; *к.* **чем-кара**.

**ҖИЗНИ́** *и.* Җизнигә, җизние, җизниенә; *ялг.:* **җизнисе, җизнисенә**. *1932 елның июнь аенда хатынны ике улым белән кайтарып җибәрдем. Качырып эшләнде бу эш. Нәдер авылына – **җизнисенә**.* Гасырлар авазы; *к.* **әби**.

**ҖИҢГӘЧИ́** *и.* Җиңгәчигә, җиңгәчие, җиңгәчиенә; *ялг.:* **җиңгәчисе, җиңгәчисенә**; *к.* **әби**.

**ҖИҢГИ́** *и.* Җиңгигә, җиңгие, җиңгиенә; *ялг.:* **җиңгисе, җиңгисенә**. *Шуны гына көткәндәй, **җиңгисе** аңа да чәй һәм абзыйсына танау корытырга ниндидер чуар чүпрәк кисәге дә кертте.* А. Хәлим; *к.* **әби**.

**ҖИҢЕ́Л** *с. ялг.:* **җиңелерәк**. *Ибн Фадлан белән Болгарга килгән сәүдәгәрләрнең берсе ханның улларының акылга **җиңелерәген** бозыклыкка алып керә.* М. Хәбибуллин. *Гашыйк ир-атка мондый билгесезлектә утыруга караганда дар агачы каршында басып тору **җиңелерәктер**, мөгаен.* А. Нәҗми. *Эш Казанга Верховный судка барып җиткәч, Нәгыймә апаның яшь баласы булуын исәпкә алып, җәзаны **җиңелерәккә**: 56 нчы статьяга күчергәннәр.* Р. Зарипов; *дөр.:* **җиңелрәк**; *к.* **бай**.

**ЗАДА́НИЕ** *и.* Заданиегә, заданиесе, заданиесенә, заданиеләр; *ялг.:* **заданиега, заданиесы, заданиесына, заданиелар**. *Кичә разведвзвод **заданиедан** үзенең тәҗрибәле ике разведчигын югалтып кайтты.* Г. Әпсәләмов. *Ә озак хат язмавының сәбәбе, аларның отряды ерак тайга эчендә яшерен хәрби **заданиеда** булганга күрә икән.* Безнең гәҗит; *к.* **звание**.

**ЗАДА́НИЯ** *и. ялг. Командаларга төрле **заданиялар** бирелә һәм алар аны күпмедер вакыт эчендә эшләргә тиеш булалар.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар; *дөр.:* **задание**; *к.* **предприятия**.

**ЗАЕЗД** *и.* Заездда, заезддан; *ялг.:* **заезда, заездан**. *Кызганычка каршы, беренче* ***заезда*** *ук ике багги трассадан төшеп калды һәм финишка җитә алмады*. Туган як. *Һәр* ***заездан*** *соң ипподром өстенә ат тояклары туздырган тузан белән бергә азарт һәм көндәшлек рухы да күтәрелде.* Авыл таңнары. *Бу* ***заезда*** *ике нәселле айгыр Гулахар һәм Дуплет арасында киеренкелек урнашты*. Татар-информ; *к.* **поезд**.

**ЗАКО́НЧАЛЫК** *и. ялг.* Законлылык, законлы булу, законга сыю. ***Закончалык*** *нигезендә комиссия составына шулай ук районның контроль-хисаплау палатасы рәисе дә керә*. Маяк; *дөр.:* **закон нигезендә, закон кысаларында, законга нигезләнеп, законлы рәвештә**; *чаг.:* **закончалы́к**.

**ЗАКОНЧАЛЫ́К** *и.* Билгеле эзлеклелек, кагыйдә; *чаг.:* **зако́нчалык**.

**ЗАМАНАВИ́ 1.** *с. ялг.; дөр.:* **заманча, хәзерге заман ...-ы/-е; заманыбыз ...-ы/-е**.

**2.** *рәв. мәгъ. ялг. Коръән гыйлеме бу күрсәтмәләрнең илаһи асылын ача, аларга* ***заманави*** *тәфсир кыла, иман савытын ныгыта*. Т. Әйди; *дөр.:* **заманча, заман күзлегеннән, заман таләпләрен истә тотып**; *к.* **мәгълүмати**.

**ЗАНЯ́ТИЕ** *и.* Занятиегә, занятиесе, занятиесенә, занятиеләр; *ялг.:* **занятиега, занятиесы, занятиесына, занятиелар**. *Шулпаны чүмереп бетерүгә, солдатларны, билдән кар ерып, алты чакрым ераклыкка мылтык, миномёт күтәртеп практик һәм тактик* ***занятиега*** *чаптырдылар*. Татар әдипләре. *Балалар, әйтегез әле, без сезнең белән үткән* ***занятиеда*** *нинди җыр өйрәнә башлаган идек әле?* Белем.ру; *к.* **звание**.

**ЗАНЯ́ТИЯ** *и. ялг.* ***Занятиядә*** *урман тулы солдат, ашарга көненә дүрт йөз грамм ипи белән өшегән бәрәңге шулпасы, җитмәсә анысы да тозсыз*. Татар әдипләре; *дөр.:* **заниятие**; *к.* **предприятия**.

**ЗАПЧА́СТЬ** *и.* Запчастька, запчасте, запчастена, запчастьлар; *ялг.:* **запчастькә, запчастенә, запчастьләр**. *Тугыз трактордан бишәү калды. Калганнарын* ***запчастькә*** *сүттеләр.* Казан утлары. *Балаларны* ***запчастькә*** *сату турындагы куркыныч фактлар Русиядә әледән әле калкып тора*. Татарстан яшьләре; *к.* **повесть**.

**ЗАЯВЛЕ́НИЕ** *и.* Заявлениегә, заявлениесе, заявлениесенә, заявлениеләр; *ялг.:* **заявлениега, заявлениесы, заявлениесына, заявлениелар**. *Безнең бер кандидат* ***заявлениесын*** *алган.*

Матбугат.ру. *Күп очракта «исковые **заявлениелар**» бик ялгыша!* Матбугат.ру; *к.* **звание**.

**ЗАЯВЛЕ́НИЯ** *и. ялг. Бүген Хисами кызы Зәйнәп, аксак Ибәй кызы Галия, теге Фатыйма камсамулга керергә **заявления** бирәләр.* Һ. Такташ; *дөр.:* **заявление**; *к.* **предприятия**.

**ЗӘВЫ́К** *и.* Зәвыкка, зәвыгы, зәвыгына, зәвыклар; *ялг.:* **зәүкка**, **зәүкы, зәүкына**, **зәүкъ, зәүклар, зәүкълар**. *Шигырьне һәркем үзенчә аңласын, ни өчен без укучының **зәүкына** килеп орынабыз, авторда булмаган нәрсәләрне казып чыгарабыз, авторда булганнарын күрмибез, күрмәмешкә салышабыз.* Р. Батулла. *Шуңар күрә Галиябану һәр сүз, һәр карашына кадәр тирән художество **зәүкы** белән эшләнгән сәхнә образы булып туа.* Н. Таждарова. *Шундый яхшы кыра, падиша йоклау гына түгел, төшендә бик **зәүкъ**-**сафалар** да күрә.* Татар әкиятләре.

Сүзнең **зәүкы** формасы иске дип санала һәм бары тик шигырьләрдә ритмга буйсындырып иҗек санын киметү йөзеннән яки стиль таләпләренә туры китерү өчен кулланыла: *Чәчкә төсле җырларымны җырламыйм **зәүкым** өчен ---.* Ш. Бабич. Хәзерге татар телендә традиция буенча сүз тулы вариантта төрләнә; *дөр.:* **зәвыкка, зәвыгы, зәвыгына**; *чаг.:* **милек**.

**ЗӘКЯ́Т** *и.* Зәкятка, зәкяты, зәкятына; *ялг.:* **зәкәткә, зәкәте, зәкәтенә**. *Иман, намаз, **зәкәт** кебек исламның төп нигезләре хакында Коръәннең күп изге аятьләрендә бәян ителә*. Безнең гәҗит. ***Зәкәт**, вакыф һәм ислам хокукында булган башка шартнамәләрне өйрәнәбез*. Татар заманы. *Артык маллары булганга хаҗ, гомрә кылалар, җиһадта катнашалар, **зәкәт** бирәләр.* Дога китабы.

**ЗӘНКИ́** *и.* Зәнкигә, зәнкие, зәнкиенә; *ялг.:* **зәнкисе**, **зәнкисенә**; *к.* **көрси**.

**ЗӘРКӘ́Н** *и. ялг. Чынлыгына ышану өчен **зәркән** булуның кирәге юк.* Т. Галиуллин. *Бу атнада Казан ярминкәсендә **зәркән** эшләнмәләр, алтын-көмеш күргәзмәсенә Русиянең иң зур ювелир ширкәтләре килгән иде*. Р. Вәли; *дөр.:* **зәргәр**.

**ЗӘРКӘНЧЕ́** *и. ялг. **Зәркәнчеләр** һәм бакырчылар искиткеч гүзәл бизәнү әйберләре үрнәкләре тудыралар*. Һ. Такташ. *Татар **зәркәнчеләренә** хас сәрке, каралтып бизәк төшерү алымнары белән таныштыру*. Р. Әхмәтҗанова; *дөр.:* **зәргәр**; *к.* **каллиграфчы**.

**ЗӘРКӘНЧЕЛЕ́К** *и. ялг. Алтын Урда чорында болгарларда әле монголларга кадәр үк барлыкка килгән һөнәрләрнең бар төр-*

*ләре дә үсешен дәвам итә: тимер кою, тимерчелек, бакыр кою, **зәркәнчелек**, чүлмәк ясау, пыяла әйберләр ясау, күн эшкәртү, туку, сөяк кисү, киез басу һ.б.* Б. Хәмидуллин. *Тимерчелек, **зәркәнчелек** һәм башка һөнәрләр камилләшә.* Казан ханлыгы халыклары; *дөр.:* **зәргәрчелек**; *к.* **каллиграфчы**.

**ЗӘХМӘТИ́** *с. ялг. Хәлим хәтер ташы астында чак-чак сулыш алып яткан аң-зиһене белән тоеп белә: бу – **зәхмәти** тамга һәм бу зәхмәткә аның үзенең дә турыдан-туры катнашы булырга тиеш.* Г. Гыйльманов. *Бу **зәхмәти** кешенең яктылыкка омтылу теләкләре юкка чыккан, ул – бары тик караңгылык томанында яшәүче берәү.* Ватаным Татарстан. *Билгеле булганча, әлеге **зәхмәти** имтиханнар хәзер һәр мәктәптә түген, бәлки аерым бер үзәкләрдә (имтихан кабул итү пункты) генә уздырыла.* Intertat.ru; *дөр.:* **зәхмәт ...-ы/-е**, **зәхмәтле**; *к.* **мәгълүмати**.

**ЗВА́НИЕ** *и.* Званиегә, званиесе, званиесенә, званиеләр; *ялг.:* **званиега, званиесы, званиесына, званиелар**. *Кабаланганда я рапорт биргәндә «подполковник» дип тулысынча әйтмиләр, әйтсәләр дә, **званиенең** баштагы иҗегә әллә ни колакка чалынмый.* С. Шәрипов. ***Званиены** кемгә бирәчәкләр?* Кәеф ничек?

***-ия*** гә беткән алынма сүзләргә һәрвакыт алгы рәт кушымчасы кушыла.

**ЗВА́НИЯ** *и. ялг. Ләкин мин диссертациясез, **званиясез**, кафедрасыз галим!* Р. Батулла; *дөр.:* **звание**; *к.* **предприятия**.

**ЗВОНА́РЬ** *и.* Звонарьга, звонаре, звонарена, звонарьлар; *ялг.:* **звонарьгә, звонаренә, звонарьләр**; *к.* **лагерь**.

**ЗОБАНИ́** *и.* Зобанига, зобание, зобаниена; *ялг.:* **зобанисы**, **зобанисына**; *к.* **көрси**.

**ЗО́МБИ** *и.* Зомбига, зомбие, зомбиена, зомбилар; *ялг.:* **зомбисы, зомбисына, зомбигә, зомбисе, зомбисенә, зомбиләр**; *к.* **бигуди**.

**ЗО́МБИЛӘШТЕРҮ** *ф. ялг. Заман музыкасы белән балаларны **зомбиләштерәләр**.* «Азатлык радиосы» сайты; *дөр.:* **зомбилаштыру**; *к.* **бигуди**.

**ИВАСИ́** *и.* Ивасига, ивасие, ивасиена, ивасилар; *ялг.:* **ивасисы, ивасисына, ивасигә, ивасие, ивасисенә**; *к.* **бигуди**.

**ИГУА́Н** *и. ялг. Анда дөнья фаунасының сирәк очрый торган төрләрен – **игуан**, тутый кошларны һ.б. күрергә мөмкин булачак.* «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе сайты. *«Казан ярминкәсе»ннән*

*җиткерүләренчә, күргәзмә экспозициясендә мәче яки эт кебек иң популяр йорт хайваннарыннан тыш, дөнья фаунасының сирәк очрый торган төрләрен – **игуаннар**, тутый кошлар һ.б. күрергә мөмкин*. Татар-информ; *дөр.:* **игуана**.

Язма тел аркылы кергән алынма сүзләр, ягъни XX гасырда кергән сүзләр язуда татар теленең орфографиясенә яраклашмый (сирәк чыгармалар булырга мөмкин). Терминнар беркайчан да яраклашмый. Ягъни авазлар төшеп калу яки өстәлү күзәтелми һәм язуда чагылмый.

**ИДЕА́Л** *и*. Югары максат, омтылышның, теләк һәм максатның иң югары ноктасы; *ялг.:* **идеал тәртип, идеал буй-сын**. *Шул кыска гына ике сәгатьлек дәрестән соң Генштабта карталарны алып бару **идеал** рәвештә үтәлә башлый*. З. Зәйнуллин. *Татар, башкорт, казакъ, үзбәк, таҗик фольклоры аны **идеал** патша итеп сурәтли*. И. Закирова. *Сораштыруларга ышансаң, илдәге күпчелек хатын-кыз аны бүген дә **идеал** ир дип саный*. Безнең гәҗит; *чаг.:* **идеаль**; *к.* **вокаль**.

**ИДЕА́ЛЬ** *с*. Хыялда гына яши торган; абстракт; камил, бик яхшы: **идеаль тәртип, идеаль буй-сын**; *чаг.:* **идеал**; *к.* **вокаль**.

**ИДЕЯ-ПОЛИ́ТИК** *с. ялг. Без әле ул чакта, Абай ага, царизмның **идея-политик** советнигы профессор һәм миссионер Николай Иванович Ильминскийның Казакъстандагы генерал губернаторга «Инородец мәгарифчеләре – Алтынсариннарны, Кунанбаевларны – үз кабыклары эчендә яшәтегез» дигән «киңәшләрен» белми идек*. Х. Туфан. *Китапның шактый өлешен 1905 ел революциясе чорында барлыкка килгән көндәлек татар матбугатын тикшерү, газета-журналларның **идея-политик** йөзен билгеләү, татар телендәге беренче большевистик газета «Урал»ны һәм татар большевикларының листовка һәм прокламацияләрен анализлау кебек мәсьәләләр алып тора*. Габдулла Тукайга багышланган Интернет-портал; *дөр.:* **идея-политика ...-ы/-е, идея һәм политика ...-ы/-е** яки **идея-сәясәт ...-ы/-е, идея һәм сәясәт ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ИДЕЯ-ПРОБЛЕМА́ТИК** *с. ялг. Нәтиҗә ясап әйтсәк, «Өйгә таба» повесте **идея-проблематик** яктан гаять үзенчәлекле*. З. Әхәтова; *дөр.:* **идея-проблематика ...-ы/-е, идея һәм проблематика ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ИДЕЯ-СӘНГА́ТЬЧӘ** *с. ялг. Әлеге әсәрнең **идея-сәнгатьчә** үзенчәлекләрен анализлауга автор тулы бер бүлек багышлый*.

Э. Галиева; *дөр.:* **идея-сәнгать ...-ы/-е, идея һәм сәнгать ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ИДЕЯ-СӘЯСИ́** *с. ялг. Бүгенге партияләрнең* ***идея-сәяси*** *көрәше күренми.* Ватаным Татарстан. *1908–1910 елларда Тукай татар прогрессив матбугатының авангардында барган «Яшен», «Ялт-йолт» журналларын гамәлгә куюда, үстерүдә, аларның* ***идея-сәяси*** *эчтәлеген күтәрүдә зур роль уйный.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар. *Ул илебездә вахабчыларның идея-сәяси караш-лары турында сөйләде.* Intertat.ru; *дөр.:* **идея-сәясәт ...-ы/-е, идея һәм сәясәт ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ИДЕЯ-ТӘРБИЯВИ́** *с. ялг. Әсәрнең* ***идея-тәрбияви*** *әһәмияте; поэманың* ***идея-тәрбияви*** *кыйммәте; дөр.:* **идея-тәрбия ...-ы/-е, идея һәм тәрбия ...-ы /-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ИДЕЯ-ТЕМА́ТИК** *с. ялг. Язучы мирасында аерым җитеш-сезлекләр, чор белән чикләнгән яклар да бар, әмма, гомумән, аның иҗаты һәм* ***идея-тематик****, һәм сәнгати яктан бәһаләп бетер-гесез бер хәзинә.* Х. Миңнегулов. *Мәҗит Гафуриның «Ана теле», Габдулла Тукайның «Туган тел» һәм Нажар Нәҗминең «Татар теле» шигырьләрендә* ***идея-тематик*** *яктан нинди уртаклык һәм аермалыклар бар?* Р. Илькина. *Халкыбыз язмышының төрле чор-дагы рухи сәхифәләре – данлы да, канлы да, бәхетле дә, моң-зарлы да битләре шагыйрь иҗатының* ***идея-тематик*** *эчтәлеген билге-ли.* Н. Насыйбуллина; *дөр.:* **идея-тематика ...-ы/-е, идея һәм тема-тика ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ИДЕЯ-ТЕОРЕ́ТИК** *с. ялг. Чөнки әсәр, татар әдәбияты өчен* ***идея-теоретик*** *база хезмәтен үтәп кенә калмыйча, бөтен бер иҗат юнәлешенә --- нигез сала.* Ә. Закирҗанов; *дөр.:* **идея-теория ...-ы/-е, идея һәм теория ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ИДЕЯ-ФӘЛСӘФИ́** *с. ялг. Хезмәтнең аерым бүлекләрендә чыганакларга һәм текст фактурасына, төп геройларга һәм* ***идея-фәлсәфи*** *проблематикага, шигъри тасвирлауга нисбәтле әлеге төрдәш ясаучы компонентларның чагылыш үзенчәлеге, функциясе, гомумән, әһәмияте җентекле һәм күпсанлы мисаллар ярдәмендә ачыклана.* Ә. Закирҗанов. *Шагыйрь әнкәйләр образы-на* ***идея-фәлсәфи*** *мәгънә йөкли, алар шигырьләрдә милләт анасы шәрехләрен ала.* С. Шәрипов; *дөр.:* **идея-фәлсәфә ...-ы/-е, идея һәм фәлсәфә ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ИДЕЯ-ХУДО́ЖЕСТВОЛЫ** *с. ялг. Элементлар* ***идея-художестволы****, образлы максатларга ярашлы рәвештә булмый. Хәтта документаль вакыйгаларны образлар дөньясы итеп чагылдырганда да язучы бик күп артык нәрсәләрне төшереп калдыра.* З. Нигъмәтуллин; *дөр.:* **идея-художество ...-ы/-е, идея һәм художество ...-ы/-е** яки **идея-сәнгать ...-ы/-е, идея һәм сәнгать ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ИДЕЯ-ЭСТЕ́ТИК** *с. ялг. Октябрь инкыйлабына кадәр язылган әсәрләр арасында* ***идея-эстетик*** *әһәмияте белән, жанрларны үзләштергәнлеге ягыннан «Беренче чәчәкләр» драмасы һәм «Назлы кияү» комедиясе аерылып тора.* А. Әхмәдуллин. *Кандалыйлар иҗаты аша турыдан-туры Акмуллага килеп тоташа торган күпгасырлы татар язма әдәбияты, күренекле мәгърифәтчеләребезнең* ***идея-эстетик*** *мирасы.* Х. Мәхмүтов. *Әлбәттә, шулай булса да, шагыйрь аның аша үз* ***идея-эстетик*** *карашларын уздыруны, теге яки бу әдәби уйланманы булдыра алганча чынлыкка ашыруны һәм халык тарафыннан тәңгәл кабул иттерүне дә күздә тота.* Р. Харрасова; *дөр.:* **идея-эстетика ...-ы/-е, идея һәм эстетика ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ИҖТИМАГЫЙ-КӨ́НКҮРЕШ** *и. ялг. Төрки-татар дөньясына диннең йогынтысы гаять көчле булуы сер түгел: ул хәтта фольклордан килгән традицияләрне үзгәртә, милли аңдагы мәҗүси элементларны гына түгел,* ***иҗтимагый-көнкүреш*** *белән бәйле карашларны да трансформацияли.* Казан (Идел буе) федераль университеты; *дөр.:* **иҗтимагый яшәеш -ы/-е, җәмгыять-көнкүреш -ы/-е, җәмгыять һәм көнкүреш -ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**И́ЗВЕСТЬ** *и.* Известька, известе, известена, известьлар; *ялг.:* **известькә, известенә, известьләр**. *Моллюскларның кабырчыгы* ***известьтән*** *һәм мөгезсыман матдәдән тора*. Биология. *Җир астыннан чыккан чишмә суында* ***известьтән*** *тыш без белмәгән тагын күп матдәләр бар*. Безнең гәҗит. *Апрель-май айларында, яфраклы, ылыслы һәм катнаш урманнарда,* ***известькә*** *бай уңдырышлы туфракта күренә башлый.* Википедия; *к.* **повесть**.

**ИЗЛОЖЕ́НИЕ** *и.* Изложениегә, изложениесе, изложениесенә, изложениеләр; *ялг.:* **изложениега, изложениесы, изложениесына, изложениелар**. *Кичләрен сочинение-****изложениелар*** *язып, тапкырлау таблицасын ятлап интегәсезме?* Сабантуй. *«Безнең*

*мәктәпләргә татар теле дәресләре эшкәртмәләренә, яңа инша һәм* ***изложениелар*** *җыентыкларына ихтыяҗ бар, әлбәттә», – ди укытучы*. Татар-информ; *к.* **звание**.

**ИЗЛОЖЕ́НИЯ** *и. ялг. Татарстанда* ***изложения*** *язу өчен 429 укучы теркәлгән.* Белем.ру; *дөр.:* **изложение**; *к.* **предпрития**.

**ИЛА́У** *и.* Илауга, илавы, илавына, илаулар; *ялг.:* **илауы, илауына**; *к.* **билбау**.

**ИЛАҺИЛАШТЫРУ́** *ф. ялг. Күрәсең, мондый сыйфатлар тәңрече әби-бабаларыбызның күчмә тормыш вакытында табигать кочагында яшәп, әлеге күренешләрне* ***илаһилаштыру*** *чорыннан ук тәрбияләнеп килгәндер.* Мәдәни җомга. *Аның Третьяков галереясындагы триптихында 1970 нче еллар ахырындагы техник үзгәрешләрне, индустрияне* ***илаһилаштыру*** *чагыла.* Р. Вәлиев. *Әгәр дә рәсем, сурәт кемне дә булса, нәрсәне дә булса* ***илаһилаштыру****, изгеләштерү, аңа аерым бер зур хөрмәт күрсәтү һәм, ахыр чиктә, табыну өчен ясала икән, бу үзеннән-үзе тыела.* Ялкын; *дөр.:* **илаһиләштерү**.

**ИМАМЧЫЛЫ́К** *и. ялг. Анда данлыклы имам Сәгъди хәзрәт Салихов* ***имамчылык*** *иткән.* iskesabai.ru; *дөр.:* **имамлык**; *к.* **каллиграфчы**.

**ИМИ́** *и.* Имигә, имие, имиенә; *ялг.:* **имисе, имисенә**; *к.* **әби**.

**ИМИНЧЕЛЕ́К** *и. ялг. Исән-сау кайттыңмы? Йөргән җирләреңдә* ***иминчелекме****?* Г. Ибраһимов. *– Агай-эне, тукта әле,* ***иминчелекме****?* Г. Гобәйдуллин; *дөр.:* **иминлек**; *к.* **каллиграфчы**; *к. ш. ук* **катлаулык**.

**ИНВАЛИ́Д** *и.* Инвалидка, инвалиды, инвалидына, инвалидлар; *ялг.:* **инвалитка, инвалиты, инвалитына, инвалитлар**. *Кемгә кирәге бар сукыр* ***инвалитның****?* Ф. Хөсни. *Барлык мәдәни чараларда уздырылып барыла ---: гөрләтеп әниләр бәйрәме,* ***инвалитлар*** *декадасын билгеләп үттеләр соңгы вакытта!* Матбугат.ру; *к.* **гибрид**.

**ИНВЕНТА́РЬ** *и.* Инвентарьга, инвентаре, инвентарена, инвентарьлар; *ялг.:* **инвентарьгә, инвентаренә, инвентарьләр**; *к.* **лагерь**.

**ИНЖЕНЮ́** *и.* Инженюга, инженюы, инженюына; *ялг.:* **инженюсы, инженюсына**; *к.* **авеню**.

**ИНТЕЛЛЕКТУА́Л** *и.* Акыл яки рухи хезмәт белән шөгыльләнүче кеше; югары интеллектка ия кеше; *ялг.:* **интеллектуал бәйге, интеллектуал көч, интеллектуал марафон**. *Ул узган якшәмбедә*

*Чуашстанның Татар Согыты авылында узган «Чуашстан мөселман яшьләренең **интеллектуал** бәйгесе» дип атала.* Татар заманы. *Академик Фуат Ганиев, телевизорда интервью биргәндә, Америка галимнәре исбатлаган аяныч нәтиҗәне сөйләде: әгәр бала үз ата-ана теленнән икенче бер телгә күчеп, үз ана телен белми калса, аның фикер йөртү һәм **интеллектуал** көче 4 тапкыр ким була икән*. Фән һәм тел. «***Интеллектуал** марафон» халыкара олимпиаданың 17 еллык тарихы бар*. «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе сайты; *чаг.:* **интеллектуаль**; *к.* **вокаль**.

**ИНТЕЛЛЕКТУА́ЛЬ** *с.* Акыл эшчәнлегенә бәйле; рухи: **интеллектуаль бәйге, интеллектуаль көч, интеллектуаль марафон**; *чаг.:* **интеллектуал**; *к.* **вокаль**.

**ИНТЕРВИ́ДЕНИЕ** *и.* Интервидениегә, интервидениесе, интервидениесенә, интервидениеләр; *ялг.:* **интервидениега, интервидениесы, интервидениесына, интервидениелар**; *к.* **звание**.

**ИНТЕРВИ́ДЕНИЯ** *и. ялг.; дөр.:* **интервидение**; *к.* **предпрития**.

**ИНТЕРВЬЮ́** *и.* Интервьюга, интервьюы, интервьюына; *ялг.:* **интервьюсы, интервьюсына**. *Җыры да, видеосы да, **интервьюсы** да, фотолары да бер урында, шушында ук сораулар да бирергә була*. Сабантуй. *Татарстан Дәүләт Советы рәисе Фәрит Мөхәммәтшин бер **интервьюсында** бүгенге пенсиянең аз булуына канәгатьсезлек белдерде*. Татарстан яшьләре. *«Бердәм Русия» партиясе турындагы **интервьюсыннан** соң Татарстанның беренче Президенты Минтимер Шәймиев аңа өстәмә аңлатмалар бирде.* Безнең гәҗит; *к.* **авеню**.

**ИНФОРМАЦИОН-АГАРТУ́** *с. ялг. Шул максаттан мөселман дин әһелләре социаль программалар, проектлар, **информацион-агарту** һәм хәйрия эшләрендә актив катнашырга тиеш*. Татарстан Республикасы Мөселманнарының Диния Нәзарәте; *дөр.:* **информацион агарту ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ИНФОРМАЦИОН-АНАЛИ́ТИКА** *с. ялг. Мөхәммәдиева Фәридә Вадутовна – **информацион-аналитика** бүлеге әйдәп баручы белгече*. 2013 Универсиадасы блогы; *дөр.:* **информация һәм аналитика ...-ы/-е, мәгълүмат һәм аналитика ...-ы/-е, информацион аналитика ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ИНФОРМАЦИОН-АҢЛАТУ́** *с. ялг. 15 октябрь көнне Россиядә һәм республикабызда пенсия фонды **информацион-аңлату***

*кампаниясен башлады.* Алга; *дөр.:* **информацион аңлату ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ИНФОРМАЦИОН-ИННОВА́ЦИЯ** *с. ялг. Минем бу илләрдә булганым юк, ләкин хәзерге* ***информацион-инновация*** *чорында яшәгәнлектән аларның хәлләре белән танышырга мөмкинлекләр зур.* Яшел үзән; *дөр.:* **информацион инновация ...-ы/-е, информацион-инновацион, информация һәм инновация ...-ы/-е, мәгълүмат һәм инновация ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ИНФОРМАЦИО́Н-ИСӘПЛӘҮ** *с. ялг. Информацион-исәпләү үзәге; информацион-исәпләү бүлеге; дөр.:* **информация һәм исәпләү ...-ы/-е, мәгълүмат һәм исәпләү ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ИНФОРМАЦИО́Н-ИСӘП-ХИСАП** *с. ялг. Аның сәбәбен* ***информацион-исәп-хисап*** *үзәге җитәкчесе Елена Измайлова аңлата.* Яшел Үзән; *дөр.:* **информация һәм исәпләү ...-ы/-е, мәгълүмат һәм исәпләү ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ИНФОРМАЦИО́Н-МӘГАРИФ** *с. ялг. Килешү үз чиратында --- яшьләр арасында наркотикларга каршы* ***информацион-мәгариф*** *оешмалары төзергә мөмкинчелек бирәчәк.* Татарстан Республикасы Мөселманнарының Диния Нәзарәте; *дөр.:* **мәгълүмат һәм белем бирү ...-ы/-е, мәгълүмат һәм агарту ...-ы/-е, информация һәм белем бирү ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ИНФОРМАЦИО́Н-МЕТОДИКА** *с. ялг. Семинарга урыннардагы* ***информацион-методика*** *үзәкләре җитәкчеләре һәм мәгариф идарәләренең (бүлекләре) башлангыч белем бирүгә җаваплы белгечләре --- чакырыла.* Казан мэриясенең рәсми порталы. *Ул «РОСНАНО» компаниясе тарафыннан табигыйфәнни цикл укытучылары,* ***информацион-методика*** *үзәкләре методистлары, олимпиадаларда җиңү яулаган сәләтле балалар өчен оештырыла.* Татар-информ; *дөр.:* **информацион-методик, информация-методика ...-ы/-е, информация һәм методика ...-ы/-е, мәгълүмат-методика ...-ы/-е, мәгълүмат һәм методика ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ИНФОРМАЦИО́Н-ТЕЛЕКОММУНИКАЦИЯ** *с. ялг. 2015 елның 1 сентябреннән «Россия Федерациясенең* ***информацион-телекоммуникация*** *челтәрләрендә шәхси мәгълүматларны эшкәртү тәртибенең төгәллеген тикшерү өлкәсендә кайбер закон*

*чыгару актларына үзгәрешләр кертү турындагы» закон үз көченә керде.* Татар-информ; *дөр.:* **информацион-телекоммуникацион, информация-телекоммуникация ...-ы/-е, мәгълүмат-телекоммуникация ...-ы/-е, мәгълүмат һәм телекоммуникация ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ИНФОРМАЦИО́Н-ТЕХНОЛОГИЯ** *с. ялг. Моннан тыш, Татарстанның* ***информацион-технология*** *һәм туризм куәте презентацияләнгән.* Татар-информ; *дөр.:* **информацион-технологик, информацион технологияләр ...-ы/-е, мәгълүмат технологияләре ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ИНФОРМАЦИО́Н-УКЫТУ** *с. ялг. Күптән түгел татар теленә дистанцион өйрәтү* ***информацион-укыту*** *проектын Республика Президенты Рөстәм Миңнехановка тәкъдим иттеләр.* Әлмәт таңнары; *дөр.:* **информацион укыту ...-ы/-е, информация һәм белем бирү ...-ы/-е, мәгълүмат һәм белем бирү ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ИНФОРМАЦИО́Н-ЭЗЛӘНҮ** *с. ялг. Санау методы --- гамәли бурычларын хәл итүгә булыша: рефератлар, библиография,* ***информацион-эзләнү*** *системаларын төзергә мөмкинлекләр бирә.* Ф. Сафиуллина; *дөр.:* **информацион эзләнү ...-ы/-е, информация эзләү ...-ы/-е, мәгълүмат эзләү ...-ы/-е, исәпләү-эзләү ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ИНФОРМАЦИО́Н-ЭЗЛӘҮ** *с. ялг. Телнең төрле функциональ, территориаль, хронологик, иҗтимагый һәм башка барлык вариантларын да чагылдырган мондый корпуслар лингвистика өлкәсендәге нәзари тикшеренүләр өчен дә, гамәли эшчәнлек өчен дә кыйммәтле чыганак, тәфсилле* ***информацион-эзләү*** *системалары ролен үти.* Фәнни Татарстан; *дөр.:* **информацион эзләнү ...-ы/-е, информация эзләү ...-ы/-е, мәгълүмат эзләү ...-ы/-е, исәпләү-эзләү ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ЙӨГӘНЛЕКЛӘ́Ү** *ф. ялг. Айгырны* ***йөгәнлекләү****; хисләрне* ***йөгәнлекләү****; тойгыларны* ***йөгәнлекләү****; дөр.:* **йөгәнләү**; *к.* **каллиграфчы**.

**ИПИ́** *и.* Ипигә, ипие, ипиен; *ялг.:* **иписе, иписенә**. *Торып юынды да,* ***иписе*** *беткәнен күргәч, машина белән генә магазинга барып килергә уйлады.* «ФАНТАТ Блогы – ФАНТАСТИКА Татарча». *Акча, өстәлендә* ***иписе****, телевизордан хоккей һәм футбол булсын!* Гыймрановларның сайты; *к.* **эби**.

**ИРНӘ́Ү** *и.* Ирнәүгә, ирнәве, ирнәвенә, ирнәүләр; *ялг.:* **ирнәүе, ирнәүенә**; *к.* **билбау**.

**ИСТРЕБИ́ТЕЛЬ** *и.* Истребительгә, истребителе, истребителенә, истребительләр; *ялг.:* **истребительга**, **истребителена, истребительлар**. *Байтак кына хезмәт иткәч Борисоглебсктагы авиаучилищега кереп летчик **истребительга** укып чыктым*. Р. Мөхәммәдиев; *к.* **апрель**.

**ИХЛАСИ́** *с. ялг. М. Мәһдиевнең шәхесе, иҗаты белән **ихласи** сокланып, мөкиббән китеп язылган мәкаләләр, чыгышлар күп булса да, һәммәсенә таянып, гомумиләштереп язылган китап әлегә язылмаган.* Казан утлары. *Сөембикә аңа күтәрелеп карады, елмаерга итте, иллә **ихласи** елмаю килеп чыкмады ---*. М. Хәбибуллин. *Һәркемнең шушы дөньяви берәмлекләрне **ихласи** хөрмәтләве кемнең кем булуын бик ачык күрсәтә.* Татарстанда мәгариф; *дөр.:* **ихлас, ихластан**; *к.* **мәгълүмати**.

**ИШЕ́КАЛДЫ** *и. ялг. Бу кисешкән юлларда һәм трамвай рельслары аша **ишекалды** юлларына керә торган урыннарда асфальт һәм резина җәю белән бәйле*. Шәһри Казан. *Соңгы елларда һаваларның үзгәрүе турында **ишекалдында** җыелып утыручы әбиләрдән башлап зур-зур сәясәтчеләргә кадәр күп итеп сөйләшәләр.* Матбугат.ру; *дөр.:* **ишегалды**.

Бергә язылган кайбер кушма сүзләрдә ике сузык яки сузык һәм сонор аваз арасында калган саңгырау тартык яңгыраулаша: ***ишЕкАлды – ишегалды****; чыгарма:* **халыкара**.

**ИШКӘ́КАЯКЛЫЛАР** *и. күпл. зоол. ялг*. Имезүче диңгез хайваннары отряды; *дөр.:* **ишкәгаяклылар**; *к.* **ишекалды**.

**ИЮ́ЛЬ** *и.* Июльгә, июле, июленә, июльләр; *ялг.:* **июльга, июлена, июльлар**. *Сасна авылында, шул ук елның 24 **июленда** Арча районының Кышкар авылында өлкән кешеләр белән очрашып, сөйләшеп, истә калган хатирәләрне җыялар*. Габдулла Тукайга багышланган Интернет-портал. *Конкурста катнашучылардан гаризаларны Татарстан Республикасының Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгы 1 **июльга** кадәр кабул итә*. Актаныш муниципаль районы сайты; *к.* **апрель**.

**ИЮ́НЬ** *и.* Июньгә, июне, июненә, июньнәр; *ялг.:* **июньга, июнена, июньнар**. *Шуңа күрә татарлар зыялылары 11 **июньда** ачылган урыс журналистлары конгрессына көнләшеп карыйлар*. Р. Вәли. *Ишавылда 9 **июньда** узачак «атлы» сабантуйга рәхим

*итегез!* Туган як. *Ул быел февраль аеннан алып* ***июньга*** *кадәр 12 кешедән торган инициативалы иҗат төркеме тарафыннан башкарылды*. Казан мэриясенең рәсми порталы; *к.* **пристань**.

**ИЯРЛЕКЛӘ́Ү** *ф. ялг. Атны* ***иярлекләү****; техниканы* ***иярлекләү****; дөр.:* **иярләү**; *к.* **террорчылык**.

**КАБАРЕ́** *и.* Кабарега, кабаресы, кабаресына, кабарелар; *ялг.:* **кабарегә, кабаресе, кабаресенә, кабареләр**; *к.* **атташе**.

**КА́БЕЛЬ** *и.* Кабельгә, кабеле, кабеленә, кабельләр; *ялг.:* **кабельга, кабелена, кабельлар**. *Кыңгыр эштә тотылган егет исә аяк терәп маташмый, ә* ***кабельны*** *яндырып, криминаль юл белән төсле металл «табучы» әшнәләренең кайда ничек эшләвен, сатуга металл әзерләвен сөйләп бирә*. Татар-информ. *Кулланышлар төрле: туклану тәэмин итүче җайланмаларда фильтр конденсаторлар белән бергә даими ток чыгышында чит гөжләүдән --- яки башка тайпылулардан арыныр өчен зур индуктивлык кәтүкләреннән алып, чыбык аша радио ешлыгындагы комачаулаудан сакланыр өчен* ***кабельга*** *сапланган тишелгән феррит шарчык яки торның кечкенә индуктивлыгына кадәр*. Википедия; *к.* **апрель**.

**КАБЕРНЕ́** *и.* Кабернега, кабернесы, кабернесына, кабернелар; *ялг.:* **кабернегә, кабернесе, кабернесенә, кабернеләр**; *к.* **атташе**.

**КАБЫ́КАШАРЛАР** *и. күпл. зоол. ялг.* Коңгызлар ассемьялыгы; *дөр.:* **кабыгашарлар**; *к.* **ишекалды**.

**КАВЕ́М** *и.* Кавемгә, кавеме, кавеменә, кавемнәр; *ялг.:* **кауымы, кауымына, каүеме, каүеменә, каүемнәр**. *Үземне Болгар дәүләтендә яшәгән төрки* ***каүемнәрнең*** *дәвамчысы буларак таныйм*. Безнең гәҗит. *Хәзерге вакытта төрки халыклар якынча 30 телдә сөйләшәләр, ә менә Алтын Урда телен алсак, шушы утыз төрки* ***кауым*** *– 3 тел, нигездә бере-беренә якын телдә сөйләшәчәкләр*. М. Миначев. *Монда язылганча Чин чигендә татарлар* ***каүеме*** *яшәгән*. Безнең гәҗит; *к.* **билбау**.

**КАВЫ́Н** *и.* Кавынга, кавыны, кавынына, кавыннар; *ялг.:* **кауыны, кауынына, кауыннар**. *Баллы-татлы ризыклардан соң әле карбыз,* ***кауын*** *да ашыйбыз*. Самара региональ «Дуслык» һәм Самара шәһәр «Ак бәхет» иҗади-иҗтимагый оешмаларының уртак сайты; *к.* **билбау**.

**КАВЫРСЫ́Н** *и.* Кавырсынга, кавырсыны, кавырсынына, кавырсыннар; *ялг.:* **кауырсыны, кауырсынына, кауырсыннар**. *--- иртән балыктан кайткач миңа анам, бар Казаннан Халимә*

*апаларга кунаклар килгән, Сания кызы белән, балык керт үзләренә диде дә кулыма балык белән кечкенә* ***кауырсын*** *чиләк бирде.* В. Ильясов; *к.* **билбау**.

**КАГА́У** *и.* Кагауга, кагавы, кагавына, кагаулар; *ялг.:* **кагауы, кагауына**; *к.* **билбау**.

**КАДРИ́ЛЬ** *и.* Кадрильгә, кадриле, кадриленә, кадрильләр; *ялг.:* **кадрильга**, **кадрилена, кадрильлар**; *к.* **апрель**.

**КАЕНСАРЛЫ́К** *и. ялг. Теге* ***каенсарлыкта*** *атлар көтәр идем.* Һ. Такташ; *дөр.:* **каенсар**; *к.* **каллиграфчы**.

**КАЗАКИ́** *и.* Казакига, казакие, казакиена; *ялг.:* **казакигә**, **казакисе, казакисенә**. *Үзе, бик тиз генә кәләпүшен алыштырып, яхшы* ***казакисен*** *киеп алды.* Г. Ибраһимов.

**КА́ЙСЫ-ДА БУЛСА** *а. ялг. – Әниең дөрес әйтә,* ***кайсы-да булса*** *уку йортына кереп булса яхшы булыр иде ул, – диде кыз, оялып кына*. Туган як; *дөр.:* **кайсы да булса**; *к.* **әллә-кайда**.

**КАЛАНХО́Э** *и*. Каланхоэга, каланхоэсы, каланхоэсына, каланхоэлар; *ялг.:* **каланхойга, каланхойлар, каланхое, каланхоена, каланхоелар, каланхоэгә, каланхоэсе, каланхоэсенә, каланхоэләр**; *к.* **алоэ**.

**КАЛЕНДА́РЬ** *и*. Календарьга, календаре, календарена, календарьлар; *ялг.:* **календарьгә, календаренә, календарьләр**; *к.* **лагерь**.

**КАЛЛИГРАФЧЫ́** *и. ялг.; дөр.:* **каллиграф**.

Һөнәр һәм һөнәр осталарын белдергән атамалар татар теленең үз җирлегендә ***-чы*** кушымчасы нигезендә ясалалар. Әмма чит телдән кергән бу төр атамаларның күпчелегенең нигезендә үк «шушы өлкә белгече», «шушы һөнәр остасы» мәгънәсе салынган була, шуңа күрә аларга өстәмә рәвештә ***-чы*** күрсәткече кушу урынсыз: *рәссам* «рәсем ясау остасы», *каллиграф* «матур язу остасы» һ.б.ш. Әлеге закончалык берәр эшчәнлек өлкәсе, характер үзенчәлеге, карашлар һ.б. абстракт төшенчәләрне белдергән сүзләр ясалышына да кагыла. *МөмкинЧЕлек, вульгарЧЫлык, сәүдәЧЕлек* һ.б. *МәҗбүриЯТлек, рентабельЛЕ, уңышЛЫКлар* һ.б. очраклардагы күрсәтелгән кушымчалар да урынсыз. Ләкин бу кушымчалар һәрвакыт ялгыш ялгана дигән сүз түгел. Һәр очракта сүз һәм форма ясагыч кушымчалар сүзнең мәгънәсеннән һәм кушымчаның мәгънәсеннән һәм функциясеннән чыгып ялганырга тиеш.

**КАЛЛИГРАФЧЫЛЫ́К** *и. ялг.; дөр.:* **каллиграфлык**; *к.* **каллиграфчы**.

**КАЛЬЦИНИРЛА́У** *ф. ялг. Акбур* ***кальцинирлау****. Сода* ***кальцинирлау****. Известьташны* ***кальцинирлау****; дөр.:* **кальцинация үткәрү, кальцинацияләү**; *к.* **реагирлау**.

**КАМВОЛЬЛЕ́** *и. ялг.* **-ле** кушымчасы исемнән сыйфат ясау өчен кушыла, ***камволь*** сүзе үзе дә сыйфат; *дөр.:* **камволь**; *к.* **каллиграфчы**.

**КАМИКА́ДЗЕ** *и.* Камикадзега, камикадзесы, камикадзесына, камикадзелар; *ялг.:* **камикадзегә, камикадзесе, камикадзесенә, камикадзеләр**. *Әйтүләренә караганда,* ***камикадзеләрнең*** *усал гамәле бик күп американнарны тирән тәшвишкә, шом халәтенә төшергән.* Р. Батулла; *к.* **атташе**.

**КАНАЛИЗА́ЦИЯЛӘҮ** *ф. ялг. Халыкара террор АКШка үзенең тышкы сәясәтен үткәрергә ярдәм итсә, Русиягә илнең эчке проблемаларын хәл итү өчен файдалы, чөнки, «барысы да чукынып бетсен, илдә тынычлык кына булсын» дип сөйләшә башладык бит инде. Социологлар моны «җәмгыятьтәге ризасызлыкны* ***канализацияләү****» дип атыйлар.* Татарстан яшьләре. *Кыскасы, шул чордагы андый җыеннарны оештырган милли хәрәкәт җитәкчелегенең стратегик максаты, халыктагы азатлыкка омтылышны, аның ихтыярын конкрет кысаларда* ***канализацияләү*** *булды ахры дигән шик калды.* Рөстәм Зарипов блогы; *дөр.:* **юнәлтү, борып җибәрү, ниндидер юнәлеш бирү**.

**КАНА́У** *и.* Канаунга, канавы, канавына, канаулар; *ялг.:* **канауы, канауына**. *Яңгыр һәм кар сулары агу өчен шәһәр эчендә казылган дренаж* ***канауы*** *да буалылар түккән чүп астында калган.* Байрак. *Йорт җирен су басудан саклау өчен* ***канауын*** *да үзе казый, башкасын да эшли, чөнки үз-үзеңне кайгырту авыл өчен гадәти.* Яшел Үзән; *к.* **билбау**.

**КАНДИ́** *и.* Кандига, кандие, кандиена; *ялг.:* **кандисы**, **кандисына**; *к.* **көрси**.

**КАНДИ́Л** *и.* Шәмдәл. Кандилгә, кандиле, кандиленә; *чаг.:* **кандиль**.

**КАНДИ́ЛЬ** *и.* Алмагач сорты. Кандильгә, кандиле, кандиленә, кандильләр; *ялг.:* **кандильга, кандилена, кандильлар**; *к.* **апрель**; *чаг.:* **кандил**.

**КАНИ́СТРА** *и. вар. Аны саклауны үз өстемә алам, – дип, су* ***канистрасын*** *үз янына куйды.* А. Хәсәнов. *Тәк, өч* ***канистра*** *бензин, чыбыркыңны әзерлә.* Т. Галиуллин. *– Алар кайда да шундый! –*

*диде егет, кабинасыннан бушлат капланган* ***канистра*** *чыгарып.* Ф. Яхин; *к.* **газета**.

**КАНИФО́ЛЬ** *и.* Канифольгә, канифоле, канифоленә, канифольләр; *ялг.:* **канифольга, канифолена, канифольлар**; *к.* **апрель**.

**КАНО́Э** *и.* Каноэга, каноэсы, каноэсына, каноэлар; *ялг.:* **канойга, канойлар, каное, каноена, каноелар, каноэгә, каноэсе, каноэсенә, каноэләр**. *Зәйнуллин исәнләшеп, вакланып тормады, сүзне* ***каноэләрдәге*** *күренешкә ризасызлык белдерүдән башлады ---.* Казан утлары; *к.* **алоэ**.

**КАНУНИ́** *с. ялг. Ул – ханбикә! Барча Казан җиренең* ***кануни*** *ханбикәсе!* М. Әмирханов. *Әдәбият белеме жанрларны* ***кануни*** *һәм* ***кануни*** *булмаганга аера.* Ф. Хәсәнова; *дөр.:* **канунлы, канунга туры килгән, канун нигезендәге, канунга нигезләнгән, законлы, законда каралган, законлы нигезе булган, легитим** һ.б.ш.; *к.* **мәгълүмати**.

**КАПИТА́Л** *и.* Акча, материаль байлык һ.б.ш.; *ялг.:* **капитал төзелеш, капитал чыгым, капитал хезмәт, капитал ремонт**. *Республика башлыгы Татарстанда җитештерелгән нефть химиясе продукциясен юл һәм* ***капитал*** *төзелештә тагын да киңрәк файдалану мәсьәләсенә багышланган түгәрәк өстәлдә дә катнашты.* «Азатлык радиосы» сайты. *Ул бик зур* ***капитал*** *чыгымнар сорый, алар озак еллардан соң гына үз-үзләрен аклый һәм кайтара.* Татарстан яшьләре. *Җамал Вәлидинең татар әдәби телен эшләү, үстерү, камилләштерү турындагы карашлары журнал мәкаләләрендә генә түгел, бәлки «Татар теленең грамматикасы», «Татар теленең тулы сүзлеге» кебек зур* ***капитал*** *хезмәтләрендә дә чагылыш тапкан.* Ш. Асылгәрәев. *Емелькинода яңа клуб төзелеше бара, Яңа Ибрай авыл мәдәният йортына* ***капитал*** *ремонт ясала.* Авыл таңнары; *чаг.:* **капиталь**; *к.* **вокаль**.

**КАПИТА́ЛЬ** *с.* Күләме һәм әһәмияте белән зур, мөһим; тулы зур масштаблы: **капиталь төзелеш, капиталь чыгым, капиталь хезмәт, капиталь ремонт**; *чаг.:* **капитал**; *к.* **вокаль**.

**КАПИТЕ́ЛЬ** *и.* Капительгә, капителе, капителенә, капительләр; *ялг.:* **капительга, капителена, капительлар**; *к.* **апрель**.

**КА́ПСЮЛЬ** *и.* Капсюльгә, капсюле, капсюленә, капсюльләр; *ялг.:* **капсюльга, капсюлена, капсюльлар**. *Үз вазифасын башкармаган бер бәләкәй* ***капсюльның*** *нинди аяныч нәтиҗәләр бирергә мөмкинлеген уйлап карагыз.* Балтач районы порталы; *к.* **апрель**.

**КАРА́-ЗӘҢГӘР** *с. ялг. Саргаеп, кибеп тарамышка әйләнгән, **кара-зәңгәр** тамырлары беленеп торган кул йөзе белән күзләрен сыпырып алды.* Д. Булатова; *дөр.:* **кара зәңгәр**; *к.* **ачык-кызыл**.

**КАРА́-КОҢГЫРТ** *с. ялг. Мәчет янында, алдынгы планда зур бер манара басып тора, үзе ниндидер сәер, **кара-коңгырт** төстә, өстән аскача кисәкләтеп язмалар теркәлгән гарәп хәрефләре белән*. М. Миначев. *Бәлки, аның биленә төшеп җиткән **кара-коңгырт** чәч толымнары күзгә чалынгандыр?* Л. Гыйззәтуллина; *дөр.:* **кара коңгырт**; *к.* **ачык-кызыл**.

**КАРА́-КӨРӘН** *с. ялг. Дегет – ул каты ягулыкны --- һава кертмичә җылыту нәтиҗәсендә барлыкка килүче **кара-көрән** төстәге куе беректергеч масса.* Төзү материаллары. *Күлмәксез-нисез кояш астында йөреп, аның тәне **кара-көрән** төскә кергән.* Г. Гыйльманов. *Күлмәксез-нисез кояш астында йөреп, аның тәне **кара-көрән** төскә кергән.* Ф. Вәлиев; *дөр.:* **кара көрән**; *к.* **ачык-кызыл**.

**КАРА-КУЧКЫ́Л** *с. ялг. Тау-тау ак болытлар куера килеп, салынкы **кара-кучкыл** яңгыр болытларына әверелделәр.* М. Галәү. *Егет эре ак тешләрен күрсәтеп елмайды, аның гарәпләргә охшаган **кара-кучкыл** озынча йөзе бердәм яктырып, мөлаемланып китте*. М. Маликова. *Еракта-еракта **кара-кучкыл** булып нидер күренеп тора.* Р. Батулла.

Бу төр сүзләр гомуми закончалыктан чыгарылма булып тора, чөнки яңа сүзләр ясау өчен нигез функциясен үти; *дөр.:* **каракучкыл**; *чаг.:* **ачык-кызыл**.

**КАРА-КУЧКЫЛЛАНУ́** *ф. ялг. Машинабыз **кара-кучкылланып** берүзе чүл уртасында тора.* Р. Батулла; *дөр.:* **каракучкыллану**.

**КАРА́-КЫЗЫЛ** *с. ялг. Аннары, башак өстәп салуга, олы җиленен селкетеп, озын мөгезләрен куркыныч селтәп **кара-кызыл** сыер чыга ---*. Д. Булатова; *дөр.:* **кара кызыл**; *к.* **ачык-кызыл**.

**КАРАМЕ́ЛЬ** *и.* Карамельгә, карамеле, карамеленә, карамельләр; *ялг.:* **карамельга, карамелена, карамельлар**. *Аңа затлы аракың, әрмән коньягың, шифалы шәрабың кирәк түгел, ә ирисны, **карамельны** суырмыйча тора алмас, бу мәсьәләдә теләсә нинди дәрәҗәле тәмлетамакны бәйгегә чакыра алыр*. Т. Галиуллин. *Бал артык ак төстә икән, димәк, шикәр кушылган: төсе тонык, тәме **карамельны** хәтерләтсә, эретелгән дигән сүз.* Татарстан яшьләре; *к.* **апрель**.

**КАРАО́КЕ** *и.* Караокега, караокесы, караокесына, караокелар; *ялг.:* **караокегә, караокесе, караокесенә, караокеләр**; *к.* **атташе**.

**КАРА́-САРЫ** *с. ялг. Кул-аяк бармаклары кәкрәеп бетте, битләрен* ***кара-сары*** *тут, әллә ниткән миңнәр басты.* Д. Булатова; *дөр.:* **кара сары**; *к.* **ачык-кызыл**.

**КАРА́-СОРЫ** *с. ялг. Көн яңгырлы, күктә* ***кара-соры*** *болытлар туктаусыз йөриләр ---.* Г. Ибраһимов; *дөр.:* **кара соры**; *к.* **ачык-кызыл**.

**КАРАТЕ́** *и.* Каратега, каратесы, каратесына, карателар; *ялг.:* **каратегә, каратесе, каратесенә, карателәр**; *к.* **атташе**.

**КАРА-ТУ́Т** *с. ялг. Капкадан килеп чыгуга, Зиннәт затлы яулыгыннан* ***кара-тут*** *бөдрәләрен салындырып куйган бер «җен хатыны» белән йөзгә-йөз бәрелеште.* Г. Гыйльманов; *дөр.:* **каратут**; *к.* **каракучкыл**.

**КАРА-ТУТКЫ́Л** *с. ялг. Аяк тавышына борылды,* ***кара-туткыл*** *йөзендә, матур кара күзләрендә җиңелчә елмаю уйнады.* Г. Ибраһимов; *дөр.:* **каратуткыл**; *к.* **каракучкыл**.

**КАРА-ТУТЛЫ́** *с. ялг. Озын буйлы, нечкә аяклы, чандыр бер кеше иде ул, йөзе* ***кара-тутлы****, әзрәк шадрасы да бар.* Ә. Еники. *Тәбәнәк кенә,* ***кара-тутлы*** *какча йөзле бу кешенең күз төпләренә арганлык галәмәте булып күгелҗем-сары күләгәләр яткан, чырае йокысызлыктан таушалган иде.* А. Гыйләҗев. *Йөзе түгәрәк,* ***каратутлы****, туры чәчләре маңгаен каплап тора.* М. Маликова; *дөр.:* **каратутлы**; *к.* **каракучкыл**.

**КАРА-ЧУТЫ́Р** *с. ялг. Каршыбызга тагын теге* ***кара-чутыр*** *малай килеп чыкты.* Ә. Дусайлы; *дөр.:* **кара чутыр**; *к.* **ачык-көр**.

**КАРИ́** *и.* Карига, карие, кариена; *ялг.:* **карисы**, **карисына**; *к.* **көрси**.

**КАРЛА́У** *и.* Карлауга, карлавы, карлавына, карлаулар; *ялг.:* **карлауы, карлауына**; *к.* **билбау**.

**КАРТ** *с. ялг.:* **картырак**. *Чөнки Суфия туташ сездән дүрт яшькә* ***картырак****.* Р. Батулла. – *Исәнме, Анакай! – диде* ***картырагы****.* А. Нәҗми. *Шулай ук таза кешеләрнең баш мие, буй сыннары нәфис булганнарныкына караганда 16 елга* ***картырак****.* Кәеф ничек?; *дөр.:* **картрак**; *к.* **бай**.

**КАРТЕ́ЛЬ** *и.* Картельгә, картеле, картеленә, картельләр; *ялг.:* **картельга, картелена, картельлар**; *к.* **апрель**.

**КАРТЕ́ЧЬ** *и.* Картечька, картечена, картечьлар; *ялг.:* **картечькә, картече, картеченә, картечьләр**; *к.* **повесть**.

**КАРУСЕ́ЛЬ** *и.* Карусельгә, каруселе, каруселенә, карусельләр; *ялг.:* **карусельга, каруселена, карусельлар**. ***Карусельга*** *куеп әйләнгәндәй, Үтә дә китә кайтмас еллар*. Ф. Дәүләтгәрәева. ***Карусельда*** *балалар да, өлкәннәр дә күңел ача ала*. Әлмәт таңнары. ***Карусельны*** *бүген үк ачып була, тик аның янындагы территорияне төзекләндерергә кирәк, таләпләр шундый*. Чистай хәбәрләре; *к.* **апрель**.

**КАССАПЧЫ́** *и. ялг.* ***Кассапчыга*** *май кайгы, Кара ишәккә җан кайгы*. Мәкаль. ***Кассапчысы*** *һәйбәт кәсепләнә, кыяфәте шундый җиңүле!..* З. Мансуров; *дөр.:* **кассап**; *к.* **каллиграфчы**.

**КАТА́У** *и.* Катауга, катавы, катавына, катаулар; *ялг.:* **катауы, катауына**; *к.* **билбау**.

**КАТЛАУЛЫ́К** *и. ялг. Сеңлем, кеше гомере күбесенчә* ***катлаулыклар****, чуалчыклардан, кимчелекләрдән, ялгышулардан тора*. А. Нәҗми. *Хак, һәр чорның үз* ***катлаулыклары*** *булган*. М. Хәбибуллин. «*Ләкин бу тиз арада хәл ителә торган вакытлыча* ***катлаулыклар*** *гына», – диде министр*. Татарстан яшьләре; *дөр.:* **катлаулылык**.

**-лылык/-лелек** калыбында ясалган исемнәрнең бер **-лы/-ле** форматын төшереп калдыру сүзнең мәгънәсе бозылуга китерә. ***Катлаулылык*** сүзе **катлау+лы – катлаулы+лык – катлаулылык** рәвешендә ясалган. Ләкин барлык сүзләр дә шушы рәвешле ясалган дигән сүз түгел. Кайвакытта, киресенчә, **-лык/-лык** кушымчасы белән генә ясала. Артык форма һәм сүз ясагыч кушымчалар ялгау да хата булып тора; *чаг.:* **каллиграфчы**.

**КАТО́Д** *и.* Катодка, катоды, катодына, катодлар; *ялг.:* **катотка, катоты, катотына, катотлар**; *к.* **гибрид**.

**КА́У** *и.* Кауга, кавы, кавына, каулар; *ялг.:* **кауы, кауына**; *к.* **билбау**.

**КАФЕ́** *и.* Кафега, кафесы, кафесына, кафелар; *ялг.:* **кафегә, кафесе, кафесенә, кафеләр**; *к.* **алоэ**.

**КА́ФЕЛЬ** *и.* Кафельгә, кафеле, кафеленә, кафельләр; *ялг.:* **кафельга, кафелена, кафельлар**. *Аш әзерләү бүлмәсе, бассейн, юыну урыннары яңа* ***кафельлар*** *сылап үзгәртелә*. Зәй офыклары; *к.* **апрель**.

**КАФЕХАНӘ́** *и. ялг. Базаның ял сезоны ябылганлыктан, без килеп бер атна үткәч, ашханәсе дә эшен туктатты, төшкегә*

*автостанция* ***кафеханәсенә*** *йөри башладык.* Т. Әйди. *Яхшы, мин үземнең* ***кафеханәмдәге*** *телевизорда музыкаль каналларны бетереп, яңалыклар һәм спорт каналларын гына калдырдым ди.* Безнең гәҗит; *дөр.:* **каһвәханә, кафе**.

***Сырахanә, каһвәханә, ашханә, шифаханә*** кебек сүзләрдә тамырга кушылып язылган *ханә* сүзе «бина, йорт» мәгънәсен бирә. ***Кафе*** сүзе үзе кечерәк ресторан мәгънәсен белдерә.

**КАҺВӘ** *и.* Каһвәгә, каһвәсе, каһвәсенә; *ялг.:* **кәһвә, кәһвәгә, кәһвәсе, кәһвәсенә**. ***Кәһвәләр*** *эчкәч, кыз белән Сәйдәш бакчада йөрергә чыга.* Р. Батулла. *Дөрес,* ***кәһвәне*** *ул ике генә савыт эчә, артыгын кичкә калдыра.* Ф. Яхин. *Иртән ирен – эшкә, балаларын мәктәпкә озатканнан соң, бер-берләренә кунакка,* ***кәһвәгә*** *йөриләр.* Сөембикә.

**КАША́У** *и.* Кашауга, кашавы, кашавына, кашаулар; *ялг.:* **кашауы, кашауына**; *к.* **билбау**.

**КАШБА́У** *и.* Кашбауга, кашбавы, кашбавына, кашбаулар; *ялг.:* **кашбауы, кашбауына**; *к.* **билбау**.

**КАШНЕ́** *и.* Кашнега, кашнесы, кашнесына, кашнелар; *ялг.:* **кашнегә, кашнесе, кашнесенә, кашнеләр**; *к.* **атташе**.

**КӘЕФЛЕ́К** *и. ялг. Моны күргәч, Габделбасыйрның каушавы бер* ***кәефлеккә*** *әйләнде.* Ф. Әмирхан; *дөр.:* **кәеф, кәефлелек**.

**КӘЕФЧЕЛЕ́К** *и. ялг. Күтәренке* ***кәефчелек***; *дөр.:* **кәефлелек**.

**КӘЛТӘ́Ү** *и.* Кәлтәүгә, кәлтәве, кәлтәвенә, кәлтәүләр; *ялг.:* **кәлтәүе, кәлтәүенә**; *к.* **билбау**.

**КӘНӘФИ́** *и.* Кәнәфигә, кәнәфие, кәнәфиенә; *ялг.:* **кәнәфисе, кәнәфисенә**. --- *Мәрьям исә, һичбер нәрсәгә карамыйча, яшендәй тизлек белән Зыя ягына атылды һәм, тиз арада аның* ***кәнәфисе*** *янында булып, кулларыннан кысты ---.* Г. Ибраһимов. *Иң соңгы мәртәбә ул премьер-министр* ***кәнәфисенә*** *1999 елда утыра.* Татар-информ; *к.* **гәләфи**.

**КӘНДИ́** *и.* Кәндигә, кәндие, кәндиенә; *ялг.:* **кәндисе**, **кәндисенә**; *чаг.:* **көрси**.

**КӘНҮ́ШНИ** *и.* Кәнүшнигә, кәнүшние, кәнүшниенә; *ялг.:* **кәнүшнисе, кәнүшнисенә**; *к.* **әби**; *к. ш. ук* **гәләфи**.

**КӘСЕПЛӘНҮ́** *ф. ялг. Кассапчысы һәйбәт* ***кәсепләнә****, кыяфәте шундый җиңүле!..* З. Мансуров. *Алар шулай ук балык тоту һәм бал җыю белән, ягъни урманда агач куышлыкларындагы корт ояларын карау белән* ***кәсепләнгәннәр***. Р. Фәхретдинов. *Соңгы*

*елларда Түнтәр халкы күбрәк тегүчелек белән* ***кәсепләнәләр***. Гасырлар авазы; *дөр.:* **кәсеп итү**.

**Шөгыль+ләнү** моделенә ияреп ясалган ялгыш сүз.

**КЕБЕ́К** *бәйл. ялг.:* **кебегерәк**. *Бу бит аның өчен, урманда прәнник төялгән йөк машинасы ауган* ***кебегерәк*** *булган инде*. Матбугат.ру. *Ни чарадан, бичара* ***кебегерәк*** *кабул ителде күңелгә әлеге очрак.* Авыл офыклары. *Каен агачы янында башка агачларга үсүе авыррак дигән* ***кебегерәк,*** *татар мәдәнияте дә русныкы янәшәсендә югалып кала*. «Азатлык радиосы» сайты; *дөр.:* **кебегрәк**; *к.* **бай**.

**КЕ́ГЛИ** *и.* Кеглига, кеглие, кеглиена, киглилар; *ялг.:* **кеглисы, кеглисына, кеглигә, кеглисе, кеглисенә, кеглиләр**; *к.* **бигуди**.

**КЕЛӘ́Ү** *и.* Келәүгә, келәве, келәвенә, келәүләр; *ялг.:* **келәүе, келәүенә**. *Кыш аенда Воскресение Христово чиркәвендә уздырылган керәшен* ***келәүенә*** *барган идем*. Туган як. *Кайчак зур бәйрәм* ***келәүендә*** *дә биш-алты кеше генә катнаша.* Туганайлар; *к.* **билбау**.

**КЕНӘРИ́** *и.* Кенәригә, кенәрие, кенәриенә; *ялг.:* **енәрисе, кәнәрисенә**; *к.* **әби**; *к. ш. ук* **гәләфи**.

**КЕФА́ЛЬ** *и.* Кефальгә, кефале, кефаленә, кефальләр; *ялг.:* **кефальга, кефалена, кефальлар**; *к.* **апрель**.

**КЕ́ШЬЮ** *и.* Кешьюга, кешьюы, кешьюына, кешьюлар; *ялг.:* **кешьюсы, кешьюсына**; *к.* **авеню**.

**КИ́БЕР-ҖИНАЯТЬ** *и. ялг.* ***Кибер-җинаятьләр*** *арткannан арта гына бара.* Шәһри Казан; *дөр.:* **киберҗинаять**; *к.* **фотоальбом**.

**КИ́БЕР-ТУРНИР** *и. ялг.* ***Кибер-турнирга*** *Лаешка Казан, Яшел Үзән, Арча һәм башка җирләрдән 100 дән артык кеше килде.* Кама ягы. ***Кибер-турнир*** *20 октябрьдә Башкортстанның Фәннәр академиясендә узды.* Кызыл таң; *дөр.:* **кибертурнир**; *к.* **фото-альбом**.

**КИ́БЕР-УЕН** *и. ялг. Сайлап алу зона кибертурнирының техник белгече Антон Исламов билгеләп үткәнчә,* ***кибер-уеннар*** *когнитив күнекмәләрне: фикерләү, киңлектә ориентлашу, аңлау, исәпләү, тел, фикер алышуны үстерә.* Татар-информ. *Хәзер Бөтендөнья* ***кибер-уеннары*** *да үткәрелә башлады инде*. Матбугат.ру; *дөр.:* **киберуен**; *к.* **фото-альбом**.

**КИ́БЕР-ҺӨҖҮМ** *и. ялг. Гыйнвар аенда Google Кытай җирләреннән ясалган көчле* ***кибер-һөҗүмгә*** *дучар булды, аның максаты – кытай диссидентларының электрон почтасын сафтан*

*чыгару иде дип фаразлана.* «Азатлык радиосы» сайты. *Шуңа да дүрте көнне үк дөнья пәрәвезендә катгый бәрелешләр булып үтте, хакимият яклы хакерларның сайлау процессын яктыртучы популяр сайтларга* ***кибер-һөҗүмнәре*** *оештырылды, әмма интернет җәнҗалларны моның белән генә туктатып булмады.* Булат Хаков сайты; *дөр.:* **киберһөҗүм**; *к.* **фото-альбом**.

**КИ́ВИ** *и.* Кивига, кивие, кивиена, кивилар; *ялг.:* **кивисы, кивисына, кивигә, кивисе, кивисенә, кивиләр**. *Төркия лимоны – 100 сум, Абхазия мандарины – 85 сум, --- Азәрбайҗан гранаты – 130 сум, Мисыр* ***кивисы*** *– 135 сум, Марокко әфлисуны – 65 сум.* Шәһри Казан; *к.* **бигуди**.

**КИГИ́** *и.* Кигигә, кигие, кигиенә, кигиләр; *ялг.:* **кигига, кигисы, кигисына, кигилар**.

**КИЗЛӘ́Ү** *и.* Кизләүгә, кизләве, кизләвенә, кизләүләр; *ялг.:* **кизләүе, кизләүенә**. *Бу сериядә барысы да булды, җанатарлар «сугышы» да, ватык пыялалар, көтелмәгән алкалар капкага сикерде һәм иң кызыгы вә көлкесе: капкалардан атылып чыккан чын башкорт* ***кизләүе****!* Татар заманы. *Элеккеге вакытта суы бик тәмле булган Канәфер* ***кизләүенең*** *суын труба белән бу якка чыгарганнар иде.* Матбугат.ру; *к.* **билбау**.

**КИЛЬ** *и.* Кильгә, киле, киленә, кильләр; *ялг.:* **кильга, килена, кильлар**. *Яхта әле бөтенләй күмелеп кала, әле бер ягыннан икенче ягына авыша –* ***кильга*** *җиткәнче ялтырап төбе күренеп китә, руль белән моторларны бар дип тә белми --- тайфун үзәгенә томрыла иде.* Алексей Толстой. Инженер Гаринның гиперболоиды (Кыям Миңлебаев тәрҗемәсе); *к.* **апрель**.

**КИНОПО́ВЕСТЬ** *и.* Киноповестька, киноповесте, киноповестена, киноповестьлар; *ялг.:* **киноповестькә, киноповестенә, киноповестьләр**; *к.* **повесть**.

**КИСӘ́Ү** *и.* Кисәүгә, кисәве, кисәвенә, кисәүләр; *ялг.:* **кисәүе, кисәүенә**; *к.* **билбау**.

**КИТ** *и.* Диңгез хайваны атамасы; китка, киты, китына, китлар; *ялг.:* **киткә, ките, китенә, китләр**; *к.* **скиф**.

**КИ́ТЕЛЬ** *и.* Кительгә, кителе, кителенә, кительләр; *ялг.:* **кительга, кителена, кительлар**; *к.* **апрель**.

**КЛИШЕ́** *и.* Клишега, клишесы, клишесына, клишелар; *ялг.:* **клишегә, клишесе, клишесенә, клишеләр**. *Мондый кабатлаулар, даими кулланыла торган тәгъбирләр төрки героик эпосындагы*

*борынгы эпик* ***клишеләрне*** *хәтерләтә*. Л. Мөхәммәтҗанова; *к.* **атташе**.

**КЛО́УНЧЫ** *и. ялг. Циркта* ***клоунчы*** *булу; дөр.:* **клоун**; *к.* **каллиграфчы**.

**КЛО́УНЧЫЛЫК** *и. ялг. Тик кай урыннарда йөреш, кыланыш белән* ***клоунчылыкка*** *бирелү генә урынсыз.* М. Җәлил; *дөр.:* **клоунлык**; *к.* **каллиграфчы**.

**КНЯЗЬ** *и.* Князьгә, князе, князенә, князьләр; *ялг.:* **князьга, князена, князьлар**. --- *бөтен рус халкы җыелышып, ничек тә булса* ***князьларын*** *татарлар кулыннан алыр өчен тырышып, бик күп көч белән татарларга каршы йөргәннәр*. Татар заманы.

**КНЯЗЬЛЕ́К** *и.* Князьлеккә, князьлеге, князьлегенә, князьлекләр; *ялг.:* **князьлыкка, князьлыгы, князьлыгына, князьлыклар**. *Ни эшләмәк кирәк, Алтын Урда тарафыннан* ***князьлыкларның*** *яшәү тәртибен рәткә китерү, Көнбатыш Европаның ярдәме белән үзебезгә каршы эшләнгән явызлыклар булып әйләнеп кайта*. Безнең гәҗит.

**КОБЗА́РЬ** *и.* Кобзарьга, кобзаре, кобзарена, кобзарьлар; *ялг.:* **кобзарьгә, кобзаренә, кобзарьләр**; *к.* **лагерь**.

**КОД** *и.* Кодка, коды, кодына, кодлар; *ялг.:* **котка, коты, котына, котлар**; *к.* **гибрид**.

**КОЗА́У** *и.* Козауга, козавы, козавына, козаулар; *ялг.:* **козауы, козауына**; *к.* **билбау**.

**КО́ЗЫРЬ** *и.* Козырьга, козыре, козырена, козырьлар; *ялг.:* **козырьгә, козыренә, козырьләр**; *к.* **лагерь**.

**КОЙНЕ́** *и.* Койнега, койнесы, койнесына, койнелар; *ялг.:* **койнегә, койнесе, койнесенә, койнеләр**. *Татар уртак сөйләмә теленең, ягъни татар* ***койнесенең*** *үсешендә нинди этаплар булган соң?* М. Зәкиев. *Шәһәрләрдә дә шундый процесс барган, шәһәр* ***койнесе*** *оешкан.* И. Хуҗин; *к.* **атташе**.

**КОКТЕ́ЙЛЬ** *и.* Коктейльгә, коктейле, коктейленә, коктейльләр; *ялг.:* **коктейльга, коктейлена, коктейльлар**. *Сезгә нәрсә,* ***коктейльмы****, әллә вискимы?* Г. Каюмов; *к.* **апрель**.

**КОЛАКБА́У** *и.* Колакбауга, колакбавы, колакбавына, колакбаулар; *ялг.:* **колакбауы, колакбауына**; *к.* **билбау**.

**КОЛГО́ТКИ** *и.* Колготкига, колготкие, колготкиена, колготкилар; *ялг.:* **колготкисы, колготкисына, колготкигә, колготкисе, колготкисенә, колготкиләр; колготка, колготкасы, колготка-**

**сына**. *Ашыгычлык белән итәген кияргә оныткanмы – елан кабыгыдай челтәрле кара **колготкисы** тулысынча күренеп тора.* Казан утлары. *Әнисе аның **колготкасын**, күлмәген алыштыра*. Казан утлары; *к.* **бигуди**.

**КОЛИ́БРИ** *и.* Колибрига, колибрие, колибриена, колибрилар; *ялг.:* **колибрисы, колибрисына, колибригә, колибрисе, колибрисенә, колибриләр**; *к.* **бигуди**.

**КОЛЛЕ́КЦИЯЛӘШТЕРҮ** *ф. ялг. Иске акчалар **коллекцияләштерү;** маркалар **коллекцияләштерү;** картиналар **коллекцияләштерү***; *дөр.:* **коллекцияләү, коллекция төзү, коллекция җыю**; *к.* **стимуллаштыру**.

**КОЛЛО́ИД** *и.* Коллоидка, коллоиды, коллоидына, коллоидлар; *ялг.:* **коллоитка, коллоиты, коллоитына, коллоитлар**; *к.* **гибрид**.

**КОЛОНИЗА́ЦИЯЛӘШТЕРҮ** *ф. ялг. Африка илләрен **колонизацияләштерү***; *дөр.:* **колонизацияләү, колонияләштерү, колония итү, колониягә әйләндерү; колониальләштерү**; *к.* **стимуллаштыру**.

**КОЛЬРА́БИ** *и.* Кольрабига, кольрабие, кольрабиена, кольрабилар; *ялг.:* **кольрабисы, кольрабисына, кольрабигә, кольрабисе, кольрабисенә, кольрабиләр**; *к.* **бигуди**.

**КОМА́НДОВАНИЕ** *и.* Командованиегә, командованиесе, командованиесенә, командованиеләр; *ялг.:* **командованиега, командованиесы, командованиесына, командованиелар**. *Ләкин ул бу хакта **командованиега** сүз катарга кыймый.* Р. Мостафин. *Сәяхәтебезнең беренче көнендә корпусның **командованиесын**, музей белән таныштырдылар*. Кайбыч таңнары. *«Кызыл» гаскәрләрнең туплавы Халык армиясенең **командованиены** саклык һөҗүмне башлауга мәҗбүр иткән*. Википедия; *к.* **звание**.

**КОМА́НДОВАНИЯ** *и. ялг. Ачыграк әйткәндә, ул әлеге сугыш барышында рус **командованиясенең** мөселман дивизиясен канкардәш төрекләрнең башын кисәргә тиешле балта итеп файдаланырга теләүләрен аңлый.* Фән һәм тел; *дөр.:* **командование**; *к.* **предприятия**.

**КОМБИНА́ЦИЯЛӘШТЕРҮ** *ф. ялг. Төрле төсләрне **комбинацияләштерү;** шахматта йөрешләрне **комбинацияләштерү;*** *дөр.:* **комбинацияләү, комбинация ясау, комбинация төзү; яраклаштыру, туры китерү**; *к.* **стимуллаштыру**.

**КО́МИ** *и.* Комига, комие, комиена, комилар; *ялг.:* **комисы, комисына, комигә, комисе, комисенә, комиләр**; *к.* **бигуди**.

**КОМО́Д** *и.* Комодка, комоды, комодына, комодлар; *ялг.:* **комотка, комоты, комотына, комотлар**. *Марат ике атлап бер сикерде дә Артемны якасыннан йолкып җан фәрманга почмак якка селтәде. Артем баш чүмече белән шундагы* ***комот*** *почмагына килеп бәрелде*. Ф. Имамов; *к.* **гибрид**.

**КОМПЛЕ́КТЛАШТЫРУ** *ф. ялг. Механизаторлар трактор һәм авыл хуҗалыгы машиналарына механик ремонт кына түгел, косметик ремонт та ясау өстенә, аларны* ***комплектлаштырып*** *та куйганнар иде.* Татарстан яшьләре. *Архив бүлеге эшчәнлеге архив документларын исәпкә алу,* ***комплектлаштыру****, аларны саклау һәм халык ихтыяҗын канәгатьләндерүдән гыйбарәт*. Зәй офыклары; *дөр.:* **комплектлау, комплект төзү, комплект ясау, комплект итү; тулыландыру**; *чаг.:* **стимуллаштыру**.

**КОМПО́СТИРЛАУ** *ф. ялг. Билет* ***компостирлау***; *дөр.:* **компостерлау**; *к.* **реагирлау**.

**КОНВОИРЛА́У** *ф. ялг. Полиция хезмәткәре, Россия Эчке эшләр министрлыгы Әлмәт районы буенча бүлегенең гаепләнүчеләрне һәм шик астындагыларны вакытлыча тоткарлау изоляторының гаепләнүчеләрне һәм шик астындагыларны саклау һәм* ***конвоирлау*** *бүлекчәсе машина йөртүчесе Ринат Абзаловның 2009 елгы кызы Алсу Абзалова озак вакытлар дәвамында «баш миендәге диффуз шеш» диагнозы белән ДРКБда дәвалана*. Әлмәт таңнары. *Тоткыннарны* ***конвоирлау*** *– җинаять-җәза системасы хезмәткәрләре башкаручы иң җаваплы бурычларның берсе.* Татар-информ; *дөр.:* **конвойлау, конвой белән алып бару**; *к.* **реагирлау**.

**КОНВОИРЛАШТЫРУ́** *ф. ялг.* ***Конвоирлаштыру****, медицина хезмәте күрсәтү, капиталь төзелеш буенча тулы күләмле бурычлар билгеләнде*. Туган як; *дөр.:* **конвойлау, конвойлауны оештыру, конвой белән алып баруны оештыру**; *к.* **стимуллаштыру**.

**КОНДИ́ТЕРЧЫ** *и. ялг.* ***Кондитерчы*** *булып эшләү; дөр.:* **кондитер**; *к.* **каллиграфчы**.

**КОНСЕ́РВ** *и. ялг. Менә шунда ул кечерәк кенә бер* ***консерв*** *заводында юрисконсульт булып эшли башлый.* Р. Мирхәйдәров. *Өлфәт абзый папирус төпчегенә кат-кат төкереп, капка артындагы кара балчыкка яхшылап утырткан* ***консерв*** *банкасына ыргытты да төн караңгылыгы аша тагын «кунак» малайга борылып карады.* Л. Ибраһим-Вәлиди. *Киткәндә куеп киткән* ***консерв*** *калае каен суы белән тулган иде, әбисен сыйлыйм әле, дип, чайпал-*

*дырмый сак кына тотып, өйләренә кайтып җитте.* З. Кадыйрова; *дөр.:* **консервы**.

**КОНСЕ́РВА** *и. ялг.* ***Консерва*** *дип аталган бу калайларның матурлыгы балаларны шаккатырды.* Р. Батулла. *Теге немец һаман минем янда –* ***консерва*** *банкасыннан ботка ашап утыра.* Г. Гыйльманов. *Айзигына ашарга* ***консерва*** *ачып, табагына ике өлеш артыграк бушатты ---.* Ф. Яхин; *к.* **газета**.

**КОНСО́ЛЬ** *и.* Консольгә, консоле, консоленә, консольләр; *ялг.:* **консольга, консолена, консольлар**; *к.* **апрель**.

**КОНСТЕ́БЛЬ** *и.* Констебльгә, констебле, констебленә, констебльләр; *ялг.:* **констебльга, констеблена, констебльлар**; *к.* **апрель**.

**КОНТР-АГЕ́НТ** *и. ялг. Янәсе, «фирма-однодневка»ның* ***контр-агентлары*** *булганнар.* Безнең гәҗит; *дөр.:* **контрагент**; *к.* **фото-альбом**.

**КОНТР-ДӘЛИ́Л** *и. ялг. Шуннан соң инде* ***контр-дәлилләр*** *санап кителә.* Р. Миңнуллин; *дөр.:* **контрдәлил**; *к.* **фото-альбом**.

**КОНТР-ҖАВА́П** *и. ялг.* ***Контр-җаваплары****: Башкортстанның үзендә дә татарча газета-журналлар күп, китаплар, хәтта татарча дәреслекләр дә басыла, әле генә гөрләп Татар җыены үтте, мәктәпләр ачабыз һәм башкалар.* Татарстан яшьләре; *дөр.:* **контрҗавап**; *к.* **фото-альбом**.

**КОНТРНАСТУПЛЕ́НИЕ** *и.* Контрнаступлениегә, контрнаступлениесе, контрнаступлениесенә, контрнаступлениеләр; *ялг.:* **контрнаступлениега, контрнаступлениесы, контрнаступлениесына, контрнаступлениелар**; *к.* **звание**.

**КОНТРОЛЬ-БӘЯЛӘ́Ү** *с. мәгъ. ялг. Анда 2016 елгы* ***контроль-бәяләү*** *материаллары кулланылды.* Кайбыч таңнары; *дөр.:* **тикшерү-бәяләү ...-ы/-е, тикшерү һәм бәяләү ...-ы/-е**; башка контекстларда: **күзәтчелек итү-бәяләү...-ы/-е, күзәтчелек итү һәм бәяләү ...-ы/-е,** һ.б.ш.; *к.* **либераль-икътисад**.

**КОНТРО́ЛЬ-ИНСПЕКЦИЯСЕ** *с. ялг. Бу хакта ТР Дәүләт алкоголь инспекциясенең Яшел Үзәндәге территориаль органының* ***контроль-инспекциясе*** *бүлеге эксперты Анна Гыйләҗева хәбәр итте.* Кайбыч таңнары; *дөр.:* **контроль инспекциясе ...-ы/-е, күзәтчелек инспекциясе ...-ы/-е, контроль-инспекция ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**КОНТРОЛЬ-ИСӘПЛӘ́Ү** *и. ялг. Мәгариф министрлыгы мәгълүматларына караганда, узган уку елында төп фәннәр буенча*

***контроль-исәпләү*** *материалларындагы мәгълүматларны Интернет челтәренә куюның 31 очрагы теркәлгән.* З. Фәтхетдинова. «*Ютазы муниципаль районының* ***контроль-исәпләү*** *палатасы турында»гы положениене раслау соравын* ***контроль-исәпләү*** *палатасы рәисе З. Сәитгалина яктыртты.* Ютазы таңы; *дөр.:* **контроль исәпләү ...-ы/-е, контроль һәм исәпләү ...-ы/-е, күзәтчелек һәм исәпләү ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**КОНТРОЛЬ-КҮЗӘТҮ́** *с. мәгъ. ялг. Башкортстан Президенты каршындагы Урындагы үзидарә органнарына карата* ***контроль-күзәтү*** *эшчәнлегенең нәтиҗәлелеген анализлау буенча ведомствоара комиссия Русия Президенты карары белән төзелгән иде.* Кызыл таң; *дөр.:* **контроль-күзәтү ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**КОНТРОЛЬ-ПО́СТ** *с. мәгъ. ялг. 15 март көнне Киров районының «Малиновка»* ***контроль-пост*** *пунктында 10 килограммга якын героин тотканнар.* Кәеф ничек?; *дөр.:* **контроль посты, тикшерү посты, контроль тикшерү ...-ы/-е, күзәтү-тикшерү пункты**; *к.* **либераль-икътисад**.

**КОНТРОЛЬ-ПРО́ПУСК** *с. мәгъ. ялг. Менә трамвай* ***контроль-пропуск*** *пунктына җитеп туктады.* М. Яһудин; *дөр.:* **тикшереп үткәрү ...-ы/-е, контроль һәм үткәрү ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**КОНТРОЛЬ-ТИКШЕРҮ́** *и. ялг. --- ашык-пошык кына корыштырып куелган бер* ***контроль-тикшерү*** *пункты түбәсендә яз кояшында назланып, татлы хыялларына чумып ята.* И. Сираҗи. *Укучыларның* ***контроль-тикшерү*** *материаллары (тестлар) шулай ук ел саен төрле бәхәсләр тудыра.* Кәеф ничек?; *дөр.:* **контроль тикшерү ...-ы/-е, контроль һәм тикшерү ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**КОНТРОЛЬ-ҮЛЧӘ́Ү** *и. ялг. Башта безнең чыгарылыш укучылары* ***контроль-үлчәү*** *материаллары буенча БДИ тапшырачак.* Казан утлары. *Түбән Кама нефть химиясе колледжын тәмамлаган иде, хәзерге вакытта «Нефтехим» акционерлык җәмгыятендә* ***контроль-үлчәү*** *приборлары һәм автоматика слесаре булып эшли.* Туган як. *Лаборатория технологик процессларны модельләштерү өчен* ***контроль-үлчәү*** *җиһазларын, идарә системаларын, автоматизацияне, программа белән тәэминатны өйрәнү буенча студентлар, магистрантлар һәм аспирантлар белән дәресләр үткәрү өчен каралган.* Татар-информ; *дөр.:* **контроль үлчәү ...-ы/-е, контроль**

**һәм үлчәү ...-ы/-е, тикшерү-үлчәү ...-ы/-е, тикшерү һәм үлчәү ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**КОНТРОЛЬ-ҮТКӘРЎ** *и. ялг. Шартларга бәйле рәвештә* ***контроль-үткәрү*** *пункты җитәкчесе звеноларны кирәкле җиһазлар белән тәэмин итә.* 2013 Универсиадасы блогы; *дөр.:* **тикшереп үткәрү ...-ы/-е, контроль һәм үткәрү ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**КОНТРОЛЬ-ХИСАПЛА́У** *и. ялг. Бүген Казанда муниципаль берәмлекләрнең* ***контроль-хисаплау*** *органнары рәисләре дәүләт, муниципаль заказларын урнаштыру буенча комиссия вәкилләре катнашында семинар-киңәшмә үтте.* А. Исмәгыйлев; *дөр.:* **контроль хисаплау ...-ы/-е, контроль һәм хисаплау ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**КОНТР-ПРОПАГА́НДА** *и. ялг. Үзләре, балалары бәхет күрмәгән күршеләре шикаятенә таянып, советларга каршы* ***контр-пропаганда*** *алып баруда, милләтчелектә гаепләнгән әтисе 1937 елда ук атылган икән ләбаса.* Т. Галиуллин; *дөр.:* **контрпропаганда**; *к.* **фото-альбом**.

**КОНТР-ҺӨҖЎМ** *и. ялг. Һәм, әлбәттә, алар Кызыл Армиянең Югары командованиесенең шушы көннәрдә җентекләп эшләнгән* ***контр-һөҗүм*** *планының нечкәлекләрен ачыклавын һәм башкалада фашист гаскәрләренең тар-мар ителәчәген башларына да китерә алмыйлар.* Биектау хәбәрләре. *Унберенче минутта* ***контр-һөҗүмдә*** *теләчеләр исәпне тигезли.* Безнең гәҗит; *дөр.:* **контрһөҗүм**; *к.* **фото-альбом**.

**КОНТР-ЧАРА́** *и. ялг. Шуңа күрә Илдарский* ***контр-чаралар*** *турында уйлый башлады.* Г. Әпсәләмов; *дөр.:* **контрчара**; *к.* **фото-альбом**.

**КОНФЕРАНСЬЕ́** *и.* Конферансьега, конферансьесы, конферансьесына, конферансьелар; *ялг.:* **конферансьегә, конферансьесе, конферансьесенә, конферансьеләр**; *к.* **ателье**.

**КОНФЕ́ТА** *и. ялг. Кыз плитәне мактый-мактый чәй куеп җибәрде, башы күккә тигән мәһабәт суыткычтан шоколадлы* ***конфеталар*** *һәм мармелад белән шыплап тулы зур сай тәлинкә башын калкытты.* Ф. Бәллүр; *к.* **газета**.

**КОНФЕТТИ́** *и.* Конфеттига, конфеттие, конфеттиена, конфеттилар; *ялг.:* **конфеттисы, конфеттисына, конфеттигә, конфеттисе, конфеттисенә, конфеттиләр**; *к.* **бигуди**.

**КОНЦЛА́ГЕРЬ** *и*. Концлагерьга, концлагере, концлагерена, концлагерьлар; *ялг.:* **концлагерьгә, концлагеренә, концлагерьләр**. *Әлеге көндәлекне нацист* ***концлагерендә*** *вафат булган яһүд кызы язган, композитор шул әсәр буенча опера иҗат итә*. Казан утлары. *Әтием Галләметдин Мөхәммәтшәрип улы 10 ел Совет* ***концлагерендә*** *булып кайтты*. Безнең гәҗит. *Сочида Олимпия уеннарын оештыруны алар Освенцим* ***концлагеренә*** *барып күңел ачуга тиңли*. «Азатлык радиосы» сайты; *к*. **лагерь**.

**КООРДИНА́ЦИЯЛӘШТЕРҮ** *ф. ялг. Утырышы барышында штаб сәркәтибе – Казан муниципаль берәмлегенең Административ контрольне* ***координацияләштерү*** *идарәсе башлыгы Гөлшат Гыйсмәтуллина биредә катнашучыларны төп нигезләмәләр белән таныштырды, штаб шулар нигезендә эшләячәк*. Татар-информ; *дөр.:* **координацияләү, көйләү, җайга салу**; *к*. **стимуллаштыру**.

**КОРА́БЛЬ** *и*. Корабльгә, корабле, кораблено, корабльләр; *ялг.:* **корабльга**, **кораблена, корабльлар**; *к*. **апрель**.

**КОРА́ЛЛ** *и*. Кораллга, кораллы, кораллына, кораллар; *ялг.:* **коралы, коралына, коралллар**. *Болгарлар фин-угор халыклары белән аралашып яшәгәнгә күрә, ювелир эшләнмәләрендә дә форма ягыннан, тәңкәләр һәм* ***коралллар*** *белән бизәлеше ягыннан охшашлыклар шактый*. Белем.ру; *к*. **металл**.

**КОРД** *и*. Кордка, корды, кордына, кордлар; *ялг.:* **кортка, корты, кортына, кортлар**; *к*. **гибрид**.

**КОРО́ЛЬ** *и*. Корольгә, короле, короленә, корольләр; *ялг.:* **корольга, королена, корольлар**. *Әстерхан һәм Казанны алу сезнең галиҗәнаб* ***корольга*** *лаеклы эш булыр*. Г. Гобәйдуллин. *Хельг Калдун Рюрикны үтерә, Рюрикка кияүгә чыккан Киев каласы каханы кызы Фатыйманы (Карамзин бу гүзәл хатынны «Фатьма» дип яза) Швеция* ***королена*** *озата*. М. Хәбибуллин; *к*. **апрель**.

**КОРРЕКТИРЛА́У** *ф. ялг. Текстны* ***корректирлау;*** *планнарны* ***корректирлау;*** *дөр.:* **корректлау, коррекцияләү, корректура кертү, төзәтү**; *к*. **реагирлау**.

**КОРСА́КАЯКЛЫЛАР** *и. күпл. зоол. ялг*. Моллюсклар классы; *дөр.:* **корсагаяклылар**; *к*. **ишекалды**.

**КОРША́У** *и*. Коршауга, коршавы, коршавына, коршаулар; *ялг.:* **коршауы, коршауына**; *к*. **билбау**.

**КОРЬӘН-И КӘРИ́М** *и. ялг.* ***Корьән-и Кәримне*** *ачык-көр тавыш белән моңлы-аһәңле итеп уку – ул үзе бөек бәхет*. Р. Батулла; *дөр.:* **Коръәне Кәрим**.

**КОТЛЕ́ТА** *и. вар. Монда «**котлетадан** чебенне» аерырга кирәк, милләттәшләр.* Матбугат.ру; *к.* **газета**.

**КО́ФЕ** *и.* Кофега, кофесы, кофесына, кофелар; *ялг.:* **кофегә, кофесе, кофесенә, кофеләр**. *Шоколады-конфеты, **кофесе**-какаосы, чикләвеге-шикәре – һәммәсе-һәммәсе агылып кына торды*. Ф. Яруллин. *Ул бу аваз ияртеменең аның сүзләренә каратамы, **кофегәме** икәнен аңламыйча бер-ике мизгелгә аптырап кала, әмма дәвам итә: – Анда хәзер яңартканнар, бу атнада үзем дә яңа чаңгыларымны алып барган идем.* Л. Әбүдәрова. *Кабинет хуҗасы «ярый, эшләрбез» дигән сыман башын кагып куйды, кунакчыл подполковник тәкъдим иткән хуш исле **кофене** шоколадлы конфет белән йотып куйгач Рабит Ора Бит рәхмәтләрен укыйукый «өе»нә җыена башлады*. Ф. Бәллүр; *к.* **атташе**.

**Кофе** сүзе **каһвә** сүзенең сөйләм варианты буларак кулланыла.

**КӨРӘКАЯ́К** *и. зоол. ялг.* Диңгез әкәм-төкәме; *дөр.:* **көрәгаяк**; *к.* **ишекалды**.

**КӨРӘ́КАЯКЛЫЛАР** *и. күпл. зоол. ялг.* Диңгез әкәм-төкәмнәре отряды; *дөр.:* **көрәгаяклылар**; *к.* **ишекалды**.

**КӨРСИ́** *и.* Көрсигә, көрсие, көрсиенә; *ялг.:* **көрсисе**, **көрсисенә**. *Ана кочагындамы, мәктәп **көрсисендәме** булсын, балаларыбызга Тукайны сөйдерү нияте белән иң әүвәл аның кызганыч тулы тәрҗемәи хәлен сөйлибез* ---. Габдулла Тукайга багышланган Интернет-портал.

***-и*** гә тәмамланган гарәп һәм фарсы алынмалары да татар сүзләре белән аналогия буенча тартым кушымчасының ***-е*** вариантын кабул итә. Ләкин аннан соң килгән кушымчаларда яки башка категорияләр белән төрләндергәндә, нигез үзенчәлекләренә бәйле рәвештә, арткы рәт кушымчалары да язылырга мөмкин, аларга игътибар итәргә кирәк: *мәс.:* **хаҗилар, суфилар** һ.б.; *чаг.* **гәләфи**.

**КӨРТИ́** *и.* Көртигә, көртие, көртиенә; *ялг.:* **көртисе, көртисенә**; *к.* **гәләфи**.

**КРЕМЛЬ** *и.* Кремльгә, кремле, кремленә, кремльләр; *ялг.:* **кремльга, кремлена, кремльлар**. *Google Earth картасыннан **Кремльга** карасаң, Кол Шәриф мәчетеннән Сөембикә манарасына юнәлгән дүрт манаралы олы шәүләне күрәсең*. Татар заманы. *Бүген*

*Казан Кремле янында тантаналы рәвештә «**Кремльдан Кремльга** кадәр ЮНЕСКО бөтендөнья тарихи-мәдәни мирасын саклап калу» моторалли тәмамланды*. «Рәсми Татарстан» порталы. ***Кремльда** Кол Шәриф җәмигъ мәчетендә 2006 елда ачылып, хәзергә кадәр Ислам мәдәнияте музее эшләп килә*. Татар-информ; *к.* **апрель**.

**КРЕ́НДЕЛЬ** *и.* Крендельгә, кренделе, кренделенә, крендельләр; *ялг.:* **крендельга, кренделена, крендельлар**; *к.* **апрель**.

**КРЕ́ПОСТЬ** *и.* Крепостька, крепосте, крепостена, крепостьлар; *ялг.:* **крепостькә, крепостенә, крепостьләр**. *Янки лагереннан безне Демблин **крепостенә** күчерделәр*. Казан утлары. *Кулга алынган министрларны сарайны җылытыр өчен әзерләнгән һәм баррикада итеп файдаланылган утын өемнәре яныннан Петропавел **крепостенә** алып китәләр*. Мәйдан; *к.* **повесть**.

**КРЕЩЕ́НИЕ** *и.* Крещениегә, Крещениесе, Крещениесенә, Крещениеләр; *ялг.:* **Крещениега, Крещениесы, Крещениесына, Крещениелар**. *Ул хәзер Раштуадан алып **Крещениега** кадәр дәвам итә торган «святки» дигәнне аңлата*. Самара региональ «Дуслык» һәм Самара шәһәр «Ак бәхет» иҗади-иҗтимагый оешмаларының уртак сайты. *Мин үзем дә, балаларым да һәр елны **Крещениеда** коенабыз*. Әлки хәбәрләре. *Дөрес, бәкедә коену **Крещениеның** мәҗбүри йоласы түгел, һәр дин тотучының шәхси эше*. Кайбыч таңнары; *к.* **звание**.

**КРЕЩЕ́НИЯ** *и. ялг. **Крещения** коенуларында Зәңгәр күлгә 1000 ләп кеше килер дип көтелә*. Әлмәт таңнары; *к.* **предприятия**.

**КРИМИНА́Л** *и.* Җинаять, җинаятьчелек; *ялг.:* **криминал төркем, криминал сугыш, криминал яңалык**. *Тагын бер сәбәп: сугышчылар сылтавы белән, шартлауларны бай кешеләрдән акча таләп итүче **криминал** төркемнәр оештырган булырга мөмкин*. Безнең гәҗит. *Шуның аркасында күбесе **криминал** сугышларда һәлак булды*. Ватаным Татарстан. *Телевизордан **криминал** яңалыкларны күрсәткәндә, тегe яки бу җинаятьнең шаһиты булган кешеләрне дә сөйләтәләр*. Татарстан яшьләре; *чаг.:* **криминаль**; *к.* **вокаль**.

**КРИМИНАЛЛАШТЫРУ́** *ф. ялг. МР Советының юридик бүлеге җитәкчесе Мария Бисярина халыкара документлар һәм Россия Федерациясендә коррупциягә каршы тору, ришвәт бирүгә яки алуга вәгъдәне **криминаллаштыру**, ришвәт бирү яки ришвәт алуны тәкъдим итү өлкәсендә гамәлдәге законнар турында чыгыш ясады*. Идел таңнары; *чаг.:* **криминальләштерү**.

**КРИМИНАЛЛАШУ́** *ф. ялг. Элеккеге совет шабашниклары Русиядә төзүчеләр сыйныфы кытлыгыннан файдаланырга гына өйрәнделәр, ә һөнәри дәрәҗәләре элеккеге кебек үк калды. Бу – илдәге* ***криминаллашу*** *чорының нәтиҗәсе ---.* Татарстан яшьләре. *Ялган товар әйләнеше бигрәк тә күп халык яши торган эре шәһәрләрдә* ***криминаллашкан***. Татар-информ. *Утырышны ачып, Россия Президенты Владимир Путин көн тәртибенә кертелгән мәсьәлә күп проблемаларны берләштерә, шуңа күрә җәмгыятьнең* ***криминаллашу*** *сәбәпләрен бетерү буенча чаралар эшләргә кирәк, дип ассызыклады.* Рәсми Татарстан; *чаг.:* **криминальләшү**.

**КРИМИНА́ЛЬ** *с.* Җинаятьчелеккә бәйле: **криминаль төркем, криминаль сугыш, криминаль яңалык**; *чаг.:* **криминал**; *к.* **вокаль**.

**КРИМИНАЛЬЛӘШТЕРҮ́** *ф.* Криминаль юлга җибәрү, криминаль төс бирү: **икътисадны криминальләштерү, социаль һәм сәяси өлкәләрне криминальләштерү**; *чаг.:* **криминаллаштыру**.

**КРИМИНАЛЬЛӘШҮ́** *ф.* Криминаль төсмер алу, җинаятьчелек белән бәйләнү; җинаятьчелек арту: **корал әйләнеше криминальләшү; шәһәрдәге вазгыять криминальләшү**; *чаг.:* **криминаллашу**.

**КРИСТА́ЛЛ** *и.* Кристаллга, кристаллы, кристаллына, кристаллар; *ялг.:* **кристалы, кристалына, кристалллар**. *Татарстан Президентына водород ягулыгы элементлары, микроэлектроника,* ***кристалллар*** *үстерү өлкәсендәге эшләнмәләр күрсәтелде.* Рәсми Татарстан. *«Puls arventure» ярдәме белән күтәрелгән проектлар фармацевтика, торбалар чистарту, оптика, юеш* ***кристалллар*** *һәм башка өлкәләргә кагыла*. Intertat.ru. *Әгәр амёбалы су тамчысына аш тозының кечкенә генә* ***кристалын*** *салсаң, амёбаның тәне йомарлана, җыела ---.* Биология; *к.* **металл**.

**КРОССВО́РД** *и.* Кроссвордка, кроссворды, кроссвордына, кроссвордлар; *ялг.:* **кроссвортка, кроссворты, кроссвортына, кроссвортлар**; *к.* **гибрид**.

**КРУПЬЕ́** *и.* Крупьега, крупьесы, крупьесына, крупьелар; *ялг.:* **крупьегә, крупьесе, крупьесенә, крупьеләр**; *к.* **ателье**.

**КУАКЛА́У** *ф. ялг.* ***Куаклау*** сүзе татар теленең сүз ясау калыпларына туры килсә дә, чынлыкта андый сүз дә, ул белдергән төшенчә дә юк.

**КУАНЫЧЛЫ́К** *и. ялг. Аталы-аналы ике карчыга бер тау башында урын тота иделәр. Вә дәрәҗәләренә карап лаек кәсеп итеп,* ***куанычлыкта*** *гомер итә иделәр.* Татар халык иҗаты. *Февраль*

*инкыйлабын Русиядә изелгән бөтен халыклар бик шатлык, **куанычлык** белән каршы алган ---*. Гасырлар авазы; *дөр.:* **куаныч**; *к.* **каллиграфчы**.

**КУГЫНЧЫ́** *и. ялг. Бүреләр артыннан **кугынчы** чыгару; дөр.:* **кугын**; *к.* **каллиграфчы**.

**КУГЫНЧЫЛЫ́К** *и. ялг. **Кугынчылык*** сүзе татар теленең сүз ясау калыпларына туры килсә дә, чынлыкта андый сүз дә, ул белдергән төшенчә дә юк; *дөр.:* **кугын**; *к.* **каллиграфчы**.

**КУЕ́-ЗӘҢГӘР** *с. ялг. Полковник Баһавиевның бу фаразы дөрескә чыга: «кунаклар» Арчада өч көн узгач пәйда була, ягъни У 324 АЕ / 02 номерлы **куе-зәңгәр** машина милиция экипажларының берсе күзенә чалына.* Безнең гәҗит. *Алар арасында шулай ук **куе-зәңгәр** күк йөзе фонында тик алсу лаләләр генә төшерелгәннәре дә бар*. Татар-информ; *дөр.:* **куе зәңгәр**; *к.* **ачык-кызыл**.

**КУЕ́-КАЛЫН** *с. ялг. Ул арада ул кызның **куе-калын** толымнарында ялтыравык тасмалар үрелгәнен күреп ала*. Р. Гаязетдин; *дөр.:* **куе калын**; *к.* **ачык-көр**.

**КУЕ́-КАРА** *с. ялг. Ибраһим хан балалары Габдел Латыйф та, Әҗем хан да мәһабәт ирләр иде, буйлы, көр тавышлы, **куе-кара** сакаллы, карап торырлык ага белән эне иде*. Р. Батулла. *Әмма **куе-кара** болытлар кечке эңгер-меңгерне тәмам караңгылаткан.* Н. Акмал. *Әле кояш нурларының әсәре дә юк – авыл өстендәге **куе-кара** төн юрганы иренеп кенә үз чабуларын җыеп маташа.* Шәһри Казан; *дөр.:* **куе кара**; *к.* **ачык-кызыл**.

**КУЕ́-КОҢГЫРТ** *с. ялг. Саргылт сыеклык яки **куе-коңгырт** төстәге каты матдә, тыгызлыгы 1,08–1,16 г/см ---*. Төзү материаллары. *Хәбәрсез югалган ир-ат зәңгәр төстәге чалбар, зәңгәрле-яшелле куртка, «хаки» төсендәге итекләр, **куе-коңгырт** төстәге бейсболка кигән булган.* Татар-информ; *дөр.:* **куе коңгырт**; *к.* **ачык-кызыл**.

**КУЕ́-КУЧКЫЛ** *с. ялг. Көн дәвамында әллә ничә тапкыр өстен алыштырды: йә күксел болытларны яулык итеп чөеп куя, йә **куе-кучкыл** бәрхет төсендәге болытларны кәпәч итеп башына чәпи, йә уйнаклап очкан йомшак карларны шәл итеп бөркәнә.* Көмеш кыңгырау; *дөр.:* **куе кучкыл**; *к.* **ачык-кызыл**.

**КУЕ́-КЫЗЫЛ** *с. ялг. Шәрә хатыннар сурәте төшерелгән бер затлы шешәдән атаман, сырлы стакан тутырып, икебезгә дә **куе-кызыл** эчемлек агызды.* Н. Әхмәдиев. *Самагон ясаганда әче-*

*шүнең өстәмә продукты булып аракы мае, төрле төстәге (аклы-сарылы, **куе-кызыл**) майлы сыеклык тора ---*. Туган як. *Сүрәләр язылган битләрнең тирә-ягында **куе-кызыл** төстәге уклар*. Кызыл таң; *дөр.:* **куе кызыл**; *к.* **ачык-кызыл**.

**КУЕ́-ОЗЫН** *с. ялг. Алсуланып янып торган бит алмаларын **куе-озын** керфекләргә төренгән шомырттай кара күзләре ничек нурландыра*. Мәдәни җомга; *дөр.:* **куе озын**; *к.* **ачык-көр**.

**КУЕ́-САРЫ** *с. ялг. Вулкан кратерыннан ургылып ага торган **куе-сары** төстәге лаваның сәер матурлыгы Самусны хәйран калдырды*. Р. Батулла; *дөр.:* **куе сары**; *к.* **ачык-кызыл**.

**КУЕ́-ЯШЕЛ** *с. ялг. --- ул торфлы сазлыкларга таба сузылып киткән **куе-яшел** төстәге дерелдәвеккә күрсәтте*. Р. Вәлиев. *Кыздырылган кабак онын бераз су кушып янә болгаталар, аннан **куе-яшел**, кара төстәге май сыгып алалар*. Татарстан яшьләре; *дөр.:* **куе яшел**; *к.* **ачык кызыл**.

**КУЕ́-ЯШЬКЕЛТ** *с. ялг.: Эңгер инде өй каршындагы тупыл башларына кадәр үк менеп җитә, **куе-яшькелт** колачын җәеп, шәфәкъ алсулыгына таба ага.* Ватаным Татарстан; *дөр.:* **куе яшел** яки **яшькелт**.

Ялгыш бер үк төзелмәдә берьюлы ике сыйфат дәрәҗәсенең күрсәткечләрен куллanудан гыйбарәт: ***куе*** сүзе төснең интенсивлыгын, тирәнлеген; ***-кылт/-келт, -гылт/-гелт*** кушымчасы исә билгеле сыйфатның тиешенчә булмавын, кимлеген белдерә. Бер исем бер үк вакытта ике килештә була алмаган кебек, бер сыйфат та бер үк вакытта ике дәрәҗә формасында була алмый. Шундый ук типтагы хаталар: ***бик төчкелт, нык сыеграк, үтә яшькелт***. Бер үк дәрәҗәнең ике чарасын берьюлы куллану да ялгыш.

Төсләрне белдергәндә ***куе*** компонентының язылышы турында: *к.* **ачык-кызыл**.

**КУЛАКЧЫЛЫ́К** *и. ялг. **Кулакчылыкта** гаепләү; дөр.:* **кулаклык**; *к.* **каллиграфчы**.

**КУЛБА́У** *и.* Кулбауга, кулбавы, кулбавына, кулбаулар; *ялг.:* **кулбауы, кулбауына**; *к.* **билбау**.

**КУЛЛАНМАЛЫ́К** *и. ялг. Физикада **кулланмалык** бастырып чыгару; дөр.:* **кулланма**; *к.* **каллиграфчы**.

**КУЛЛЫЛАНУ́** *ф. ялг.* ***Куллылану*** сүзе татар теленең сүз ясау калыпларына туры килсә дә, чынлыкта андый сүз дә, ул белдергән төшенчә дә юк; *к.* **куллылык**.

**КУЛЛЫЛЫ́К** *и. ялг.* ***Каты куллылык, йомшак куллылык, кәкре куллылык*** кебек тезмәләр составында килә. *Киресенчә, каты* ***куллылыкка*** *өйрәнгәннәр, камчы һәм күсәкне бик яхшы аңлыйлар*. В. Юныс. *Аның бу «каты* ***куллылык»*** *гамәлләре очраклы түгелдер, калебендәдер*. Шәһри Казан.

***Оста, алтын*** кебек сүзләр белән килә алмый. Мондый очракларда *алтын куллы булу, оста куллы булу* дип язу дөрес. *Өлкәннәрнең оста* ***куллылыгына*** *ис китәрлек*. Әлмәт таңнары. *Оештыручыларны хуҗаларның көчләре дә, алтын* ***куллылыклары*** *да кызыксындырмады, аларның балалар белән уртак тел таба алуларын тикшерделәр*. Яңарыш.

***Куллылык*** сүзе татар теленең сүз ясау калыпларына туры килсә дә, чынлыкта андый сүз дә, ул белдергән төшенчә дә юк. Сүзнең барлыкка килүе түбәндәгечә: ***каты куллы*** сүзтезмәсе лексикализация кичереп ***катыкуллы*** кушма сүзе барлыкка китерә, аның нигезендә кушымчалау ысулы белән ***катыкуллы+-лык катыкуллылык;*** шулай ук ***йомшаккуллылык, кәкрекуллылык*** һ.б.ш. Хәзерге вакытта алар аерым языла, әмма үзеннән алда килгән сыйфат белән генә тулы лексик мәгънә белдерә, шуңа күрә аларны кушып язу дөрес дип саныйбыз: ***катыкуллылык, йомшаккуллылык, кәкрекуллылык*** һ.б.ш. Кушып язмаган очракта алар урынына синтаксик вариантларын кулланырга мөмкин: *Өлкәннәрнең* ***остакуллы булуына*** *ис китәрлек* урынына ***оста кулларына*** *ис китәрлек* һ.б.ш. Шул ук принцип ***катыкуллылану*** һ.б.ш. типтагы сүзләргә карый.

**КУЛЬТИВЛАШТЫРУ́** *ф. ялг. Гаделлек идеяләрен* ***культивлаштыру***; *дөр.:* **культивацияләү, үстерү; нәрсәнең дә булса таралуына уңай шартлар тудыру, булышлык итү**; *к.* **стимуллаштыру**.

**КУЛЬТПОХО́Д** *и.* Культпоходка, культпоходы, культпоходына, культпоходлар; *ялг.:* **культ-походка, культ-походы, культ-походына, культ-походлар, культпохотка, культпохоты, культпохотына, культпохотка**; *к.* **гибрид,** *к. ш. ук* **фото-альбом**.

**КУЛЬТУРА-АГАРТУ́** *с. мәгъ. ялг. ҮК карарыннан өзек: «Авыл җирендә элек башланган* ***культура-агарту*** *биналары төзүне унынчы бишьеллык азагында тәмам итү өчен кирәкле чаралар күрергә»*. Р. Батулла. *Аннан соң Алабуга шәһәрендәге* ***культура-агарту*** *училищесының хор бүлегендә белем алган*. Сөембикә. *Көн*

*тәртибендә – колхозда **культура-агарту** эшенең торышы.* Татарстан яшьләре; *дөр.:* **культура агарту ...-ы/-е, культура һәм агарту ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**КУНАЧАЛА́У** *ф. ялг. Тавыклар көтәклектә **куначалаган;** дөр.:* **кунаклау**.

**КУНЫЧЛА́У** *ф. ялг. Бала итеген **кунычлау;** дөр.:* **куныч тегү**.

**КУПЕ́** *и.* Купега, купесы, купесына, купелар; *ялг.:* **купегә, купесе, купесенә, купеләр**. *Уфада Фәниярларга, төшеп, башка поездга утырырга кирәк булганга, **купедә** җыену ыгы-зыгысы башланды.* Ф. Яруллин. *Сөйләнә-сөйләнә үз **купесенә** килеп җиткәч кенә, сәхнәдәшләренең шаяртканнарын аңлап, рәхәтләнеп көлә башлый.* Р. Батулла; *к.* **алоэ**.

**КУРА́РЕ** *и.* Курарега, кураресы, курарресына, курарелар; *ялг.*: **курарегә, курaресе, курaресенә, курареләр**; *к.* **атташе**.

**КУТЮРЬЕ́** *и.* Кутюрьега, кутюрьесы, кутюрьесына, кутюрьелар; *ялг.:* **кутюрьегә, кутюрьесе, кутюрьесенә, кутюрьеләр**; *к.* **ателье**.

**КУШМЕТА́ЛЛ** *и.* Кушметаллга, кушметаллы, кушметаллына, кушметаллар; *ялг.:* **кушметалы, кушметалына, кушметалллар**; *к.* **металл**.

**КУЫ́КАЯКЛЫЛАР** *и. күпл. зоол. ялг*. Бөҗәкләр отряды; *дөр.:* **куыгаяклылар**; *к.* **ишекалды**.

**КУЫ́КУТЫЧАЛАР** *и. күпл. бот. ялг.* Үсемлекләр классы; *дөр.:* **куыгутычалар**; *к.* **ишекалды**.

**КҮЗӘНӘ́КАРА** *с. ялг*. Үсемлек яки хайван организмында тукыма күзәнәкләре арасында була торган. *Агачтагы су ике төргә бүленә: күзәнәк стенасын тотып торган күзәнәк суы һәм күзәнәкләр арасында иркен урнашкан **күзәнәкара** су.* Төзү материаллары. *Тукыма ул – охшаш төзелешле, бер үк функцияне башкаручы һәм үзара **күзәнәкара** матдә белән тоташкан күзәнәкләр төркеме*. Биология. *Аны гадәти крем өстеннән сылап куйсагыз, бит тирегезгә зыян килергә мөмкин, чөнки кершән порошогы **күзәнәкара** кушылмалар эченә кереп тула.* Шәһри Казан; *дөр.:* **күзәнәгара**; *к.* **ишекалды**.

**КҮП** *рәв. ялг.:* **күберәк**. *Тракторлар аттан **күберәк**.* А. Хәлим. *Самогонын кем **күберәк** йоткандыр, кем азырак, кырлы стакан өстәлне өч мәртәбә әйләнеп чыкты дигәндә ярты литрлы шешә бушап калды.* Р. Мөхәммәдиев. *Ә хәмер дигәннәре, көймәдә,*

*бензинга караганда да* ***күберәк*** *иде...* И. Кашфразыев; *дөр.:* **күбрәк**; *к.* **бай**.

**КҮПАВЫ́З** *и. зоол. ялг.* Суалчан; *дөр.:* **күбавыз**; *к.* **ишекалды**.

**КҮ́ПАЛЛАЛЫК** *и. ялг.* Күп аллалык; политеизм. *Сәяси карашлар кешеләрнең мәҗүси,* ***күпаллалык*** *чорындагы сәнгатендә үк урын тапкан булган инде.* К. Гыйззәтов. *Бу –* ***күпаллалыкка*** *керә, ә ислам дине, инде белгәнегезчә, бары тик бер Аллаһка гына табынырга чакыра.* Ф. Бәйрәмова. *Динебез үзенең башлангыч чорында* ***күпаллалыкка****, мәҗүсилеккә, мөшриклеккә каршы кискен көрәштә формалашкан.* Мәдәни җомга; *дөр.:* **күбаллалык**; *к.* **ишекалды**.

**КҮ́ПАТОМЛЫ** *с. ялг.* Берничә атомлы. *Полиэфир – күпнигезле кислотаны яки аның альдегидын* ***күпатомлы*** *спирт белән поликонденсацияләп табылган югары молекуляр кушылма.* Төзү материаллары. *Аны ясар өчен химик элемент –* ***күпатомлы*** *спирт кулланыла.* Intertat.ru; *дөр.:* **күбатомлы**; *к.* **ишекалды**.

**КҮПАЯ́К** *и. зоол. ялг.* Бөҗәк; *дөр.:* **күбаяк**; *к.* **ишекалды**.

**КҮ́ПАЯКЛЫЛАР** *и. күпл. зоол. ялг.* Бөҗәкләр классы; *дөр.:* **күбаяклы**; *к.* **ишекалды**.

**КҮ́ПИҖЕКЛЕ** *с. ялг.* Берничә иҗекле. *Биредә* ***күпиҗекле*** *татар сүзләрендә соңгы иҗектә «О», «Ө» сузыкларының кулланылмавы исәпкә алынды.* Фән һәм тел. *Ике шагыйрь иҗатыннан мәхәббәт темасына язылган әсәрләрне алсак, гадәттә, алар Тукайда – шул чорның* ***күпиҗекле*** *формаларында, антитезалы тасвирларга корылган ---.* Р. Харрасова; *дөр.:* **күбиҗекле**; *к.* **ишекалды**.

**КҮ́ПИРЛЕЛЕК** *и. ялг.* Берничә ирле булу. ***Күпирлелек*** *биредә егерменче гасырда тыелган.* Кызыл таң. *Күпхатынлылык дигән төшенчә бар икән,* ***күпирлелек*** *күренеше дә булсын.* Матбугат.ру. *Әгәр күпхатынлылыкны рәсмиләштерергә әйтсәгез,* ***күпирлелекне*** *дә рәсмиләштерергә тиешсез.* «Азатлык радиосы» сайты; *дөр.:* **күбирлелек**; *к.* **ишекалды**.

**КҮ́ПУРЫНЛЫ** *с. ялг.* Берничә урынлы. *Җиңүчеләргә спорт кирәк-ярагы һәм Татарстан Эчке эшләр министрлыгының махсус бүләге –* ***күпурынлы*** *палатка тапшырылды.* Мәгърифәт; *дөр.:* **күбурынлы**; *к.* **ишекалды**.

**КҮ́ПҮЛЧӘМЛЕ** *с. ялг.* Берничә үлчәмле. *Шулар арасында пленар утырышларда яңгыраган берничә докладны – КДАТУның*

*фәнни эшләр буенча проректоры Альфред Сөләймановның **күпүлчәмле** мәгълүматларны анализлауда проекцион ысуллар куллануга --- багышланган чыгышларны әйтеп китәргә мөмкин.* Фән һәм тел. *Фәнни хезмәтләре автоматик идарә итү системнары теориясенә, --- **күпүлчәмле** стационар булмаган идарә итү системнарның динамик характеристикаларны төзү методларына карый*. Википедия; *дөр.:* **күбүлчәмле**; *к.* **ишекалды**.

**КҮ́ПҮЛЧӘНЕШЛЕ** *с. ялг*. Берничә үлчәнешле; *дөр.:* **күбүлчәнешле**; *к.* **ишекалды**.

**КҮ́ПУКЛАДЛЫ** *с. ялг*. Берничә укладлы; *дөр.:* **күбукладлы**; *к.* **ишекалды.**

**КҮРЕ́К** I *и*. Матурлык, гүзәллек; *ялг.:* **күреге, күрегенә**. *Ил **күреге**, урман **күреге**, дөнья **күреге**; дөр.:* **күреккә, күрке, күркенә**; *к.* **милек**; *чаг.:* **зәвык**.

**КҮРЕ́К** II *и*. Эшкәртелгән хайван тиресе; өрдерү җайланмасы; *ялг.:* **күрке, күркенә**. *Бозау **күрке**, тимерче **күрке**, гармун **күрке**; дөр.:* **күреккә, күреге, күрегенә**; *к.* **зәвык**; *чаг.:* **милек**.

**КҮРШЕДӘ́Ш** *с. ялг. Мирас генетик булмаган очракта, **күршедәш** ул телләрнең озак вакыт дәвам иткән элемтәләре нәтиҗәләренә кайтып калачак (я гади, санга-йөзгә бер очраучы алынмаларны гына тәшкил итәчәк; я бер үк вакытта алынмаларны да, телләрнең ассимиляцияләнү нәтиҗәләрен дә – аларның адстрат, субстрат, суперстрат, гиперстрат, креолизация кебек төрләрен – үз эченә алачак).* Фән һәм тел; *дөр.:* **күрше**; *к.* **каллиграфчы**.

**КҮЧМӘЧЕЛЕ́К** *и. ялг. Бериш язучылар, тарихчылар һәм сәяхәтчеләр **күчмәчелекне** чиктән тыш тәнкыйтьләгәннәр ---.* Р. Фәхретдинов. *Ягъни утрак тормышта яшәгән Европа илләре, янәсе, алдынгы цивилизацияле дәүләтләр; **күчмәчелектә** гомер кичергән Азия халыклары исә – артта калган, хәтта кыргый варварлар.* Ф. Урманче. *Ул вакытта кайбер төрки кабиләләр, Болгар җирләрендә җәйләп, Көньяк Казагыстан (Җидесу) өлкәсендә кышлап, **күчмәчелек** белән көн иткәннәр.* Р. Әхмәтьянов; *дөр.:* **күчмәлек**; *к.* **каллиграфчы**.

**КҮЧҮЧЕЛЕ́К** *и. ялг. **Күчүчелек** борынгы төркиләрнең тормыш рәвеше булган; дөр.:* **күчмәлек**.

**КЫЕКАВЫ́З** *и. зоол. ялг*. Балык; *дөр.:* **кыегавыз**; *к.* **ишекалды**.

**КЫЕ́КАВЫЗЛЫЛАР** *и. күпл. зоол. ялг.* Балыклар семьялыгы; *дөр.:* **кыегавызлылар**; *к.* **ишекалды**.

**КЫЗА́У** *и.* Кызауга, кызавы, кызавына, кызаулар; *ялг.:* **кызауы, кызауына**; *к.* **билбау**.

**КЫЗГЫ́ЛТ-САРЫ** *с. ялг.* ***Кызгылт-сары** юллы буй-буй кофта, шундый ук төстәге киң балаклы ыштаннар киеп, кылыч аскан егетләрне күргәч, үзеңнең XX гасырда яшәгәнеңне онытып куясың*. М. Мәһдиев. *Бер кулына Рамиләне күтәреп, икенче кулы белән арбасын тартып, киң, биек такта баскычтан **кызгылт-сары** такта ишеккә таба менгәндә, Лениза нык дулкынланган иде.* М. Маликова; *дөр.:* **кызгылт сары**.

Төсләрне белдергән ике сыйфат бергә килгәндә, әгәр алар арасында тезүле мөнәсәбәт булмаса, беренче сыйфат икенчесенең аергычы булып тора, төп төснең өстәмә төсмерен белдерә һәм ***ачык кызыл*** очрагындагы кебек үк аерым языла.

**КЫЙММӘ́Т** *с. ялг.:* **кыйммәтерәк**. *Резидә ханым, тормыш бизмәнендә акча, сезнең өчен һәр изге эшләргә караганда да, **кыйммәтерәк** тоела түгелме?..* Яшел Үзән. *Нәтиҗәдә балалар бакчасында ул көннәрдә яшелчә, җиләк-җимешне күбрәк бирергә, яисә **кыйммәтерәк** торган, әйтик сөт ризыклары бирергә мөмкиннәр*. Актаныш муниципаль районының мәгълүмат-мөхәррият үзәге сайты. *Андый комплекстан алынган ягулык газы, үзкыйммәте буенча, газпром газыннан **кыйммәтерәк** булмый.* Матбугат.ру; *дөр.:* **кыйммәтрәк**; *к.* **бай**.

**КЫЛА́У** *и.* Кылауга, кылавы, кылавына, кылаулар; *ялг.:* **кылауы, кылауына**; *к.* **билбау**.

**КЫЛДА́У** *и.* Кылдауга, кылдавы, кылдавына, кылдаулар; *ялг.:* **кылдауы, кылдауына**; *к.* **билбау**.

**КЫРА́У** *и.* Кырауга, кыравы, кыравына, кыраулар; *ялг.:* **кырауы, кырауына**. *Гомер көзләремнең ак **кырауы** Чәчләремә төшә сызылып*. Ф. Дәүләтгәрәева. *Менделеев районы Иске Гришкино мәктәбе дә – оптимизация «**кырауына**» эләгеп, унберьеллыктан тугызъеллыкка калдырылган мәктәп*. Туганайлар; *к.* **билбау**.

**КЫРША́У** *и.* Кыршауга, кыршавы, кыршавына, кыршаулар; *ялг.:* **кыршауы, кыршауына**. *Куриловка тәгәрмәчләре тимердән генә эшләнә, аны ясаганда агач материаллары кулланылмый, тәгәрмәчнең тышкы **кыршауы**, агач тәгәрмәчнекеннән икели диярлек тар ---*. В. Ильясов. *Иркенлеге чиксез булса, ireклегенең*

***кыршауы** бар*. Самара өлкәсе татарларының официаль сайты; *к.* **билбау**.

**КЫРЫКАЯ́К** *и. зоол. ялг.* Бөҗәк; *дөр.:* **кыргаяк**; *к.* **ишекалды**.

**КЫРЫКАЯКЛА́Р** *и. күпл. зоол. ялг.* Бөҗәкләр классы; *дөр.:* **кыргаяклар**; *к.* **ишекалды**.

**КЮРЕ́** *и.* Кюрега, кюресы, кюресына, кюрелар; *ялг.:* **кюрегә, кюресе, кюресенә, кюреләр**; *к.* **атташе**.

**ЛА́ГЕРЬ** *и.* Лагерьга, лагере, лагерена, лагерьлар; *ялг.:* **лагерьгә, лагеренә, лагерьләр; лагергә, лагерләр; лагерга, лагеры, лагерына, лагерлар**. *Хөкем урыны итеп иң куркыныч дәүләт җинаятьчеләре сөрелә торган Рогервик **лагеры** билгеләнә*. Г. Мөхәммәтшин. *Җәйге **лагерга** сыер саварга мин төшеп киттем*. Мәйдан.

Рус теленнән һәм рус теле аркылы кергән алынма сүзләрнең **-рь** га беткәннәрен төрләндергәндә III зат тартым кушымчасының алгы рәт варианты кушыла. Ләкин аннан соң килгән кушымчаларда яки башка категорияләр белән төрләндергәндә, арткы рәт кушымчалары ялгана. **-ть, -шь, -сь, -зь, -чь** ларга беткән сүзләр дә шул ук закончалыкка буйсына.

Ай атамалары татар теленә күптәннән кергәнгә күрә, алар фонетик яктан күбрәк үзләштерелгән, аларның язылышында вариантлылык күзәтелә; *к.* **январь**.

**ЛЕ́ГИНСЫ** *и.* Легинсыга, легинсые, легинсыена, легинсылар; *ялг.:* **легинс, легинсысы, легинсысына, легинслар**; **легинса, легинсасы, легинсасына, легинсалар**. *1988 елда Шанель Йортының яңа модельеры Лагерфельд подиумга **легинслар** чыгара.* Саба таңнары; *к.* **шорты**.

**ЛЕГИРЛА́У** *ф.* Металлны махсус эшкәртү.

Сүз дөрес язылган һәм ***реагирлау*** мәкаләсендә китерелгән кагыйдә бу сүзгә кагылмый, чөнки сүздәге ***-ир реагирлау*** сүзендәге кебек рус теле суффиксы түгел, ә сүзнең нигезенә карый. ***Визирлау*** (визир белән үлчәү мәгънәсендә генә!) һәм ***плакирлау*** сүзләре шулай ук дөрес; *чаг.:* **реагирлау**.

**ЛЕГИРЛАШТЫРУ́** *ф. ялг. Корычны **легирлаштыру**; дөр.:* **легирлау**; *к.* **стимуллаштыру**.

**ЛЕ́ДИ** *и.* Ледига, ледие, ледиена, ледилар; *ялг.:* **ледисы, ледисына, ледигә, ледисе, ледисенә, ледиләр**. *Президент*

*Медведев дәүләтара очрашуларда йөргән арада Россиянең баш* ***ледисы*** *Светлана Медведева Россия Федерациясенең Әнкара бөек илчелегендә «Рус халык әкиятләре – төрек телендә» китабын таныту җыелышына иштирак итте.* Татар-информ; *к.* **бигуди**.

**ЛЕЙКОПЛА́СТЫРЬ** *и.* Лейкопластырьга, лейкопластыре, лейкопластырена, лейкопластырьлар; *ялг.:* **лейкопластырьгә, лейкопластыренә, лейкопластырьләр**; *к.* **лагерь**.

**ЛЕОПА́РД** *и.* Леопардка, леопарды, леопардына, леопардлар; *ялг.:* **леопартка, леопарты, леопартына, леопартлар**; *к.* **гибрид**.

**ЛИ** *и.* Лига, лие, лиена, лилар; *ялг.:* **лисы, лисына, лигә, лисе, лисенә, лиләр**; *к.* **бигуди**.

**ЛИБЕРА́Л** *и.* Либерализм карашларындагы кеше; *ялг.:* **либерал карашлар**, **партия**, **либерал хәрәкәт, либерал фирка**. *Мәскәүдәге белгеч Владимир Прибыловский, «Русиянең сәяси элитасындагы* ***либерал*** *караштагылар, соңгы айларда Медведев чәчәге шиңәр дип үз өметләрен Кудринга баглый башлаган иде», дип белдерә.* Н. Алан. *2007 елдагы сайлауда «Ватандашлар платформасы» исемле бизнес яклы* ***либерал*** *фирка җиңде.* А. Кормаш; *чаг.:* **либераль**; *к.* **вокаль**.

**ЛИБЕРАЛ-ДЕМОКРА́ТИК** *с. ялг. Алар Сергей Иванов белән инде шактый тузган* ***либерал-демократик*** *сәяси партиясе арбасын әйтерсең лә Иван Крыловның мәгълүм әкиятендәгечә төрле тарафка өстери.* Шәһри Казан. *Үзбәкстанның* ***либерал-демократик*** *партиясе 2004 елны узган парламент сайлауларында иң күп урынны алуга иреште.* «Азатлык радиосы» сайты; *дөр.:* **либераль-демократик**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ЛИБЕРА́ЛЬ** *с.* Либерализмга бәйле; йомшак; **либераль хәрәкәт, либераль мөнәсәбәт, либераль карашлар**, **либераль партия**, **либераль хәрәкәт, либераль фирка**; *чаг.:* **либерал**; *к.* **вокаль**.

**ЛИБЕРАЛЬ-ДЕМОКРА́Т** *с. ялг. Коммунист һәм* ***либераль-демократ*** *лидерлары теркәлеп өлгергән.* «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе сайты; *дөр.:* **либерал-демократ**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ЛИБЕРАЛЬ-ДЕМОКРА́ТИЯ** *с. ялг. Дәүләт Думасына сайлауда катнашканнарның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «Бердәм Россия» фиркасенә – 62,21%;* ***либераль-демократия*** *фиркасенә – 14,06%; коммунистлар фиркасенә – 11,7%; «Гадел Россия»гә – 7,39%.* Татар-информ; *дөр.:* **либераль-демократик, либераль демократия ...-ы/-е, либерал-демократлар ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ЛИБЕРАЛЬ-ИКЪТИСА́Д** *с. ялг. Шулай итеп, «Мин карашларым белән* ***либераль-икътисад*** *юнәлешендә торган кеше» дип белдереп, Владимир Путин Русия халкын кырыс капитализм шартларына җайлашырга мәҗбүр иткән сәясәтне дәвам итүен ачык раслады*. Кызыл таң; *дөр.:* **либераль-икътисади** яки **либераль икътисад ...-ы/-е**.

Парлы сүз тезүле бәйләнеш белән ясала, ягъни ике сүз дә бер үк сүз төркеменә карарга тиеш: исем+исем, сыйфат+сыйфат һ.б. Төрле сүз төркемнәренә караган сүзләр арасында тезүле бәйләнеш була алмый, димәк алар сызыкча аша язылмый. Аларны сызыкча аша язу рус теленнән ялгыш калька ясау нәтиҗәсендә барлыкка килә.

**ЛИКВИ́Д** *и*. Ликвидка, ликвиды, ликвидына, ликвидлар; *ялг.:* **ликвитка, ликвиты, ликвитына, ликвитлар**; *к*. **гибрид**.

**ЛИМОНА́Д** *и*. Лимонадка, лимонады, лимонадына, лимонадлар; *ялг.:* **лимонатка, лимонаты, лимонатына, лимонатлар**; *к*. **гибрид**.

**ЛИПИ́Д** *и*. Липидка, липиды, липидына, липидлар; *ялг.:* **липитка, липиты, липитына, липитлар**; *к*. **гибрид**.

**ЛОГОПЕ́Д** *и*. Логопедка, логопеды, логопедына, логопедлар; *ялг.:* **логопетка, логопеты, логопетына, логопетлар**; *к*. **гибрид**.

**ЛОКОМОБИ́ЛЬ** *и*. Локомобильгә, локомобиле, локомобиленә, локомобильләр; *ялг.:* **локомобильга, локомобилена, локомобильлар**; *к*. **апрель**.

**ЛОМБА́РД** *и*. Ломбардка, ломбарды, ломбардына, ломбардлар; *ялг.:* **ломбартка, ломбарты, ломбартына, ломбартлар**; *к*. **гибрид**.

**ЛОСИ́НЫ** *и*. Лосиныга, лосиные, лосиныена, лосинылар; *ялг.:* **ласин, лосинысы, лосинысына, лосиннар; лосина, лосинасы, лосинасына, лосиналар**. – *Төшәм, төшми ди менә, көтеп тор, син итәк тутырып, – ул Такинәнең* ***лосинасына*** *ымлап күрсәтте, – ыштан тутырып бала тапканга мин гаеплемени, синең балаларны хөкүмәт карый, мин көнбагыш сатып тамак туйдырам*. Х. Мөдәррисова. *Яшь буынның бөтен тәненә ябышып торган,* ***лосинаны*** *хәтерләткән чалбар киюе һәм башка сәер кыланышларын «субкультура» төшенчәсе белән аңлатырга мөмкин*. Кызыл таң. *Икенчесе: «Минем өчен колхоз – тигровый бизәкле* ***лосина*** *киеп урамда йөрүче кеше», – дип яза*. Шәһри Казан. *Моннан тыш кызлар туникалар яки озын футболкалар белән кию өчен ачык төстәге* ***лосиналар*** *да сайлый ала*. Ватаным Татарстан; *к*. **шорты**.

**ЛЬЕ** *и.* Льега, льесы, льесына, льелар; *ялг.:* **льегә, льесе, льесенә, льеләр**; *к.* **ателье**.

**МАДЕМУАЗЕ́ЛЬ** *и.* Мадемуазельгә, мадемуазеле, мадемуазеленә, мадемуазельләр; *ялг.:* **мадемуазельга, мадемуазелена, мадемуазельлар**; *к.* **апрель**.

**МАЗЬ** *и.* Мазьга, мазе, мазена, мазьлар; *ялг.:* **мазьгә, мазенә, мазьләр**. *Дөрес, черкиләргә каршы хәзер төрле **мазьләр**, аэрозольләр кулланырга мөмкин*. Кызыл таң. *Сеңер тартылганда һәм каты бәрелгәндә составына бал корты һәм елан агуы кергән җылытучы **мазьләрне** файдаланырга була*. Өмет. *Гөлфирә кулга тоттырган **мазьне** эндәшми генә сыладым да, аркасына полиэтилен ябып куйдым*. Матбугат.ру; *к.* **повесть**.

**МАКРАМЕ́** *и.* Макрамега, макрамесы, макрамесына, макрамелар; *ялг.:* **макрамегә, макрамесе, макрамесенә, макрамеләр**; *к.* **атташе**.

**МАКСА́Т** *и.* Теләк, хая, морад; *ялг.:* «цель» мәгънәсендә (атуда). *Һәр снайперга **максат** беркетелгән. --- **Максат** урыныннан күчә, снайпер да күзләре белән күчә.* Татарстан яшьләре; *дөр.:* **мишень, мәрә, мәрәй, тәмек**.

**МА́КСИ** *и.* Максига, максие, максиена, максилар; *ялг.:* **максисы, максисына, максигә, максисе, максисенә, максиләр**; *к.* **бигуди**.

**МАМЫ́КАШАР** *и. зоол. ялг.* Бөҗәк; *дөр.:* **мамыгашар**; *к.* **ишекалды**.

**МАНГО́ЛЬД** *и.* Мангольдка, мангольды, мангольдына, мангольдлар; *ялг.:* **мангольтка, мангольты, мангольтына, мангольтлар**; *к.* **гибрид**.

**МА́НСИ** *и.* Мансига, мансие, мансиена, мансилар; *ялг.:* **мансисы, мансисына, мансигә, мансисе, мансисенә, мансиләр**; *к.* **бигуди**.

**МАРГИНА́Л** *и.* Җәмгыятьтәге яңа шартларга ияләнә алмаган, җәмгыять тарафыннан кабул ителмәгән, читкә этелгән кеше; *ялг.:* **маргинал төркем, маргинал шәхес**. ***Маргинал** төркемнәр интернетта шактый.* «Азатлык радиосы» сайты; *чаг.:* **маргиналь**; *к.* **вокаль**.

**МАРГИНА́ЛЬ** *с.* Җәмгыятьтәге яңа шартларга ияләнә алмаган; гомуми әхлакый һ.б. нормаларны кабул итә алмый торган; җәмгыять тарафыннан кабул ителмәгән, читкә этелгән; *чаг.:* **маргинал**.

**МАРИНА́Д** *и.* Маринадка, маринады, маринадына, маринадлар; *ялг.:* **маринатка, маринаты, маринатына, маринатлар**; *к.* **гибрид**.

**МАРМЕЛА́Д** *и.* Мармеладка, мармелады, мармеладына, мармеладлар; *ялг.:* **мармелатка, мармелаты, мармелатына, мармелатлар**; *к.* **гибрид**.

**МАСКАРА́Д** *и.* Маскарадка, маскарады, маскарадына, маскарадлар; *ялг.:* **маскаратка, маскараты, маскаратына, маскаратлар**; *к.* **гибрид**.

**МАТБУГАТ-АТТАШЕ́** *и. ялг. Җырның сүзләрен Санкт-Петербургта үтәчәк саммит өчен Россия командасы* ***матбугат-атташесе*** *Наталья Макуни махсус язган.* Татар-информ.

Русча ***пресс-атташе*** сүзен ялгыш, калька рәвешендә тәрҗемә итү нәтиҗәсендә килеп чыккан; *дөр.:* **матбугат атташесы**.

**МАТДӘВИ** *с. ялг. Аларның берсендә* ***матдәви*** *кыйммәтләр алдан йөрсә, икенчесендә рухи кыйммәтләр өстенлек итә. Бу ике система бер-берсенә көндәш булсалар да, күп очракта үзара каршылык кискен төс алса да, мәҗбүри рәвештә килешеп, дөньядагы тотрыксыз тигезләнешне саклыйлар.* Ә. Илдус; *дөр.:* **матди**; *к.* **мәгълүмати**.

**МАТЕРИАЛЛАШТЫРУ́** *ф. ялг. Әгәр дә бу сүзләрне* ***материаллаштырырга*** *мөмкин булса, алар ярдәмендә барлык иске юлларны төзекләндереп булыр иде.* Алга. *Бу инде, музыкадан татарча беренче әлифба буларак, моңа хәтле әйтелгән идеяләрне* ***материаллаштырып****, халыкка җиткерүдә җитди бер адым иде ---.* Казан утлары; *дөр.:* **материальләштерү**.

**МӘГЪЛҮМАТИ́** *с. ялг. Башта Миңнехановның матбугат хезмәте,* ***мәгълүмати*** *ачыклыкка килгәндә, үзен һөнәри яктан яхшырак итеп күрсәтер дигән өмет бар иде.* Н. Алан. *Чынлап та, гомуми һәм тоталь* ***мәгълүмати*** *вакуум чорында җитмешенче еллардагы совет яшьләре арасында Вашингтоннан яңгыраган әлеге популяр музыкаль тапшыруны кем хәтерләми икән?* Т. Кәримов.

Татар теленең үзендә сүз ясау һәм төрләндерү кушымчаларының зур бер системасы бар. Телне саклау һәм үстерүнең төп принцибы беренче чиратта телнең үз мөмкинлекләреннән файдалануны шарт итеп куя. Чит телнең сүзьясагыч һәм төрләндергеч чараларын куллану бу принципны тупас бозу булып тора. Гарәп яки

фарсы теленнән әзер килеш кергән алынма сыйфатларда гына ***-и*** кушымчасы урынлы, чөнки ул үз җирлегендә – гарәп телендә гарәп кушымчасы белән ясалган: *сихри, милли, җитди* һ.б.ш. Әмма әлеге сүзләрнең дә кайберләре, мәс.: *фикри, хәяти* һ.б.ш. искергән, башка вариантлар белән алмашынган булуы сәбәпле, хәзерге татар әдәби телендә стилистик кулланышы чикле. Гомумән, югарыда әйтелгәнчә, өстенлек һәрвакыт татар калыбында ясалган чараларга бирелергә тиеш; *дөр.:* **мәгълүмат агентлыгы, мәгълүмат чыганагы, мәгълүмат ярдәме**.

**МӘГЪЛҮМАТЛА́Р** *и. күпл. ялг. Денис авылы турында күп еллар дәвамында җыелган **мәгълүматлар** мәктәп музеенда саклана*. Г. Шәйхи. *Бүгенге көндә безгә өлкә бердәм интернет ресурс кирәк, яшьләргә кагылышлы булган **мәгълүматлар** шунда туплана барыр иде.* Яңарыш; *дөр.:* **мәгълүмат туплау, мәгълүмат урнаштыру** һ.б.

*Мәгълүмат, тәэминат, гадәләт, тәэсорат* кебек гарәп алынмалары күплек сан кушымчасы кабул итмиләр, чөнки башлыча абстракт төшенчә белдерәләр һәм «нәрсәнеңдер күплеге, җыелмасы, тупланмасы» семасын эченә алган җыйма исем булып торалар.

**МӘГЪРИФӘТИ́** *с. ялг. Басма китап – мәдәни, **мәгърифәти** һәм, гомумән, иҗтимагый яктан бик зур алгарыш булып тора*. Мәдәни җомга. *Көньяк Казахстанда Сыр-Дәрья буенда 1500 елдан артык тарихы булган һәм элек-электән ислам дөньясының мөһим дини, **мәгърифәти**, мәдәни үзәге булып торган Төркестан каласы бар*. Мәйдан. *Әлеге ханымнарда халкыбызның җәүһәри, мирасы, **мәгърифәти** уңганлыгы, зыялылыгы буыннардан-буыннарга күчеп баруы милләтебезнең акыллы киләчәгенә олы ышаныч тудыра.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар; *дөр.:* **мәгърифәт үзәге, мәгърифәт эшчәнлеге**; *к.* **мәгълүмати**.

**МӘДӘНИ́** *с. ялг.:* **мәдәниерәк**. *Бер карасаң, пәйгамбәр яшәгән гасыр белән чагыштырганда мәгърифәтлерәк, **мәдәниерәк** заман.* А. Тимергалин; *дөр.:* **мәдәнирәк**; *к.* **бай**.

**МӘДӘНИ-АГАРТУ́** *с. ялг. Менә шул акчага ай буе ашап-эчеп тор, өс-баш та ал, йорт кирәк-ярагы да, «дәү әни» дип көтеп торган бәгырь кисәкләрең янына хәл белергә дә барып кайт, чирләп китсәң, дару-уколлар, газета-журнал, театр-концерт кебек **мәдәни-агарту** гамәлләренә дә өлеш чыгар, ай буе юлда йөрергә дә калдыр.* Безнең гәҗит. *Ә әнинең заманында*

***мәдәни-агарту*** *училищесына укырга кирәргә теләге булган.* Өмет; *дөр.:* **мәдәни агарту ...-ы/-е**; **мәдәният һәм агарту ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**МӘДӘНИ-КӨ́НКҮРЕШ** *с. ялг. Ул корылмаларга бару юлында урнашкан кайбер* ***мәдәни-көнкүреш*** *биналарының торышы Илбашның кәефен җибәрде.* Мәдәни җомга. *Чөнки слётка килүчеләрне матур, барлык уңайлыклары булган йортлар,* ***мәдәни-көнкүреш*** *объектлары каршылады.* Татарстан яшьләре; *дөр.:* **мәдәният-көнкүреш ...-е/-ы; мәдәният һәм көнкүреш ...-е/-ы**; *к.* **либераль-икътисад**.

**МӘҖБҮРИЯТЛЕ́К** *и. ялг.* ***Мәҗбүриятлек*** *туган вакытта, хәрам әйбернең хәрамлыгы бетә.* Безнең гәҗит. *Каләм әһеле үз милләтен ихлас мәхәббәт белән яратырга тиеш,* ***мәҗбүриятлек*** *белән түгел, бәлки чын күңеллән булганда гына кыйммәт шул.* Казан утлары; *дөр.:* **мәҗбүрият, мәҗбүрилек**; *к.* **каллиграфчы**.

**МӘМИ́** *и.* Мәмигә, мәмие, мәмиенә; *ялг.:* **мәмисе, мәмисенә**; *к.* **әби**.

**МӘНИ́** *и.* Мәнигә, мәние, мәниенә; *ялг.:* **мәнисе, мәнисенә**; *к.* **көрси**.

**МӘХӘЛЛӘ́И** *с. ялг.* ***Мәхәлләи*** *икамәте Казанда Печән базарына якын бер урында икән.* Г. Камал; *дөр.:* **мәхәллә ...-ы/-е, мәхәллә мәхкәмәсе**; *к.* **мәгълүмати**.

**МӘХӘЛЛИ́** *с. ялг. --- Англиягә мөлхак калып, бары Ирландиянең үзенә башка бер* ***мәхәлли*** *парламент сорау тарафында иде.* С. Максуди. *Һәр милләт әфрадыннан* ***мәхәлли*** *һәм гомуми мәхкәмәләргә төрле кагыйдәләр һәм ул мәхкәмәләрдә төрле төрле милләт әфрадына җибәрелә торган кагыйдәләр шул милләтнең телендә язылырга тиешледер.* Гасырлар авазы; *дөр.:* **мәхәллә ...-ы/-е, мәхәллә мәхкәмәсе**; *к.* **мәгълүмати**.

**МӘШГҮ́ЛЬ** *хәб. сүз ялг. Үз дөньябыз белән* ***мәшгүль*** *булыйк, Яхшылык бит тормыш бизәге!* К. Фатыйхова-Бәдретдинова. *Анда һәркем үз биографиясе, тормышта ирешкән уңышлары, балалары, оныклары турында, бүген ни белән* ***мәшгүль*** *булуын сөйли.* Мәйдан; *дөр.:* **мәшгуль**.

**МЕ́БЕЛЬ** *и.* Мебельгә, мебеле, мебеленә, мебельләр; *ялг.:* **мебельга, мебелена, мебельлар**. *Бүген иң авырткан проблемалары –* ***мебельның*** *искерүе.* Өмет. *Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов билгеләп узганча, бәясе һәм сыйфаты оптималь*

*килешкән **мебельга** өстенлек биреләчәк.* Казан мэриясенең рәсми порталы; *к.* **апрель**.

**МЕГА-ВАКЫЙГА́** *и. ялг. Сораштыруда катнашкан шәһәр кешеләренең шактый өлеше Универсиада кебек **мега-вакыйга** Казанга туристларны җәлеп итәргә сәләтле дип саный.* 2013 Универсиадасы блогы; *дөр.:* **мегавакыйга**; *к.* **фото-альбом**.

**МЕГА-ГРА́НТ** *и. ялг. **Мега-грантлар** программалары кысаларында илдә халыкара дәрәҗәдәге 200 дән артык лаборатория ачылган.* Кызыл таң; *дөр.:* **мегагрант**; *к.* **фото-альбом**.

**МЕГА-ДИСКОТЕ́КА** *и. ялг. Татар яшьләре көтеп алган **мега-дискотека** 30 нчы сентябрь кичендә «Эрмитаж» (Ривьера) клубында узачак*. Кәеф ничек?; *дөр.:* **мегадискотека**; *к.* **фото-альбом**.

**МЕГА-ДОМИНО́** *и. ялг. «АВТОВАЗ» ААҖ эре спонсор павильоны кунакларга радио белән идарә ителә торган машиналар ярышында катнашырга, **мега-домино** һәм бик зур «пятнашка» уйнарга, викториналарда катнашырга тәкъдим итә*. Идел; *дөр.:* **мегадомино**; *к.* **фото-альбом**.

**МЕГА-ЙОЛДЫ́З** *и. ялг. Әнисен ул дөньяда үзе күргән барлык тереклектән өстен күрә, президентлар, патшалар да, **мега-йолдызлар** да, арыслан-бүреләр дә аңа – Анага буйсына*. Сабантуй; *дөр.:* **мегайолдыз**; *к.* **фото-альбом**.

**МЕГА-КВЕ́СТ** *и. ялг. 31 майда Уфада **мега-квест** узды.* Кызыл таң; *дөр.:* **мегаквест**; *к.* **фото-альбом**.

**МЕГА-КИЧӘ́** *и. ялг. Универсиада паркына һәр теләгән кеше керә алса, **мега-кичәләрдә** бары тик аккредитацияле бейджикларда Volunteer язуы булганнар гына катнаша ала.* 2013 Универсиадасы блогы; *дөр.:* **мегакичә**; *к.* **фото-альбом**.

**МЕГА-КО́МПЛЕКС** *и. ялг. Аның фикеренчә, зур проектларны гамәлгә ашыру, **мега-комплекслар** төзү, аерым районнарда фермаларны реконструкцияләү әлегә авыл хуҗалыгы җитештерүен арттыруга китерми*. Кызыл таң; *дөр.:* **мегакомплекс**; *к.* **фото-альбом**.

**МЕГА-ПОПУЛЯ́Р** *с. ялг. Әйтик, мәсәлән, башка алып баручыга кунакка **мега-популяр** шәхесләр килсә, минем тапшыруыма әле сәхнәдә беренче адымнарын гына ясаучы артистлар килә*. Матбугат.ру. *Бүген татар һәм башкорт эстрадасының **мега-популяр** җырчысы Радик Юльякшинның туган көне*. Сабантуй; *дөр.:* **мегапопуляр**; *к.* **фото-альбом**.

**МЕГА-ПРЕДПРИЯ́ТИЕ** *и. ялг. Киләсе елда химик җитештерүгә, урман эшкәртүгә, машина төзүгә бәйле берничә* ***мега-предприятие*** *төзи башлаячакбыз.* Кызыл таң; *дөр.:* **мегапредприятие**; *к.* **фото-альбом**; *к. ш. ук* **звание**.

**МЕГА-ПРОЕ́КТ** *и. ялг. Инвесторлар да сәнәгать секторындагы үз* ***мега-проектларын*** *тәкъдим итүне үткәрде.* Рәсми Татарстан. *Барселона архитекторы Хосе Асебильо әйтүенә караганда, «ЭКСПО – 2020»* ***мега-проектына*** *әзерлек барышында Екатеринбург инфраструктурасын ныклап үзгәртәчәк.* Татар-информ; *дөр.:* **мегапроект**; *к.* **фото-альбом**.

**МЕГА-РЕАЛИ́СТИК** *с. ялг. Рон Мьюек* ***мега-реалистик*** *скульптураларны ясый.* Күрше; *дөр.:* **мегареалистик**; *к.* **фото-альбом**.

**МЕГА-СПО́РА** *и. ялг. Микроспорангийда микроспоралар барлыкка килә, алардан ата гаметофит формалаша, ә мегаспорангийда* ***мега-споралар*** *өлгерә, алардан ана гаметофит үсеш ала.* Википедия; *дөр.:* **мегаспора**; *к.* **фото-альбом**.

**МЕГА-ТАНЫЛГА́Н** *с. ялг. Мин үземне IT өлкәсендә* ***мега-танылган*** *шәхес димәс идем, ниндидер танылганлык бар, әлбәттә.* Intertat.ru; *дөр.:* **мегатанылган**; *к.* **фото-альбом**.

**МЕГА-УНИВЕРСИТЕ́Т** *и. ялг. Хөкүмәтнең тиешле блогына* ***мега-университетлар*** *булдыру мәсьәләсен уйларга кушылачак.* Кызыл таң; *дөр.:* **мегауниверситет**; *к.* **фото-альбом**.

**МЕГА-ҮЗӘ́К** *и. ялг. Киләчәктә Русия халкы хәзерге кебек 83 аерым төбәктә түгел, ә 20 эре индустриаль* ***мега-үзәк*** *тирәсенә тупланып яшәргә мөмкин.* Н. Алан; *дөр.:* **мегаүзәк**; *к.* **фото-альбом**.

**МЕГА-ФЕ́РМА** *и. ялг. «Восток» хуҗалыгында да яңа* ***мега-ферма*** *сафка баскач, җитештерү нык артты.* Хезмәт даны; *дөр.:* **мегаферма**; *к.* **фото-альбом**.

**МЕГА-ШӘҺӘ́Р** *и. ялг. Аның максаты каланы дөньяның* ***мега-шәһәрләренең*** *берсе итү.* Татар-информ; *дөр.:* **мегашәһәр**; *к.* **фото-альбом**.

**МЕГА-ШИРКӘ́Т** *и. ялг. КамАЗ кебек* ***мега-ширкәт*** *урнашкан Чаллының Әлмәттән калышуы күзгә ташлана.* «Азатлык радиосы» сайты; *дөр.:* **мегаширкәт**; *к.* **фото-альбом**.

**МЕГА-ШО́У** *и. ялг. Быелгы* ***мега-шоуда*** *30 дан артык мегайолдызның чыгышыннан тыш, күп бүләкләр дә булачак.* Кәеф ничек?; *дөр.:* **мегашоу**; *к.* **фото-альбом**.

**МЕГА-ЭКРА́Н** *и. ялг.* ***Мега-экран*** *2013 елгы Универсиаданың ачылыш һәм ябылу тантанасын, футбол матчларын, шулай ук реклама роликларын трансляцияләячәк.* Саба таңнары; *дөр.:* **мегаэкран**; *к.* **фото-альбом**.

**МЕДА́ЛЬ** *и.* Медальгә, медале, медаленә, медальләр; *ялг.:* **медальга, медалена, медальлар**. ***Медальны*** *яки орденны бирәр администратор яисә проект катнашучылары бирә ала*. Википедия. *Шул рәвешле, без икебез дә, орден һәм* ***медальлар*** *белән бүләкләнгән ике сугыш ветераны, үз Ватаныбызда эзәрлекләнә торган куркыныч җинаятьчеләр булып киттек*. Р. Мөхәммәдиев. *Нәтиҗәдә Италия командасы Олимпиадада катнашкан капиталистик илләр арасында* ***медальлар*** *саны буенча беренче иде һәм монда Гомәр әфәнденең дә өлеше зур.* Туган як; *к.* **апрель**.

**МЕД-КОМИ́ССИЯ** *и. ялг. Бу айда барысы да* ***мед-комиссияне*** *үтеп бетәргә тиешләр.* Матбугат.ру; *дөр.:* **медкомиссия**; *к.* **мед-сестра**.

**МЕД-ПУ́НКТ** *и. ялг. Колхоз идарәсендә бригадирларга көндәлек эш кушуны ничек кирәк, алай төгәлләп, бармагын авызына кабып суырырдай булып көтте Фәрди* ***мед-пунктның*** *ачылганын.* Ватаным Татарстан; *дөр.:* **медпункт**; *к.* **мед-сестра**.

**МЕД-САНБА́Т** *и. ялг. Пилоткасын,* ***мед-санбат*** *кызларына охшатып көязләп, каш өстенә төшереп кигән.* Г. Әпсәләмов; *дөр.:* **медсанбат**; *к.* **мед-сестра**.

**МЕД-СЕСТРА́** *и. ялг. Ичмасам,* ***мед-сестраны*** *чакырып килим, – дип, Ләйсән киенеп чыгып китте.* Сөембикә.

Рус теленнән әзер килеш алынган кыскартылма кушма сүзләр, мәсәлән, беренче компоненты ***мед-, полит-, агит-*** һ.б.ш. булган һәм шул модель белән татар теленең үзендә ясалган ярымкалькалар, татар телендә һәрвакыт кушылып кына языла; *дөр.:* **медсестра**.

**МЕД-УЧИ́ЛИЩЕ** *и. ялг. 1981 елда Бөгелмә* ***мед-училищесын*** *тәмамлап Бишкурайга килгән яшь белгеч Әнүзәгә өйләнде*. Өмет; *дөр.:* **медучилище**; *к.* **мед-сестра**.

**МЕДУЧИ́ЛИЩЕ** *и.* Медучилищега, медучилищесы, медучилищесына, медучилищелар; *ялг.:* **медучилищегә, медучилищесе, медучилищесенә, медучилищеләр**; *к.* **атташе**.

**МЕМОРИА́Л** *и.* Зур тарихи вакыйга яки даһи шәхес istәлегенә багышланган архитектура-скульптура ансамбле яки мо-

нумент; *ялг.:* **мемориал такта, мемориал үзәк, мемориал комплекс**. *Төмәннең үзәк универсаль кибетендә (ЦУМ) беренче директор Иван Беспаловка багышланган **мемориал** такта куелды.* Яңарыш. *Чал Казан Кремле каршында каһарман шагыйрь Муса Җәлилгә һәм аның көрәштәш дусларына – халкыбызның йөз аклыгын, намусын, фидакарьлеген һәм тугрылыгын гәүдәләндерүче асыл ир-егетләргә багышланган **мемориал** үзәктә тирән уйларга чумып басып торам.* Мәйдан. *Кичә Сөйки кичүе янында яр буенда теплоходта һәлак булучылар истәлегенә **мемориал** комплекс ачылды.* Идел таңнары; *чаг.:* **мемориаль**; *к.* **вокаль**.

**МЕМОРИА́ЛЬ** *с.* Берәр тарихи вакыйганы яки атаклы шәхес истәлеген мәңгеләштерә торган; *чаг.:* **мемориал**; *к.* **вокаль**.

**МЕРКАНТИ́Л** *с. ялг. Аерым кешене күздә тотып әйтмим, кайбер **меркантил** зыялыларыбызның, үзләренең прәннеккә алдануларын яшерергә тырышып, мәгълүмат чараларында яки болай, сүз аралаш «хакимияткә үтмичә, аңа йогынты ясап булмый» дигән кебегрәк акlануларын ишеткәнем бар.* Н. Шәрифуллин; *дөр.:* **меркантиль**; *к.* **вокаль**.

**МЕРКАНТИ́ЛЬ** *с.* Матди якны гына кайгыртучан, үз файдасы, үз кесәсе өчен генә тырышкан; *чаг.:* **меркантил**; *к.* **вокаль**.

**МЕТА́ЛЛ** *и.* Металлга, металлы, металлына, металлар; *ялг.:* **металы, металына, металллар**.

Рус теленнән һәм рус теле аркылы кергән алынма сүзләргә морфемалар кушылган чиктә ике бертөрле аваз туры килгәндә, фонемалар керешү күренеше күзәтелә. Бу беренче чиратта әйтелештә чагыла. Язуда исә бу кагыйдә тамыр ахырында ике бер үк төрле фонема булып, аңа шул ук фонемага башланган кушымча ялганганда гына чагыла. Чөнки, бер яктан, морфемалар – һәм тамыр, һәм кушымча – язуда үз тулылыгын сакларга тиеш: ***меταЛЛ*** + ***-ы*** = ***метаЛЛы***; ***граММ*** + ***-ы*** = ***граММы***; ***муСС*** + ***-ы*** = ***муССы***; икенче яктан, бер үк төрле өч аваз рәттән килү дә татар теленә хас түгел: ***метаЛЛ + -Лар = метаЛЛар, метаЛЛ + -Лы = метаЛЛы; муСС + -Сыз = муССыз.*** Теоретик әдәбиятта бу турыда төрлелек күзәтелә. Мәсәлән, академик грамматикада «сонантлар катнашкан тартыклар җыелмасы бу кагыйдәгә буйсынмый» диелсә дә, ***мусс, мисс*** һ.б. мисалы бу тезисны инкяр итә (*к.* Татар грамматикасы, Т. I, 2015: 146–147 б.).

**МЕТЕО-БИЛГЕ́** *и. ялг. Ул сәләтле укучы булып чыкты, коллективка тиз кереп китте,* ***метео-билгеләр*** *генә түгел, шулай ук фельетоннар, юморескалар яза башлады.* Авыл таңнары; *дөр.:* **метеобилге**; *к.* **фото-альбом**.

**МЕТЕО-КҮЗӘТҮ́** *и. ялг. Николай Муравьев – җитмешенче елларда танылган район метеостанциясе хезмәткәре, редакциягә үз* ***метео-күзәтүләрен*** *бастырырга алып килә.* Авыл таңнары. *Инде утыз елга якын Идел буе һәм Урал гимназия, институтларының һәммәсендә дә* ***метео-күзәтүләрнең*** *фәнни оештырылуын теләгән Н.И. Лобачевский өчен зур күңелсезлек була бу.* Казан утлары; *дөр.:* **метеокүзәтү**; *к.* **фото-альбом**.

**МЕТРДОТЕ́ЛЬ** *и.* Метрдотельгә, метрдотеле, метрдотеленә, метрдотельләр; *ялг.:* **метрдотельга, метрдотелена, метрдотельлар**. *Урынына утыруга ук* ***метрдотельны*** *чакырды, тегесе йөгереп килеп тә җитте*. Р. Батулла. – *Бу шаяру нәкъ вакытында һәм урынлы яңгырады, барысы да озаклап, рәхәтләнеп көлештеләр,* ***метрдотельның*** *борчылуын кул белән алып ташладылармыни, ул күз ачып йомганчы тынычланып калды.* Р. Мирхәйдәров; *к.* **апрель**.

**МИГРЕ́НЬ** *и.* Мигреньга, мигрене, мигренена, мигреньнар; *ялг.:* **мигреньгә, мигрененә, мигреньнәр**. *Кем уйлаган аны ул чорларда Шундый кырыс гомер юлының* ***Мигреньгә*** *дә, милләтчелеккә дә Төтәшмәслек башлар тудыруын!..* Х. Туфан. *Кара, кызыл карлыганның яфраклары белән җиләкләре чәйгә хуш ис һәм тәм өстәп кенә калмый,* ***мигреньнән*** *котылырга, сидек куыгы проблемаларыннан арынырга булыша, басымны нормага китерә.* Әлмәт таңнары. *Кайбер кешеләр 20–30 еллап* ***мигреньнән*** *интексәләр дә, баш авыртуының сәбәбен һәм үзенә ничек булышасын белми.* Шәһри Казан; *к.* **пристань**.

**МИГЪМАРЧЫ́** *и. ялг. Фәридә Зәбирова (Фәридә Мөхәммәт кызы Зәбирова) –* ***мигъмарчы****, Татарстанның атказанган архитекторы.* Википедия. *Бөек төрек* ***мигъмарчысы*** *Ибне Синанны Урманче илаһи остазы күрде.* Безнең мирас; *дөр.:* **мигъмар**; *к.* **каллиграфчы**.

**МИГЪМАРЧЫЛЫ́К** *и. ялг.* Архитектура, мигъмарлык. *Кызганыч ки, безнең институтта да татар архитектурасы –* ***мигъмарчылык*** *дигән фән юк, ә тулаем Европа, Россиянеке генә укытыла.* А. Саттаров. *Мөгаллимлек эшендә дә хезмәт итә ул: Казан архитектура-төзелеш академиясендә милли* ***мигъмарчы-***

***лыкка*** *бәйле фәннәрне укыта.* Татар-информ; *дөр.:* **мигъмарлык**; *к.* **каллиграфчы**.

**МИКРО-ИКЪТИСА́Д** *и. ялг. Беренче чиратта **микро-икътисад,** ягъни конкрет предприятиенең икътисады буенча сыйфатлы белгечләр кирәк.* Татарстан яшьләре; *дөр.:* **микроикътисад**; *к.* **фото-альбом**.

**МИКРО-О́БРАЗ** *и. ялг. Аның иҗатында чын мәгънәсендә зур талант көчен күрсәтүче **«микро-образлар»** аз түгел.* Казан утлары; *дөр.:* **микрообраз**; *к.* **фото-альбом**.

**МИЛЕ́К** *и.; ялг.:* **милеге, милегенә**. *Җир тагын кемнеңдер **милеге** була алмый.* А. Нәҗми. *Син дә инде, шул хәбәрне ишетү өчен, үз өлешеңнән, васыять **милегеңнән** баш тарткансың.* Д. Булатова. *«Газпром» да дәүләт **милеге** санала, аңа карап беркемгә дә начар түгел.* Безнең гәҗит.

Исем тамырларында һәм нигезләрендә фонема йотылу дигән морфонологик күренеш бар: *халык – халкы, милек – милке* (*к.* Татар грамматикасы, Т. I, 2015: 39–40, 137–138 б.). Ләкин бу закончалык барлык сүзләрдә дә бертөрле түгел. Мәсәлән, *зәвык – зәвыгы*. Хәтта омонимнарның парадигмасында да аерма бар. Мәсәлән, *күрек I – күрке, күрек II – күреге* очрагында төрле парадигма мәгънә аеру чарасы да булып тора; *дөр.:* **милеккә, милке, милкенә**; *чаг.:* **зәвык**.

**МИЛЬ** *и.* Мильгә, миле, миленә, мильләр; *ялг.:* **мильга, мильны, мильлар**. *Биредә 100 км га күпме бензин ашый дип санамыйлар, ә бер галлон бензинның ничә **мильга** җиткәнен чагыштыралар.* Гыймрановларның сайты; *к.* **апрель**.

**МИНДА́ЛЬ** *и.* Миндальгә, миндале, миндаленә, миндальләр; *ялг.:* **миндальга, миндальны, миндалена, миндальлар**. *2 кашык **миндальга** шул кадәр үк әстерхан чикләвеге, 1/2 кадак шикәр салып төйгәч, 3–4 йомырка сарысы һәм бер йомырка агы күпертеп кәстрүлгә салалар.* Аш остасы. ***Миндальны** аз канлылык вакытында, күз күреме начарланган вакытта аеруча кулланырга киңәш итәләр.* Гимназия хәбәрләре; *к.* **апрель**.

**МИРАСИ́** *с. ялг. «Мең чакрымга мең чакрым» җыентыгына кергән шигырьләр турыдан-туры Хәсән Туфан, Гамил Афзал, Илдар Юзеев, Роберт Әхмәтҗанов, Мөдәррис Әгъләмов, Зөлфәт дәрәҗәсендәге талантлар иҗатының **мираси** дәвамы.* Шәһри Казан. *Аларның дәвамчылары нәфис вә **мираси**, алтындай кадерле*

*телебезне белерләрме?* Бөгелмә авазы; *дөр.:* **мирас хуҗасы, мирас булырлык, мирас булып калган байлык**; *к.* **мәгълүмати**.

**МИСС** *и.* Мисска, миссы, миссына, мисслар; *ялг.:* **мисы, мисына**. *Әнә Алпарда туып-үскән, авылның беренче чибәре, әгәр дә аның яшьлегендә хәзерге кебек матурлык бәйгеләре үткәрелсә, дөнья* ***мисы*** *булырлык Фирая Вәлиева-Махиянова, зиратны төзекләндерү эшләренә дә, мәчет төзелешенә дә 350 шәр мең сум акча бирде.* Әлки хәбәрләре; *к.* **металл**.

**МИҺЕРБАНЛЫ́К** *и. ялг. Нindидер күзгә күренмәс көчләрме, әллә өлкән кешенең* ***миһербанлыгы****, зирәклеге булдымы, язмыш дигәнең бу юлы да имәннең гомерен һәлакәттән йолып калды*. Р. Низамиев. *Шушы олпат җиһангирның оныгы, Алтын Урда дәүләтен бар иткән Бату хан да зирәклеге, тәвәккәллеге,* ***миһербанлыгы*** *белән дан тоткан.* М. Әмирханов. *Урталарына бер уч көнбагыш килеп төшкәч, җим исен сизеп, тыныч кына* ***миһербанлык*** *көтеп йөргән күк күгәрченнәр гаиләсендә этеш-төртеш башланды, әтәчләре чукышырга тотынды*. К. Кәримов; *дөр.:* **миһербан, миһербанлылык**; *к.* **катлаулык**.

**МИЧӘ́Ү** *и.* Мичәүгә, мичәве, мичәвенә, мичәүләр; *ялг.:* **мичәүе, мичәүенә**; *к.* **билбау**.

**МИШЕ́НЬ** *и.* Мишеньга, мишене, мишенена, мишеньнар; *ялг.:* **мишеньгә, мишененә, мишеньнәр**. – *Рядовой Петелькин, сез тагын күршегезнең* ***мишененә*** *атасыз.* Р. Могыйнов. *Аннары, үз* ***мишенеңә*** *ун патронны бер-бер артлы сибеп чыккач, монокольдән карыйсың.* М. Галиев. ***Мишеньнең*** *«күз алмасына» – унлыкка бәрү... әле ядрәләрнең берсе өстенә берсе тигән дә булса...* Казан утлары; *к.* **пристань**.

**МОГҖИЗА́Й** *с. ялг. Алтайдан китерелгән марал боланы мөгезләреннән эшләнгән* ***могҗизаи*** *дарулар һәм мумиегә кадәр – барысы да бар иде.* Рәсми Татарстан; *дөр.:* **могҗизалы, могҗиза ...-ы/-е**; *к.* **мәгълүмати**.

**МОДЕ́ЛЬ** *и.* Модельгә, моделе, моделенә, модельләр; *ялг.:* **модельга, моделы, моделына, модельлар**. ***Модельлар*** *сөйләм теле, сәхнәдә хәрәкәт, фотопроба, видеопроба, макияж, кием стиле, прическа серләренә өйрәнәчәк.* Татар-информ. *Яңа* ***модельның*** *төгәл бәясе әлегә билгесез.* Intertat.ru. *Кансас һава юлларының бу* ***модельда*** *4 очкычы бар.* «Азатлык радиосы» сайты. *Британиянең танылган* ***моделы*** *Кампбелл мәхкәмә утырышына үзе теләп*

*түгел, ә мәхкәмә әмере белән китерелде.* «Азатлык радиосы» сайты; *к.* **апрель**.

**МО́ДУЛЬ** *и.* Модульгә, модуле, модуленә, модульләр; *ялг.:* **модульга, модуле, модулена, модульлар**. ***Модульны*** *җыю эшләре алтынчы ноябрьдән башланды.* Авыл таңнары. *Алдагы икесендә курсантлар эш урыннарында үзлектән тикшеренүләр үткәрү өчен әзерлек һәм белем тупласа, соңгы* ***модульда*** *белемнәр гамәли эш барышында ныгытыла, тестлар уздыруда методик алымнар үзләштерелә, анализлар ясала.* Казан мэриясенең рәсми порталы; *к.* **апрель**.

**МОНАСТЫ́РЬ** *и.* Монастырьга, монастыре, монастырена, монастырьлар; *ялг.:* **монастырьгә, монастыренә, монастырьләр**. *2003 елда республиканың бер районында* ***монастырьне*** *тергезгәндә, берничә кабер табылды, алар өстенә кирпеч ватыклары ташланган иде.* Кызыл таң. *Галимнәр картаеп урын өстендә үлгән раһибәләрнең 20 яшьләре дә тулмыйча* ***монастырьгә*** *килгәч язган иншаларын җентекләп тикшергән.* «Азатлык радиосы» сайты. *Болактан Елан* ***монастыренә*** *баручы җир асты юлы турында 70 яшьлек Василий бабай Томилин болай дип сөйләгән ---.* Татарстан яшьләре; *к.* **лагерь**.

**МОНО-ДИЕ́ТА** *и. ялг. Суыклар чорында* ***моно-диеталар*** *турында онытыгыз.* Әлмәт таңнары; *дөр.:* **монодиета**; *к.* **фото-альбом**.

**МОНО-ҖЫЕНТЫ́К** *и. ялг. 2011 елда гына да биш әдәби* ***моно-җыентык*** *чыгарылган.* Кама ягы; *дөр.:* **моножыентык**; *к.* **фото-альбом**.

**МОНО-КАЛА́** *и. ялг.* ***Моно-калаларның*** *финанс хәлен яхшырту проектлары Баймак һәм Күмертау мисалында күрсәтелә.* «Азатлык радиосы» сайты; *дөр.:* **монокала**; *к.* **фото-альбом**.

**МОНО́КЛЬ** *и.* Монокльгә, монокле, моноклена, монокльләр; *ялг.:* **монокльга, моноклена, монокльлар**; *к.* **апрель**.

**МОНО-КОМА́НДА** *и. ялг. Җиңүче исеменә бер кешедән торган «Казахстан»* ***моно-командасы*** *– фәлсәфә факультеты студенты Елизавета Платонова лаек дип табылды.* Darelfønyn; *дөр.:* **монокоманда**; *к.* **фото-альбом**.

**МОНО-СПЕКТА́КЛЬ** *и. ялг. Фестивальнең тагын бер үзенчәлеге: Наталья Ибраһимова, ак рояльда биеп, «Пианофрения» хореографик* ***моно-спектакле*** *белән шаккатырачак.* Татар-информ; *дөр.:* **моноспектакль**; *к.* **фото-альбом**.

**МОНО-ТИПИ́Я** *и. ялг. Аның ачышы билгеле* ***моно-типия*** *(буявы кибеп өлгермәгән сурәтне икенче кәгазьгә бастырып алу) ысулын хәтерләтә.* Өмет; *дөр.:* **монотипия**; *к.* **фото-альбом**.

**МОНОТОНЛЫ́** *с. ялг. Алыштырсаң алыштырмасаң да, барыбер* ***монотонлы*** *бер көй агыла сыман.* Ә. Мушинский; *дөр.:* **монотон**; *к.* **каллиграфчы**.

**МОНОТОНЛЫЛЫ́К** *и. ялг. Ләкин шул ук вакытта «Өч аршын җир»дәге вакыйгалар үсешендә әлеге темаларның гына яңгырап торуы* ***монотонлылыкка*** *китерә, спектакльнең ритмы югала кебек.* Сәхнә; *дөр.:* **монотонлык**; *к.* **каллиграфчы**; *к. ш. ук* **катлаулык**.

**МОНО-ШӘҺӘ́Р** *и. ялг. Безнең Чаллы Европа стандартларына туры килерлек, яңа башлангычлар, бик күп инновацион проектлар тамыр җибәргән, чит төбәкләрне кызыктырып җәлеп итә торган* ***моно-шәһәр***. Мәйдан; *дөр.:* **моношәһәр**; *к.* **фото-альбом**.

**МОПЕ́Д** *и.* Мопедка, мопеды, мопедына, мопедлар; *ялг.:* **мопетка, мопеты, мопетына, мопетлар**; *к.* **гибрид**.

**МОТЕ́ЛЬ** *и.* Мотельгә, мотеле, мотеленә, мотельләр; *ялг.:* **мотельга, мотелена, мотельлар**; *к.* **апрель**.

**МӨМКИНЧЕЛЕ́К** *и. ялг. Көн дә аның белән генә утырыр идем, андый* ***мөмкинчелек*** *юк шул.* Г. Шәйхи. *Вакыт җитте, бүтән* ***мөмкинчелек*** *булмаячак.* З. Кадыйрова. *Матур яшисең икән,* ***мөмкинчелек*** *булган саен бүләк ясап торасы килә.* Кәеф ничек?; *дөр.:* **мөмкинлек**; *к.* **каллиграфчы**.

**МӨСЕЛМАНЧЫЛЫ́К** *и. ялг. Гомере буенча аның мәдәниятенең бүленмәгән бер өлеше булган* ***мөселманчылыкны*** *черетүдән саклар өчен Идел буе мөселманының динчелегенә ябышкан ишанлык, мөтәгассыйблык (фанатизм) кеби төрле-төрле паразитлардан пакьләргә тырышкандыр.* Х. Миңнегулов; *дөр.:* **мөселманлык**; *к.* **каллиграфчы**.

**МӨТӘВӘЛЛИ́** *и.* Мөтәвәллигә, мөтәвәллие, мөтәвәллиенә; *ялг.:* **мөтәвәллисе, мөтәвәллисенә**; *к.* **көрси**.

**МӨФТИ́** *и.* Мөфтигә, мөфтие, мөфтиенә; *ялг.:* **мөфтисе, мөфтисенә**. *Сүриягә күченгәч, ваххабилыкны күтәреп чыкканы өчен Сүрия* ***мөфтисе*** *аны илдән куа, Албани Сәгуд Гарәпстанга килә һәм ваххабилык фикерләрен шунда үстерә.* Ислам: татарлар һәм мөселманнар. *Татарстан баш* ***мөфтисе*** *Илдус Фәизов Төркия*

*баш **мөфтисен** «Коръән-Кәрим елы» чараларына чакырды*. Татар-информ; *к.* **көрси**.

**МӨШТӘРИ́** *и.* Мөштәригә, мөштәрие, мөштәриенә; *ялг.:* **мөштәрисе, мөштәрисенә**; *к.* **көрси**.

**МУ́ЗЫКАЛАШТЫРУ** *ф. ялг. Бу очрак Габәшинең татар композиторлары арасында иң беренче башлап спектакльләрне **музыкалаштыручы** икәнлеген күрсәтә*. Казан утлары; *дөр.:* **музыкага салу, көйгә салу**.

**МУЛЧЫЛЫ́К** *и. ялг.; дөр.:* **муллык**; *к.* **каллиграфчы**.

**МУЛЬЧИРЛА́У** *ф. ялг; дөр.:* **мульчалау, мульча белән каплау, мульча салу**; *к.* **реагирлау**.

**МУМИЁ** *и.* Мумиёга, мумиёсы, мумиёсына; *ялг.:* **мумиегә, мумиесе, мумиесенә**. *Биредә, үсентеләрдән алып, кондыз бизләреннән, Алтайдан китерелгән марал боланы мөгезләреннән эшләнгән могҗизаи дарулар һәм **мумиегә** кадәр – барысы да бар иде.* Рәсми Татарстан. *Даруханәдән алынган 2 грамм **мумиене** 10 аш кашыгы май аенда җыелган балда эретәләр, иртән ач карынга 1 аш кашыгы баллы **мумиене** әкренләп суыралар*. Мәдәни җомга.

Сүзнең дөрес язылышы *мумиё*, укылышы *[мумийо]*, ягъни нигез арткы рәт аваз белән тәмамлана, димәк, аңа арткы рәт кушымчасы ялганырга тиеш. Шулай ук ***ё*** хәрефен ***е*** белән алмаштыру аның ялгыш укылышына һәм әйтелешенә, шул сәбәпле ялгыш кушымчалар кушылуына китерергә мөмкин, шуңа күрә язуда ***ё*** хәрефен язу мөһим.

**МУНДИА́ЛЬ** *и.* Мундиальгә, мундиале, мундиаленә, мундиальләр; *ялг.:* **мундиальга, мундиалена, мундиальлар**. *Бүген алар, **мундиальны** кайсы вакытта уздыру яхшырак булыр, дигән сорауга җавап эзли*. Шәһри Казан; *к.* **апрель**.

**МУСС** *и.* Мусска, муссы, муссына, мусслар; *ялг.:* **мусы, мусына**. *Балаларга ул кечкенә капкейклар пешерде дә, бер өлешен шоколад **мусы**, икенчесен җиләкләр белән бизәде*. Кызыл таң; *к.* **металл**.

**МЫЕ́КАЯКЛЫ** *с. ялг. Кайбер утрак тереклек итүче организмнарның хәрәкәтчән личинкалары төрнең таралуына ярдәм итә, мәсәлән моллюскларда һәм **мыекаяклы** кыслаларда – диңгез чикләвекләрендә*. Биология; *дөр.:* **мые́гаяклы**; *к.* **ишекалды**.

**МЫЕ́КАЯКЛЫЛАР** *и. күпл. ялг. зоол.* Кысласыманнарның бер төркеме; *дөр.:* **мые́гаяклылар**; *к.* **ишекалды**.

**МЮ́СЛИ** *и*. Мюслига, мюслие, мюслиена, мюслилар; *ялг.:* **мюслигә, мюслиенә, мюслиләр**; *к.* **бигуди**.

**НАТУРА́Л** *и*. Гетеросексуал; *ялг*. **натурал ашлама, натурал ефәк**. *Әшнәлек вә бераз төртеп, Алдык күрәп **Натурал** ашлама. Үсәр гөрләп Җиләк-җимеш безнең бакчада.* Р. Батулла; *чаг.:* **натураль**; *к.* **вокаль**.

**НАТУРА́ЛЬ** *с*. Чын, табигый, ясалма булмаган: **натураль ефәк, натураль төс, натураль ашлама**; *чаг.:* **натурал**; *к.* **вокаль**.

**НӘФЕ́С** *и. ялг.:* **нәфсе, нәфсенә**. *Гарунның **нәфсе** никадәр зур булмасын, куркуы да бар иде*. З. Мурсиев. *Ягулыкның бәясе арту бары тик нефть эшләп чыгаручыларның **нәфсенә** генә бәйле*. Татарстан яшьләре. *Шул ач күзнең **нәфсе** төшкән Лисәпит акчасына* ---. И. Диндаров; *дөр.:* **нәфескә, нәфесе, нәфесенә**; *к.* **зәвык**; *чаг.:* **милек**.

**НЕЙТРА́Л** *и*. Нейтралитет тарафдары; нейтралитет яклы кеше; *ялг.:* **нейтрал статус, нейтрал җир**. – *Йөрешен «**нейтрал**»га куегыз да, машинаны этеп кенә күчереп, көчекне алабыз, – ди*. Татарстан яшьләре. *Мишлин ханым сүзләренчә, Швейцариянең **нейтрал** статусы аңа, Тәһранның атом програмы тирәсендәге каршылыкта арадашчы булырга мөмкинлек бирә*. «Азатлык радиосы» сайты. *Очрашу үзенә күрә **нейтрал** җирдә – Идел суларында узды дияргә була, кунаклар Казанга Болгардан кайту юлында тукталган иде*. «Азатлык радиосы» сайты; *чаг.:* **нейтраль**; *к.* **вокаль**.

**НЕЙТРА́ЛЬ** *с*. Битарафлык саклаган, якларның берсенә дә карамаган; көрәш, бәхәс һ.б. булганда, бер якка да катнашмаучы, битараф; әче дә, селтеле дә булмаган; *чаг.:* **нейтрал**; *к.* **вокаль**.

**НЕО-КЛА́ССИКА** *и. ялг. Алар башкаруында төрле жанрларда (этно-джаз, фьюжн, поп, кантри, брит-поп, рок-баллада, **нео-классика,** поп-рок һ.б.) җанлы тавышка җырланылган заманча татар җырларын ишетеп булды*. Казан утлары; *дөр.:* **неоклассика**; *к.* **фото-альбом**.

**НЕО-НАЦИ́СТИК** *с. ялг. Русиянең расизмга каршы «Сова» төркеме мәгълүматына караганда, шушы елда гына да Русиядә 147 **нео-нацистик** һәм расачыл һөҗүм теркәлгән*. Безнең гәҗит; *дөр.:* **неонацистик**; *к.* **фото-альбом**.

**НЕО-ТРАДИЦИОНАЛИ́ЗМ** *и. ялг. Быел үткәрелгән икенче «Татар дин әһелләре форумы» ТР Диния нәзарәтенең сәясәтен билгеләүче **нео-традиционализм** кысаларында узды.*

Ислам – татарлар һәм мөселманнар; *дөр.:* **неотрадиционализм**; *к.* **фото-альбом**.

**НЕО-ФАШИ́СТ** *с. ялг. Кайбер такырбашлар **нео-фашист** оешмалар өчен «давыл солдатлары» буларак хәрби хезмәткә алына, һәм шулай итеп хәрәкәт, вакыт үткән саен, ныграк сәясәткә чума.* Гыйлем; *дөр.:* **неофашист**; *к.* **фото-альбом**.

**НЕО-ФАШИ́СТИК** *с. ялг. Нәрсә, хәзер, **нео-фашистик** элементларга ияреп, азәрбайҗан белән әрмәннәрне Россия җиреннән куаргамы?* Р. Мостафин; *дөр.:* **неофашистик**; *к.* **фото-альбом**.

**НЕ́РВА** *и. ялг.:* **нерва, нервасы, нервага**. ***Нервалары** беткән, **нервалары** тузган.* Д. Салихов. *Мыгыр-мыгыр килеп бер-берегезнең **нерваларында** уйнамагыз, һәр вак-төяк сәбәп аркасында ачуланышмагыз.* Кәеф ничек? *Моңа өстәп, тәрҗемәче авыр хәлләрдән чыга белергә, «тимер **нервалы**» һәм зәвыклы булырга тиеш.* «Азатлык радиосы» сайты; *дөр.:* **нерв**, **нервы, нервка**; вариант буларак, сөйләм телендә: **нервы, нервысы, нервыга**; *к.* **страза**.

**НЕФТЬ** *и.* Нефтькә, нефте, нефтенә, нефтьләр; *ялг.:* **нефтька, нефтена, нефтьлар**. *Аның күләме гадәти җиңел **нефтька** караганда 4 тапкырга артыграк.* «Азатлык радиосы» сайты. *Республикада 2 проект – **нефтьны** күкерттән арындыру һәм газны эшкәртү технологияләрен җәелдерү каралган.* Яңа гасыр.

Гомуми кагыйдәдән чыгарма булып тора, чөнки кушымчаларның алгы рәт вариантын алып төрләнә; *чаг.* **повесть**.

**НИ́КЕЛЬ** *и.* Никельгә, никеле, никеленә, никельләр; *ялг.:* **никельга, никелена, никельлар**. *Баксаң, барлык алмаз запасларының – 50, табигый газның – 30, **никельның** – 25, нефтьнең 10 проценты нәкъ менә Русиядә икән.* Татарстан яшьләре. *«Норильский Никель» Русияның бакырның 70, **никельның** 80 процентын эшләп чыгара.* Википедия; *к.* **апрель**.

**НИ́НДИ** *а. ялг.:* **ниндиерәк**. *Рәфис белән бергә була алса, кешеләрнең аңа булган мөнәсәбәте **ниндиерәк** булыр иде икән?* А. Вергазов. ***Ниндиерәк** кешеләр икән, диеп тә уйлап куясың.* Яңарыш; *дөр.:* **ниндирәк**; *к.* **бай**.

**НИ́НДИ-ДӘ БУЛСА** *а. ялг. Бер кулыгыз белән **нинди-дә булса** әйбергә тотынып, аңа колга яки башка коткару чарасын сузыгыз.* Биектау хәбәрләре. *Бу караш Кушма Штатларның хәзерге президенты Барак Обаманың Израилне Иранга каршы **нинди-дә булса** көч куллануда тотылып калырга өндәү сәясәтенә капма-*

*каршы килә.* «Азатлык радиосы» сайты; *дөр.:* **нинди дә булса**; *к.* **әллә-кайда**.

**НИСБӘТЛЕ́К** *и. ялг. Этник* ***нисбәтлекне*** *ачыклаганда иң башта тел үзенчәлекләренә таяну аның «Тептяри и их происхождение» (Ахмаров, 1907) дигән хезмәтендә дә бик ачык чагылган, тел факторы монда да әһәмиятле атрибут, ышанычлы дәлил итеп китерелә.* Фән һәм тел; *дөр.:* **нисбәт**, **нисбәтлелек**; *к.* **катлаулык**.

**НИ́ЧЕК-ТӘ БУЛСА** *а. ялг. Үзеңне котыру авыруыннан* ***ничек-тә булса*** *сакларга буламы?* Кама ягы. *Әгәр дә гаиләдә дин булмаса, --- балаларына нәсыйхәт, тәрбия кебек сүзләр, Коръәннең аятьләрен* ***ничек-тә булса*** *төшендерү булмаса, менә бу вакытта алар бер-берсен аңламаслар, ерагаерлар иде.* Татар – ислам; *дөр.:* **ничек тә булса**; *к.* **әллә-кайда**.

**НОЛЬ** *и.* Нольгә, ноле, ноленә, нольләр; *ялг.:* **нольга, нолена, нольлар**. *10–15 ел эчендә* ***нольдан*** *күпме нәрсәләр барлыкка килде.* Безнең гәҗит; *к.* **апрель**.

**НОМИНА́Л** *и.* Кыйммәтле кәгазьләрнең, акчаларның үз өстендә күрсәтелгән бәясе; *ялг.:* **номинал бәя**. *Долларның тарихы болай: 1518 нче елда Германиянең Богемия җирендәге Йохимсштале дигән кечкенә шәһәрдә түгәрәк формалы, авырлыгы 28 грамм көмешкә,* ***номинал*** *бәясе 3 маркага тиң яңа акча сугып чыгаралар.* Белем. ру. *Яхшы сыйфатлы ялган акча купюраларын күпләп сатып алу бәясе югары, ул акчаның* ***номинал*** *бәясенең 25 – 35% ын тәшкил итә.* Кайбыч таңнары; *чаг.:* **номиналь**; *к.* **вокаль**.

**НОМИНА́ЛЬ** *с.* Берәр нәрсәнең өстендә акча бәясе белән күрсәтелгән, акча бәясе белән билгеләнгән; *дөр.:* **номиналь бәя, номиналь эш хакы**; *чаг.:* **номинал**; *к.* **вокаль**.

**НОУ-ХА́У** *и.* Ноу-хауга, ноу-хауы, ноу-хауына; *ялг.:* **ноу-хавы, ноу-хавына**.

Сүз алынма булганга күрә, **ноу-хау – ноу-хауы, ноу-хауына** язылышы чыгарма булып тора, чөнки шул ук типтагы татар сүзләрендә сузык авазлар уртасына калган ***у*** урынына ***в*** языла; *чаг.:* **билбау**.

**НОЯ́БРЬ** *и.* Ноябрьдә, ноябре, ноябрендә, ноябрьләр; *ялг.:* **ноябрьда, ноябренда, ноябрьлар**. *Дөрес, әле тагын бер уен бар барын – «Рубин» 11* ***ноябрьда*** *соңгы матчын Үзәк стадионда Мәскәүнең ЦСКА командасы белән үткәрә.* Татарстан яшьләре.

***Ноябрьның*** *беренче 3 атнасында шәһәрдә агачлар саны тагын да артырга тиеш, экологлар ноябрь – декабрь башында утыртылган агачлар әйбәт тернәкләнә дип саный, гомумән, бу эштә системалы эшләргә кирәк, диде шәһәр башлыгы.* Татар-информ. *Мәгариф системасында эшләмәүче читтән торып укучы студентлар педагогик практиканы 4 курста (7 семестрда) 20* ***ноябрьдан*** *19 декабрьга кадәр үтәләр.* «Татарстанда мәгариф» порталы; *к.* **январь**.

**НУЛЬ** *и.* Нульгә, нуле, нуленә, нульләр; *ялг.:* **нульга, нулена, нульләр**. *Шулай ук хисап приборлары да булмый, коммуналь хезмәтләргә норматив буенча исәп-хисап ясала, чынлыкта,* ***нульга*** *тигез була, ә гамәлдә ул фатирларда дистә һәм аннан артык кеше яшәргә мөмкин.* Татар-информ. *[Хезмәт хакы]* ***нульдан*** *алып илле меңгә кадәр.* Шәһри Казан. *Алар кайвакыт* ***нульдан*** *башлап, айлар буе бер мәсьәлә өстендә эшләргә мәҗбүр булалар, һәм бөтенесе бәясез дип әйтергә була.* В. Исламетдин; *к.* **апрель**.

**НЫКЛАНУ́** *ф. ялг. XV гасырның ахырында бу җирләрдә хуҗа булып Аурупа* ***ныкланды***. Википедия; *дөр.:* **ныгу**.

**ОБЫВА́ТЕЛЬ** *и.* Обывательгә, обывателе, обывателенә, обывательләр; *ялг.:* **обывательга, обывателена, обывательлар**. *1964 нче елда Х. Туфан мондый сүзләр әйтә: «Әдәбиятка килеп кергәндә, тумыштан дигәндәй, янып яшәүче, күренеп торган яшьләр дә бар, ләкин халтураның һәм* ***обывательның*** *үзенә алтын чор тудыра алган заманга, ясалма иҗат белән чын иҗат бергә буталып яшәгән мәйданга килеп керү белән яхшы сыйфатларны югалта башлыйлар, – ди Хәсән абый инде шул вакытта ук.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар; *к.* **апрель**.

**ОВА́Л** *и.* Озынча түгәрәк; *ялг.:* **овал формада**. *Ата затның җенес бизләре – орлыклыклар үзенчәлекле* ***овал*** *формада.* Биология. *Тырнаклар бертигез озынлыкта,* ***овал*** *формада булырга тиеш.* Кәеф ничек?; *дөр:* **овал формасында, овал рәвешендә, овал ясау**; *чаг.:* **оваль**; *к.* **вокаль**.

**ОВА́ЛЬ** *с.* Озынча түгәрәк формасындагы; *ялг.:* **оваль формасы, оваль формасындагы**; *чаг.:* **овал**; *к.* **вокаль**.

**О́КИСЬ** *и.* Окиська, окисе, окисена, окисьлар; *ялг.:* **окиськә, окисенә, окисьләр**. *ТР гигиена һәм эпидемиология үзәге мәгълүматларына таянып, Ә. Садретдинов, автомобиль юллары буенда һавада углерод оксиды, азот* ***окисьләре****, формальдегид һәм углеводород тупланмалары буенча куркынычсыз булган норманы*

*5,2 процентка узып киткән районнар бар ---.* Татар-информ. *Моның аңлатмасы түбәндәгечә: бу элементлар бик сирәк очрыйлар һәм авыр җылытып эретелә, суда эреми торган* ***окисьләр*** *бирәләр.* Википедия; *к.* **повесть**.

**ОКЛА́Д** *и.* Окладка, оклады, окладына, окладлар; *ялг.:* **оклатка, оклаты, оклатына, оклатлар**. *Бөтен больница медиклары премия алды ике* ***оклат****, ә фельдшерларныкы кая киткән?* Матбугат.ру; *к.* **гибрид**.

**ОКТЯ́БРЬ** *и.* Октябрьдә, октябре, октябрендә, октябрьләр; *ялг.:* **октябрьда, октябренда, октябрьлар**. *8* ***октябрьда*** *актив авторыбыз, Татарстанның атказанган сәнгать эшлеклесе, Г. Тукай бүләге иясе Марсель Галиевкә 60 яшь тулды.* Татарстан яшьләре. *Минем әбием 1925 нче елның 10 нчы* ***октябренда*** *Кукмара районының Нормабаш авылында дөньяга килә.* Матбугат.ру; *к.* **январь**.

**ОНЛАЙН-АНКЕ́ТА** *и. ялг. Хәзер алар волонтерлыкка кандидатларның* ***онлайн-анкеталары*** *белән таныша, ә майдан башлап Рекрутинг үзәгендә әңгәмәләр уздыра башлаячак.* 2013 Универсиадасы блогы; *дөр.:* **онлайн анкета**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-ӘҢГӘМӘ́** *и. ялг. Шунысын да әйтергә кирәк: 2 декабрьдә сәгать 12дә «Газета. ру» редакциясендә аның белән алдан килешенгән* ***онлайн-әңгәмә*** *булырга тиеш иде.* Р. Шакиров; *дөр.:* **онлайн әңгәмә**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-БИЛЕ́Т** *и. ялг. Мәсәлән, хәзерге вакытта камаллыларның Уфа шәһәрендә узачак гастроль спектакльләренә актив рәвештә* ***онлайн-билетлар*** *сатылу башланды.* Казан утлары; *дөр.:* **онлайн билет**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-ГАРИЗА́** *и. ялг. ---* ***онлайн-гаризалар*** *калдырган «Полиглот 2013» конкурсы финалистлары волонтер-рекрутларның сорауларына җавап бирде.* 2013 Универсиадасы блогы; *дөр.:* **онлайн гариза**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-ЗАКА́З** *и. ялг. Сервиста смартфон өчен кушымта яисә интернет-браузер аша автомобильләргә* ***онлайн-заказ*** *бирү мөмкинлеге каралган.* Кызыл таң; *дөр.:* **онлайн заказ**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-КИБЕ́Т** *и. ялг. Хәзер июль башыннан чит илләр* ***онлайн-кибетләрдә*** *сатып алынган товарларны пошлинасыз чыгару буенча закон проекты карала.* Мәдәни җомга. *Бүгенге көннән*

*Интернетта* ***онлайн-кибет*** *эшли башларга тиеш, анда да Универсиада символикасы төшерелгән продукция сатылачак.* Матбугат.ру; *дөр.:* **онлайн кибет**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-КИҢӘШМӘ́** *и. ялг. Дәүләт җыелышы – Корылтайда күпкатлы йортларны капиталь төзекләндерү мәсьәләләре буенча* ***онлайн-киңәшмә*** *үтте.* Кызыл таң; *дөр.:* **онлайн киңәшмә**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-КИТАПХАНӘ́** *и. ялг. Шушы көннәрдә Интернетта Ислам әдәбияты* ***онлайн-китапханәсе*** *эшли башлады.* Кызыл таң; *дөр.:* **онлайн китапханә**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-КОНСУЛЬТА́ЦИЯ** *и. ялг. Моннан тыш, интернетта сайт ачылган, анда* ***онлайн-консультация*** *алып барабыз.* Кызыл таң; *дөр.:* **онлайн консультация**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-КОНФЕРЕ́НЦИЯ** *и. ялг.* ***Онлайн-конференциядә*** *Президент Рөстәм Хәмитов республика халкын борчыган сорауларга җавап бирде.* Кызыл таң; *дөр.:* **онлайн конференция**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-КӨНДӘЛЕ́К** *и. ялг. «Депрессия» диагнозы куелган кешеләрнең социаль челтәрләрдә, форумнарда,* ***онлайн-көндәлекләрдә*** *язган сүзләре заманча технологияләр ярдәмендә тикшерелгән.* Кызыл таң; *дөр.:* **онлайн көндәлек**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-КУ́РС** *и. ялг. Ул теләгән һәркемгә, тест язганнан соң, үз бизнесын булдыру һәм үстерү буенча бушлай* ***онлайн-курслар*** *узу мөмкинлеге бирә.* Казан утлары; *дөр.:* **онлайн курс**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-МӘКТӘ́П** *и. ялг. «Ана теле»* ***онлайн-мәктәбе*** *уңышлы гына эшләп килә.* Казан утлары; *дөр.:* **онлайн мәктәп**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-ОЛИМПИА́ДА** *и. ялг. Илеш районыннан Ашот Амбарцумян татар теле буенча Бөтенрусия* ***онлайн-олимпиадасында*** *җиңү яулаган!* Кызыл таң; *дөр.:* **онлайн олимпиада**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-ПРОГРА́ММА** *и. ялг. Аның берсе – телне Интернет аша* ***онлайн-программалар*** *ярдәмендә өйрәнү, икенчесе – тел күнекмәләрен укытучы ярдәмендә үстерү, өченчесе – алган белемнәрне билгеле бер реаль вазгыять шартларында практикада куллану күнекмәләре алу, дүртенчесе – төрле тестлар узу.* 2013 Универсиадасы блогы; *дөр.:* **онлайн программа**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-ПРОЕ́КТ** *и. ялг. Татарстанның мәгариф һәм фән министры урынбасары Илдар Мөхәммәтов бүген «Татар-информ» мәгълүмат агентлыгында «Ана теле»* ***онлайн-проектының*** *5 еллыгына багышланган матбугат конференциясендә шулай дип белдерде*. Казан утлары; *дөр.:* **онлайн проект**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-РЕЖИ́М** *и. ялг. Отчет-сайлау утырышы* ***онлайн-режимда*** *«Бердәм Русия» партиясенең Башкортстан төбәк бүлекчәсе сайтында барды.* Кызыл таң; *дөр.:* **онлайн режим**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-САТУ́** *и. ялг. 2016 ел нәтиҗәләре буенча, китапларны* ***онлайн-сату*** *күләме 15–16 млрд сум булып бәяләнә, ягъни гомуми китап базарының 20 проценты тирәсе.* Кайбыч таңнары; *дөр.:* **онлайн сату, онлайн сәүдә**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-СЕ́РВИС** *и. ялг. Россия Федерациясе социаль иминләү фонды сайтында «Пособиеләр калькуляторы»* ***онлайн-сервисы*** *әнә шундый мөмкинлек вәгъдә итә.* Идел таңнары; *дөр.:* **онлайн сервис**.

Инглиз теленнән рус теле аркылы кергән ***онлайн*** компонентлы сүзләрнең язылышында төрлелек күзәтелә. Рус телендә аларның күпчелеге сызыкча аша языла. Бу рус теленең орфография принципларына туры килә: әгәр аергычның аерылмышка бәйли торган кушымчасы булмаса, алар сызыкча аша языла. Татар телендә исә аергыч белән аерылмышның янәшә торуы җитә, алар арасында сызыкча куюның кирәге калмый гына түгел, кую хата була, чөнки ияртүле мөнәсәбәттәге сүзләр сызыкча аша язылмый. Димәк, татар телендә аларны чыганак инглиз телендәге кебек аерым язу дөрес була. ***саунд, экспресс*** һ.б.ш. компонентлар белән ясалган сүзләр дә шул ук закончалыкка буйсына. Чыгарма: ***саундтрек***.

**ОНЛАЙН-СИМУЛЯ́ТОР** *и. ялг. Гамәли дәресләрдә үзләре катнаша алмаганнар өчен җиһазлар эшен төгәл кабатлаучы* ***онлайн-симулятор*** *куллану мөмкинлеге тудырылды.* 2013 Универсиадасы блогы; *дөр.:* **онлайн симулятор**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-СҮЗЛЕ́К** *и. ялг. Курс сөйләм, язу, грамматик лабораторияләрдән,* ***онлайн-сүзлектән,*** *төркемләп аралашу дәресләрен үткәрү өчен материаллардан, 9 дәрәҗә тестлардан тора.* Казан утлары. *2013 елда бу сүз инглиз теленең Оксфорд* ***онлайн-сүзлегендә*** *дә урын алды.* Кызыл таң; *дөр.:* **онлайн сүзлек**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-СЫНА́У** *и. ялг. Аның өчен үз электрон почтаңа кереп, EF хаты буенча **онлайн-сынау** узарга кирәк.* 2013 Универсиадасы блогы; *дөр.:* **онлайн сынау**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-ТАВЫ́Ш БИРҮ** *и. ялг. Аның сайлап алу этабы тәмамланды, хәзер барлык номинацияләр буенча **онлайн-тавыш бирү** бара.* Кайбыч таңнары. *«Ел укытучысы» конкурсы кысаларында **онлайн-тавыш бирү** үтәчәк.* Кызыл таң; *дөр.:* **онлайн тавыш бирү**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-ТАПШЫРУ́** *и. ялг. Электр энергиясенә өзеклек булса, вәгъдә ителгән **онлайн-тапшыруларга** куркыныч яныймы?* Кызыл таң. ***Онлайн-тапшыру** ярдәмендә җыелышны дөньяның теләсә кайсы ноктасыннан күзәтеп булачак.* Татар-информ; *дөр.:* **онлайн тапшыру**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-ТЕ́СТ** *и. ялг. Моннан тыш, **онлайн-тестны** Казан федераль университетында 26 майда узарга мөмкин.* Казан утлары. *Интернеттан **онлайн-тестлар** эшләп әзерләндем.* Кайбыч таңнары; *дөр.:* **онлайн тест**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-ТЕСТЛАШТЫРУ́** *и. ялг. Май ае башында **онлайн-тестлаштыру** рәвешендәге читтән торып сайлап алу турыннан соң, ә анда 3 меңләп 8, 10 нчы класс укучылары катнашыр дип көтелә (былтыр 2,7 меңләп булган), көндезге этапта 200 ләп катнашучы Казанда Универсиада авылында торачак (былтыр 100 кеше килгән).* Казан утлары; *дөр.:* **онлайн тестлау, онлайн тест үткәрү**; *к.* **онлайн-сервис**; *к. ш. ук* **тестлаштыру**.

**ОНЛАЙН-ТРАНСЛЯ́ЦИЯ** *и. ялг. Түбән Каманың 10 нчы санлы «электрон» мәктәбендә дәүләт җитәкчесе Лондондагы Трафальгар мәйданын **онлайн-трансляциядән** күзәтте, роботлар белән уйнап алды һәм укучыларның физика лабораториясендә фонтаннардагы су чыгымын, сөтнең электр үткәрүчәнлеген тикшерү эшләрен кызыксынып күзәтте.* Кәеф ничек? *«Татар-информ» агентлыгы сайтында матбугат конференциясенең **онлайн-трансляциясе** оештырылачак.* Казан утлары; *дөр.:* **онлайн трансляция**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-ТРАНСЛЯ́ЦИЯЛӘҮ** *ф. ялг. П.А. Ойунский исемендәге Саха академия театрының «Уяну» спектаклен «Татар-информ» **онлайн-трансляцияләячәк**.* Казан утлары; *дөр.:* **онлайн трансляцияләү**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-ТҮЛӘ́Ү** *и. ялг. Дәүләт хезмәте порталын яки банклар тәкъдим иткән **онлайн-түләүне** сайлап алу файдаланучыга ничек уңайлы булуга бәйле.* Кайбыч таңнары; *дөр.:* **онлайн түләү**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-УКЫТУ́** *и. ялг. Алдынгы практикаларны кулланып, эчке корпоратив идарә технологияләре, уку-укыту һәм стажировкалар узу мәйданчыклары, проект офислары булдырырга, **онлайн-укыту** технологияләрен үстерергә кирәк.* Кайбыч таңнары; *дөр.:* **онлайн укыту**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-УНИВЕРСИТЕ́Т** *и. ялг. Клод-Луи Галльен фикеренчә, проблемаларның күбесе **онлайн-университетларга** кагыла һәм бу проблеманы виртуаль спортны үстергәндә чишеп булачак.* 2013 Универсиадасы блогы; *дөр.:* **онлайн университет**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-ФО́РМА** *и. ялг. Катнашу өчен ато-rt.tatarstan. ru сайтындагы **онлайн-форманы** 15 сентябрьгә кадәр тутырырга кирәк.* Идел таңнары; *дөр.:* **онлайн форма**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОНЛАЙН-ЭНЦИКЛОПЕ́ДИЯ** *и. ялг. Галимнәр татар **онлайн-энциклопедиясенең** концепциясен әзерләгән.* Казан утлары; *дөр.:* **онлайн энциклопедия**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ОПЕРА́ЦИЯЛӘҮ** *ф. ялг. Без берәүне дә үз ихтыярыннан тыш **операцияләмибез**.* Г. Әпсәләмов; *дөр.:* **операция ясау**.

**О́ПИСЬ** *и.* Описька, описе, описена, описьлар; *ялг.:* **описькә, описенә, описьләр**. – *Безнең әйберләрне **описькә** алыгыз!* Ф. Садриев. *Бер кочак кәгазьләр – **описьләр** белән килгән иде ул.* Татар-информ; *к.* **повесть**.

**ОРИГИНА́Л** *и.* Төп нөсхә; күчерү, яңадан бастыру өчен хезмәт иткән нәрсә; оригинальлеге белән танылган кеше; *ялг.:* **оригинал рәсем, оригинал язу**. *Ә менә «Отдамся в добрые руки» дигән **оригинал** язулы футболка киеп йөргән Салаватны гына үзенә алучы изге җаннар табылмады.* Тамаша. *Мамадышның Совет урамында беркетелгән территорияләрдә фигураларны иң **оригинал** бизәү буенча 1 нче урын – Белоснежка һәм җиде гном композициясе өчен «Коррекцияләү мәктәбе»нә һәм «Боз капкалар» фигурасы өчен «Мамадыш ТКХ» коллективларына бирелде.* Мамадыш муниципаль районы ММЧ мәгълүмати сайты; *чаг.:* **оригиналь**; *к.* **вокаль**.

**ОРИГИНА́ЛЬ** *с.* Төп, оригинал булган; башкаларга охшамаган; мөстәкыйль иҗат нәтиҗәсендә туган: **оригиналь образ, оригиналь номер, оригиналь әсәр**; *чаг.:* **оригинал**; *к.* **вокаль**.

**ОРНА́МЕНТЛАШТЫРУ** *ф. ялг. Мөселман сәнгате өчен характерлы булган тоташ* ***орнаментлаштыру*** *принцибы XI гасыр азагы – XII гасыр башы болгар сәнгать предметларында киң таралыш алган.* Татарстан Республикасы Диния нәзарәте; *дөр.:* **орнаментлау, орнамент ясау, орнамент белән бизәү**; *к.* **стимуллаштыру**.

**ОРУ́ДИЕ** *и*. Орудиегә, орудиесе, орудиесенә; *ялг.:* **орудиега, орудиесы, орудиесына**. *ССРБга һөҗүм итү өчен 5,5 млн кеше, 3 712 танк, 47 260 кыр* ***орудиесы*** *һәм миномётлар, 4 950 сугыш самолёты тупланган.* Википедия. *Беренче снарядлар шартлаганын күргәч, булган* ***орудиелар*** *белән дә шул хәзерләгән хисап буенча залп бирергә куштым*. Гасырлар авазы. ***Орудиены*** *икенче позициягә күчерү өчен ярдәмгә Дәүләткировны җибәрәләр.* Туган як; *к.* **звание**.

**ОРУ́ДИЯ** *и. ялг. Автомашинасы белән алгы сызыкка сугыш кораллары да, кызылармиячеләрнең үзләрен дә ташый, артиллерия* ***орудиясе*** *тагып та йөри.* Татарстан яшьләре. ***Орудияләрдән*** *атып, күп кенә биналарны җимерәләр, Благовещение соборының гөмбәзен ишәләр*. Шәһри Казан. *1941 елның 4 июлендә команда составында – 22, кече команда составында – 39, рядовойлар составында – 256 кеше, 85* ***орудия****, 3 пулемет җайланмасы, 13 автомашина була.* Авыл таңнары; *дөр.:* **орудие**; *к.* **предприятия**.

**ОТЕ́ЛЬ** *и.* Отельгә, отеле, отеленә, отельләр; *ялг.:* **отельга, отелена, отельлар**. ***Отельга*** *әйләнеп кайткачтын да тәрҗемәчебез, артык үгет-нәсихәт биреп тормый гына, үз номерына юл тотты.* Р. Мөхәммәдиев. *Без яшәгән* ***отельда*** *атнасына ике тапкыр «Төркия төннәре» үткәрелде.* Кызыл таң. *Һәр* ***отельның*** *үз транспорты икән: кемнедер – җиңел машина, кемнәрнедер зур автобуслар, микроавтобуслар көтә*. Сабантуй; *к.* **апрель**.

**ОХША́У** *ф.* Кемгә яки нәрсәгә охшаш булу, шуны хәтерләтү; *ялг.:* кемне яки нәрсәне ярату мәгънәсендә; *Аңа* ***диңгезче булу*** *шулкадәр* ***охшый*** *ки, ул хәтта контракт буенча да калу теләге белән яна.* Кәеф ничек? *Әмма донор булу миңа* ***охшый****, кеше гомерен саклап калырга ярдәм итәсең бит, – диде ул.* Кайбыч таңнары; *чаг.* **ошау**.

**О́ЧЕРК** *и*. Очеркка, очеркы, очеркына; *ялг.:* **очергы, очергына**. *«Публицистика» номинациясендәге өченче урын Санкт-Петербургтан беренче татар телендәге «Нур» газетасын оештыручы һәм аның беренче мөхәррире Атаулла Баязитов*

*(1847–1911) турындагы биографик* ***очергы*** *өчен журналист Әлфинур ханым Гафуровага бирелгән*. Татар-информ. *«Исемдә калганнар» автобиографик* ***очергында*** *без мондый юлларны укыйбыз: «Әни Печән базарына кәләпүш чыгарганда, яки бер хезмәт илә байларның өенә барганда, кайвакыт мине дә ияртеп баргалый иде».* Габдулла Тукайга багышланган Интернет-портал; *к.* **гибрид**.

**ОША́У** *ф.* Күңелгә хуш килү, яраклы булу; *ялг.:* формасы, кыяфәте кемне яки нәрсәне хәтерләтү мәгънәсендә. *Төрбәләргә* ***ошаган*** *200 еллык таш амбарлар, урамнарда Татар теле, Татар киеме.* Iskesabai.ru. *Чыннан да Мәрҗәнә кайчагында нәни кошка, ә кайвакыт асылташка* ***ошаган*** *иде.* А. Нәҗми. *Аларның хәтта милли киемнәре безнең халыкларныкына* ***ошаган****, телләрендә дә бик күп борынгы сүзләр дә сакланып калган.* Татар әдипләре. *Аның иҗат стиле башкаларга* ***ошамаган****, үзенчәлекле һәм заманча.* Яңарыш; *чаг.* **охшау**.

**ӨСТЕНЧЕЛЕ́К** *и. ялг. Бүгенге тормышны нефтедолларлар гына ясый, шунлыктан, минемчә, өстә санап киткән геройлар* ***өстенчелек*** *итә.* Матбугат.ру; *дөр.:* **өстенлек**; *к.* **каллиграфчы**.

**ПАКЪ** *с. ялг. Йөзе акның күңеле дә* ***пакъ****, диләр*. Кызыл таң. *Аның кешелек кыйбласы һәрвакыт бер максатка – милләтнең яшь буынын аек акыллы, физик сәламәт, рухи камил, әхлакый* ***пакъ*** *һәм эшчән итеп тәрбияләүгә юнәлгән.* Яңарыш; *дөр.:* **пакь**.

**ПАКЪЛӘНДЕРҮ́** *ф. ялг. Ел саен 15 октябрьгә кадәрге вакыт бабаларыбыз алдындагы изге бурычны үтәү, күңелләрне* ***пакъләндерү****, рухны яңарту чоры булсын!* Безнең гәҗит. *Ничек соң бу 27 яшьлек малай дөньяны* ***пакъләндерергә*** *уйлаган?* Сәхнә; *дөр.:* **пакьләндерү**.

**ПАКЪЛӘНҮ́** *ф. ялг. Кешелекнең яңа гасыры рухыбыз* ***пакъләнә*** *бару белән бергә башланыр.* Казан утлары; *дөр.:* **пакьләнү**.

**ПАКЪЛӘ́Ү** *ф. ялг. Терлекне авылдан, мөселманча* ***пакъләп*** *суеп алып киләләр*. Кызыл таң; *дөр.:* **пакьләү**.

**ПАКЪЛЕ́К** *и. ялг. Кар* ***пакълеге*** *өстенә бүре каны ургылып акты.* З. Мурсиев. *Сәлкешләрне күңел* ***пакълеге*** *белән бергә, табигать чисталыгын сакларга да өндиләр*. Шәһри Казан; *дөр.:* **пакьлек**.

**ПАНЕ́ЛЬ** *и.* Панельгә, панеле, панеленә, панельләр; *ялг.:* **панельга, панелена, панельлар**. *Караш алгы* ***панельга*** *төшә,*

*спидометрның угы 120 не күрсәтә, сәгать 23:58.* Шәһри Казан. *Инде лифт шахтасы мөмкинлек биргән йортларда ишекне 80 см итеп киңәйтү һәм инвалидлар өчен төймәләр тезелгән* ***панельны*** *горизонталь кую карала.* Татар-информ. *Казан урамнарындагы хәлләрне бүген 269 видеокамера күзләп тора, алар «күргәннәр» исә 6 плазма* ***панельдан*** *торган видеостендка чыгарыла.* Татар-информ; *к.* **апрель**.

**ПАН-ИСЛАМИ́СТ** *и. ялг. Әйтик, билгеле ислам таратучы Габдеррәшит Ибраһимов* ***«пан-исламист»*** *булган, СССРда мөселманнар мохтариятен кору турында хыялланган, тик советлардан качкан татарлардан зур яклау ала алмаган.* «Азатлык радиосы» сайты; *дөр.:* **панисламист**; *к.* **фотоальбом**.

**ПАН-ТЮРКИ́СТИК** *с. ялг. Газета үзенең битләрендә турыдан-туры марксистик идеяләрне пропагандалый, буржуаз-милләтчеләргә, аерым алганда, «Мөселман иттифакы» партиясенә,* ***пан-тюркистик*** *«Тәрҗеман» газетасына каршы көрәш алып бара.* М. Хәсәнов; *дөр.:* **пантюркистик**; *к.* **фото-альбом**.

**ПА́НЦИРЬ** *и.* Панцирьга, панцире, панцирена, панцирьлар; *ялг.:* **панцирьгә, панциренә, панцирьләр; панцирга, панциры, панцирына, панцирлар; панцыры, панцырга, панцырлар**. *Дөрес тукланган сәламәт ташбаканың* ***панциры*** *каты һәм хәрәкәтсез булырга тиеш.* Ватаным Татарстан. *Һәрвакыт кулларын йомарлап җиң очларына тыгып, менә хәзер, ул-бу була калса,* ***панциренә*** *кереп качарга әзер ташбака шикелле бераз куырылып, алга бөкерәебрәк йөри иде ул.* Л. Ибраһим-Вәлиди; *к.* **лагерь**.

**ПАРА́Д** *и.* Парадка, парады, парадына, парадлар; *ялг.:* **паратка, параты, паратына, паратлар**. *Яңа Чишмә урта мәктәбе кадетчылары кадетчы исеме бирү тантанасы хөрмәтенә узган* ***паратта*** *үзләрен чын гвардиячеләр итеп таныттылар.* Яңа Чишмә хәбәрләре; *к.* **гибрид**.

**ПАРО́ЛЬ** *и.* Парольгә, пароле, паролենә, парольләр; *ялг.:* **парольга, паролена, парольлар**. ***Парольсыз*** *вай-фай яхшы нәрсә инде ул.* Татар-информ. ***Парольларын*** *онытканнар алар барысы да, шуңа үз битләренә керә алмыйлар.* Туган як; *к.* **апрель**.

**ПАРОХО́Д** *и.* Пароходка, пароходы, пароходына, пароходлар; *ялг.:* **парохотка, парохоты, парохотына, парахотлар**; *к.* **гибрид**.

**ПАРТИЗАНЧЫЛЫ́К** *и. ялг. --- бәлки,* ***партизанчылык*** *бик яхшыдыр, әмма монда, үзебезнең эшче туганнарыбыз белән*

*партизанча көрәшү бернинди киртәгә дә сыймый ---*. Казан утлары; *дөр.:* **партизанлык**; *к.* **каллиграфчы**.

**ПАСТЕ́ЛЬ** *и*. Пастельгә, пастеле, пастеленә, пастельләр; *ялг.:* **пастельга, пастелена, пастельлар**; *к.* **апрель**.

**ПА́СТЕРЛАУ** *и. ялг. Җилләтү һәм **пастерлау** цехында аннан аммиакның артык микъдары алына, микроблар юк ителә.* Кызыл таң; *дөр.:* **пастеризацияләү, пастеризация ясау**; *к.* **реагирлау**.

**ПАТРУ́ЛЬ** *и*. Патрульгә, патруле, патруленә, патрульләр; *ялг.:* **патрульга, патрулена, патрульлар**. *Шулай ук төнге **патрульга** да чыктык, тревога белән дә чакыралар иде.* Татар-информ. *--- андый урыннарда Татарстан эчке эшләр органнарының 1,9 мең хезмәткәре, 200 дән артык хезмәти техникасы көн саен хокук һәм җәмәгать тәртибе сагында тора, **патрульда** һәм урманлыкларда оператив-профилактика эшләрендә катнаша, гражданнар транспорт чаралары белән урманга кермәсен өчен кисәтү эшләре алып бара*. Татар-информ; *к.* **апрель**.

**ПӘНҖАБИ́** *и*. Пәнҗабигә, пәнҗабие, пәнҗабиенә; *ялг.:* **пәнҗабисе, пәнҗабисенә**; *чаг.:* **гәләфи**.

**ПӘРИ́** *и*. Пәригә, пәрие, пәриенә; *ялг.:* **пәрисе, пәрисенә**. *Очы юк юешлек тәнне баса иде, албасты **пәрисе** баскан кебек изә иде.* Г. Исхакый. *--- ник дисәң дию **пәрисенең** маңгай уртасында чәйтабак зурлыгында бары бер генә күзе, ниндидер яшькелт төс белән ялтырап тора ---*. В. Ильясов; *к.* **әби**.

**ПЕДА́ЛЬ** *и*. Педальгә, педале, педаленә, педальләр; *ялг.:* **педальга, педалена, педальлар**; *к.* **апрель**.

**ПЕДУЧИ́ЛИЩЕ** *и*. Педучилищега, педучилищесы, педучилищесына, педучилищелар; *ялг.:* **педучилищегә, педучилищесе, педучилищесенә, педучилищеләр**. *--- **педучилищенең** татар бүлеге студентлары һәм укытучылары катнашында узган очрашулар, шулай ук Балезино районында, 1557 елда нигез салынган борынгы Кистем авылында, Глазов шәһәрендә булу да онытылмаслык тәэсирләр калдырды*. Казан утлары; *к.* **атташе**.

**ПЕНА́ЛЬТИ** *и*. Пенальтига, пенальтие, пенальтиена, пенальтилар; *ялг.:* **пенальтигә, пенальтиенә, пенальтиләр**. *Шуннан соң турнир кагыйдәләре буенча ике команда капкасына да **пенальтиләр** бәрү үткәрелде.* Самара региональ «Дуслык» һәм Самара шәһәр «Ак бәхет» иҗади-иҗтимагый оешмаларының уртак сайты; *к.* **бигуди**.

**ПЕНСНЕ́** *и.* Пенснега, пенснесы, пенснесына, пенснелар; *ялг.:* **пенснегә, пенснесе, пенснесенә, пенснеләр**. *Инженер, үзенең һәрвакыт бимазалый торган* ***пенснесен*** *урыныннан кузгата-кузгата, Вәлиевкә сүз кушты.* А. Алиш. *Якты күл буе Әмирхан* ***пенснесенә*** *орынып алды да, елмаеп, Тукайга борылды.* Габдулла Тукайга багышланган интернет-портал; *к.* **атташе**.

**ПЕРЕЕ́ЗД** *и.* Переездда, переездддан; *ялг.:* **переезда, переездан**. *Алар авылы янындагы* ***переезда*** *авария булган, ике кеше хастаханәгә озатылган.* Туган як; *к.* **поезд**.

**ПЕ́РЕКИСЬ** *и.* Перекиська, перекисе, перекисена, перекисьлар; *ялг.:* **перекиськә, перекисенә, перекисьләр**. *Өч бал кашыгы* ***перекисьне*** *илле миллилитр суга салалар да шунда чүпрәк чылатып, авырткан җиргә компресс итеп куялар яки сызлаган тәнне ышкыйлар.* Ватаным Татарстан. *Ул исемлектә органик* ***перекисьләр*** *һәм оксидлаша торган матдәләр дә шактый.* Татар-информ; *к.* **повесть**.

**ПЕ́РЕПИСЬ** *и.* Перепиorigська, переписе, переписена, переписьлар; *ялг.:* **переписькә, переписенә, переписьләр**. *Менә монда аңлый алсаң, Кальми Бязинга 68 яшь диелгән, әле ул алдагы* ***переписьтә*** *язылган икәнлеге әйтелә.* Безнең гәҗит. *Шуның өстенә, 1937 еллардагы террор нәтиҗәсендә күпләгән асыл ирләр төрмәгә утыртыла һәм аларның күбесе үтерелә, бу халыкның табигый артымын бик нык киметә һәм* ***переписьнең*** *дөрес нәтиҗәләрен халыктан яшерергә мәҗбүр булалар.* Р. Зарипов; *к.* **повесть**.

**ПЕРИ́ОД** *и.* Периодка, периоды, периодына, периодлар; *ялг.:* **периотка, периоты, периотына, периотлар**; *к.* **гибрид**.

**ПЕРСОНА́Л** *и.* Учреждение яки оешма хезмәткәрләре; *ялг.:* **персонал эш, персонал компьютер**. *Җыелышта төп мәсьәлә: Нәби Дәүлинең* ***персонал*** *эше карала.* Тарихи шәхесләр... ***Персонал*** *эш.* Х. Камалов; *чаг.:* **персональ**; *к.* **вокаль**.

**ПЕРСОНА́ЛЬ** *с.* Аерым кешегә караган, шәхси: **персональ эш, персональ машина**; *чаг.:* **персонал**; *к.* **вокаль**.

**ПЕСИ́** *и.* Песигә, песие, песиенә; *ялг.:* **песисе, песисенә**; *к.* **әби**.

**ПЕЧА́ТЬ** *и.* Печатька, печате, печатена, печатьлар; *ялг.:* **печатькә, печатенә, печатьләр**. *Мин аны сүтәргә ашыкмадым, башта* ***печатенә****, кире адресына күз төшердем: «Казан».* Ә. Маликов. *2007 елдан башлап язмалар дөрес тәрҗемә ителгәнме, күргәзмә материаллар,* ***печатьләр****, штамплар дөрес ясалганмы,*

*теге яки бу оешмада милли телләрдә чыккан матбугат басмаларын алдыраламы – шуларның барысы да күздә тотыла.* Кызыл таң; *к.* **повесть**.

**ПЕЧЕ́НЬЕ** *и.* Печеньега, печеньесы, печеньесына; *ялг.:* **печеньегә, печеньесе, печеньесенә**. *Кибеттә сайланып тормады, бер килограмм солы **печеньесе**, бер килограмм шоколад кәнфит үлчәтеп алды да, сатучы кыз Тәнзиләгә рәхмәт әйтеп кайтырга ашыкты.* А. Хайртдинова. *Республика кулланучылар берлеге рәисе җәмгыятьтә җитештерелә торган бөтен төр продукцияне – макарон, **печеньеләр**, конфетларны, тортларны караганнан соң аларның үзкыйммәте белән кызыксынды.* Туган як; *к.* **ателье**.

**ПИГМЕНТЛАШУ́** *ф. ялг. **Пигментлашу** күбрәк яшелләнү, саргаю формасында була.* Биология; *дөр.:* **пигментлану, пигмент бүлеп чыгару, пигмент белән буялу** һ.б.ш.; *к.* **стимуллаштыру**.

**ПИКЕ́** *и.* Пикега, пикесы, пикесына, пикелар; *ялг.:* **пикегә, пикесе, пикесенә, пикеләр**. *ТБ – 3Фебез **пикегә** керде, бомба люклары ачылды, үлем йөге аска коелды.* Казан утлары. *Шуның белән **пикегә** төшә башлыйм һәм прожектордан котылам.* Кызыл таң; *к.* **атташе**.

**ПИ́КСЕЛЬ** *и.* Пиксельгә, пикселе, пикселенә, пиксельләр; *ялг.:* **пиксельга, пикселена, пиксельлар**; *к.* **апрель**.

**ПИОНЕРЧЫЛЫ́К** *и. ялг.; дөр.:* **пионерлык**; *к.* **каллиграфчы**.

**ПИ́САРЬ** *и.* Писарьга, писаре, писарена, писарьлар; *ялг.:* **писарьгә, писаренә, писарьләр**. *Ә сезнең сакчыларыгыз бар бит, хөрмәтле **писарьләрегез** бар.* Казан утлары. *Тугыз яшь тулганда Яковны Мамадыш өязенең Җүкәче авылына волость **писарьләре** әзерли торган удельное училищега укырга җибәрәләр.* Матбугат.ру; *к.* **лагерь**.

**ПИ́САРЬЛЕК** *и. ялг. Өченче рейхка хезмәт итүдә аның роле зур түгел иде, ул нindидер бер **писарьлек** вазифасын башкарган.* Булмас.ру; *дөр.:* **писарьлык**; *к.* **лагерь**.

**ПИТРА́У** *и.* Питрауга, Питравы, Питравына, Питраулар; *ялг.:* **Питрауы, Питрауына**. *Татарның Сабантуе, керәшен татарларының **Питрауы**, русларның «Каравон» бәйрәмендә уртаклыклар күп.* Кайбыч таңнары. *Җөри **Питрауы** Республика фестивале дәрәҗәсенә күтәрелде һәм Россия Федерациясенең күпсанлы халкын берләштерүче, керәшеннәрнең мәдәни мирасын, рухи байлыгын күрсәтүче мөһим чарага әверелде.* Туганайлар; *к.* **билбау**.

**ПЛАКИРЛА́У** *ф. махс.* Металл табакларын башка металл катламы белән каплау, металл эшләнмәләргә юка алтын, көмеш һ.б.ш. пластинкалар беркетү; су юудан саклау өчен сөзәк җирләрне, туфрак өемнәрен кәс белән каплау; *к.* **легирлау**; *чаг.:* **реагирлау**.

**ПЛА́СТЫРЬ** *и.* Пластырьга, пластыре, пластырена, пластырьлар; *ялг.:* **пластырьгә, пластыренә, пластырьләр**. *Йокы бүлмәсенә кереп, ул, ниһаять, пәриле футболкасын салгач кына Сәгъдия аның тәнендәге сыдырылган урыннарны, йөрәк турына ябыштырган* ***пластырьне*** *күреп алды.* М. Маликова. *Бармагына ябыштырган* ***пластыренә*** *карап алды да, сүзен дәвам итте ул.* Күрше; *к.* **лагерь**.

**ПО́ВЕСТЬ** *и.* Повестька, повесте, повестена, повестьлар; *ялг.:* **повестькә, повестенә, повестьләр**. *Кемгә ничек тоеладыр, мин бу* ***повестьне*** *рухи автобиографиям итебрәк карыйм.* М. Кәбиров. ***Повестьне*** *татар телендә укып чыккач, тәүге кичерешләрем яңарды, бу философик әсәр тагын тирән дулкынландырды.* Кызыл таң. *Әйтергә кирәк, Р. Сабырның «Хәят» пьесасы татар классигы Фатих Әмирханның шул исемдәге* ***повестенә*** *нигезләнеп иҗат ителгән.* Татар-информ.

Рус теленнән һәм рус теле аркылы кергән алынма сүзләрнең **-ть** га беткәннәрен төрләндергәндә III зат тартым кушымчасының алгы рәт варианты кушыла. Ләкин аннан соң килгән кушымчаларда яки башка категорияләр белән төрләндергәндә, арткы рәт кушымчалары ялгана. **-шь, -сь, -зь, -чь** ларга беткән сүзләр дә шул ук закончалыкка буйсына.

**ПОДПО́ЛЬЕ** *и.* Подпольега, подпольесы, подпольесына; *ялг.:* **подпольегә, подпольесе, подпольесенә**. *Ләкин реакция көчәюе аркасында Хөсәен Ямашев* ***подпольегә*** *китә һәм озак та үтми үлә.* Габдулла Тукайга багышланган интернет-портал; *к.* **ателье**.

**ПОДРАЗДЕЛЕ́НИЕ** *и.* Подразделениегә, подразделениесе, подразделениесенә; *ялг.:* **подразделениега, подразделениесы, подразделениесына**. *Алардан тыш, ярдәмчел* ***подразделениелар*** *барлыкка килде.* Ш. Асылгәрәев. *Ләйлә Фәйзелгаян кызы 2000 елда Идел буе федераль округында юридик* ***подразделениелар*** *арасында 1 урынны яулаган.* Өмет. *Яктыра башлап, күрше* ***подразделениедан*** *пулеметлар, минометлар атарга тотынгач, немецлар ниһаять тындылар.* Татар әдипләре; *к.* **звание**.

**ПОДРАЗДЕЛЕ́НИЯ** *и. ялг. Хәрби часть дигәннән, хәзер Русия армиясендә һәр* ***подразделениядә*** *православлау дине атакайлары штат*

*буенча хезмәт итәләр*. Безнең гәҗит. *Хокук сайлау органнарында эшләгән чорда ул үзен яхшы яктан гына күрсәтте һәм шуның белән үз **подразделениясе** эшчәнлеге нәтиҗәләрен күтәрергә булышты.* Авыл таңнары; *дөр.:* **подразделение**; *к.* **предприятия**.

**ПОДЪЕ́ЗД** *и*. Подъездда, подъезддан; *ялг*. **подъезда, подъездан**. *Хәтта, аны **подъезда** күрше әбисе күреп, танымады*. Р. Ахунова. ***Подъездан** кереп, баскычтан күтәрелүгә Камилнең фатир ишеге ачык, ә ишек төбендә таякка таянып, ябык кына гәүдәле озын буйлы, матур йөзләренә килешле итеп мөлаем елмаеп ир үзе басып тора иде*. Л. Ибраһим-Вәлиди. *Минә бу чемоданны күрше **подъездагы** йортның 12 нче квартирасына илтеп тапшырырсың*. Белем.ру; *к.* **поезд**.

**ПО́ЕЗД** *и*. Поездда, поездддан; *ялг*. **поезда, поездан**. *Утыз ел элек без сезнең белән бергә Тулага **поезда** барган идек*. Д. Гыйсметдин. ***Поездан** төшеп, урман аша 2–3 км юл үтеп мәктәпкә килеп җиткәндә караңгы төшкән иде*. Р. Зарипов.

Рус теленнән һәм рус теле аркылы башка телләрдән кергән алынмаларга кушымчалар ялганганда, нигез ахырында һәм кушымча башында бер үк фонемалар туры килгәндә, аларның керешүе күзәтелә. Әмма бу башлыча сөйләмдә генә кала, язуда чагылмый, чөнки морфемалар – һәм тамыр, һәм кушымча – язуда үз тулылыгын сакларга тиеш. Кагыйдә тамыр ахырында ике бер үк төрле фонема булып, аңа шул ук фонемага башланган кушымча ялганганда гына язмада чагыла; *к.* **металл** (*к.* Татар грамматикасы, Т. I, 2015: 146–147 б.).

**ПОЛИТ-АГАРТУ́** *и. ялг. Училищега узган гасырда китапханә техникумы һәм **полит-агарту** техникумы ачылган 1936 елда нигез салына.* Алабуга нуры; *дөр.:* **политагарту**; *к.* **мед-сестра**.

**ПОЛИТ-БҮЛЕ́К** *и. ялг. **Полит-бүлек** буенча ярдәмчесе майор Илларионов яңа кабул ителгән коммунистларга партбилетлар тапшырырга китте*. Г. Әпсәләмов; *дөр.:* **политбүлек**; *к.* **мед-сестра**.

**ПОЛИТ-БЮРО́** *и. ялг. **Полит-бюроның** карт-корылардан гына торуыннан көлә идек*. Татарстан яшьләре; *дөр.:* **политбюро**; *к.* **мед-сестра**.

**ПОЛИТ-МЕ́НЕДЖЕР** *и. ялг. Ул разведканың ышанычлы вәкиле һәм аена 2 000 евро хезмәт хакы ала торган заманча **полит-менеджер***. Татарстан яшьләре; *дөр.:* **политменеджер**; *к.* **мед-сестра**.

**ПОЛИТ-РАБО́ТНИК** *и. ялг. Ә үзем ул чакта диңгезчеләргә интернациональ тәрбия бирүче* ***полит-работник***. Безнең мирас; *дөр.:* **политработник**; *к.* **мед-сестра**.

**ПОЛИТ-СӘГА́ТЬ** *и. ялг. Тукта, иртәгә* ***полит-сәгатьтә*** *Гадения апа сораса, ни дип җавап бирермен?* З. Хөснияр; *дөр.:* **политсәгать**; *к.* **мед-сестра**.

**ПОЛИТ-ЭКОНО́МИЯ** *и. ялг. Куйбышевның ярдәмчесе, язучы Халик Садри, Казан профессоры,* ***полит-экономия*** *укытучысы Җәләев Шәһит тә аның укучылары иде.* Бөтендөнья татар конгрессы; *дөр.:* **политэкономия**; *к.* **мед-сестра**.

**ПОЛОЖЕ́НИЕ** *и.* Положениегә, положениесе, положениесенә; *ялг.:* **положениега, положениесы, положениесына**. *Бүген Мәскәүнең шундый йортлар урынына яңаны салу өчен акча бүлеп бирү турындагы яңа* ***положениесы*** *бар.* Безнең гәҗит. *Бәйгенең кагыйдәнамәсе (****положениесы****) буенча оештыручыларның төп максаты – китапханәчеләрнең үз эшләрендә балаларга татар телендәге китапларга ничек мәхәббәт тәрбияләүләрен күрү иде.* Татар-информ. *Суд карарын көтмичә, законсыз* ***положениелар*** *юкка чыгарылган.* Татар-информ; *к.* **звание**.

**ПОЛОЖЕ́НИЯ** *и. ялг. Нишлисең, өстән килгән* ***положения*** *шундый.* Д. Салихов. *Мин* ***положенияләрен*** *укып чыктым, эшләре матур язылган, ярдәм итү хакында да, тик аларның берсенең дә үтәлгәне юк һәм рәсми хакимият аңа үзе дә кул селтәде булса кирәк.* «Азатлык радиосы» сайты. *Аның өчен әлеге уртак эшнең* ***положениясен*** *булдырырга кирәк иде.* Татар-информ; *дөр.:* **положение**; *к.* **предприятия**.

**ПОМЕ́СТЬЕ** *и.* Поместьега, поместьесы, поместьесына; *ялг.:* **поместьегә, поместьесе, поместьесенә**. *Йомышлы татарларның 136 авылда* ***поместьеләре*** *булган.* Акъегет авылы тарихы; *к.* **ателье**.

**ПОРТМОНЕ́** *и.* Портмонега, портмонесы, портмонесына, портмонелар; *ялг.:* **портмонегә, портмонесе, портмонесенә, портмонеләр**; *к.* **атташе**.

**ПОРТФЕ́ЛЬ** *и.* Портфельгә, портфеле, портфеленә, портфельләр; *ялг.:* **портфельга, портфелена, портфельлар**. ***Портфельга*** *китап-дәфтәрләрне, ручка, карандаш, пластилин, краскалар, линейка салырга*. Белем.ру; *к.* **апрель**.

**ПО́РШЕНЬ** *и.* Поршеньга, поршене, поршенена, поршеньнар; *ялг.:* **поршеньгә, поршененә, поршеньнәр**. *Әйтик, мотордагы*

***поршеньнәргә*** *май килми башлады, ди.* Х. Камалов. *Элегрәк терсәкле валларны шомарту, цилиндр һәм* ***поршеньнәрне*** *үткенләтү өчен Ульяновскидагы автосервиска барырга кирәк була.* Яңа тормыш. *«Газ» төбенә кадәр чытырдатып басылды, «тимер таяк» бу минутта* ***поршеньне****, ә Хәмдүнәнең авызы яхшылап майланган цилиндрны хәтерләтте*. Ф. Бәллүр; *к.* **пристань**.

**ПОСО́БИЕ** *и.* Пособиегә, пособиесе, пособиесенә; *ялг.:* **пособиега, пособиесы, пособиесына**. *Быелгы йомшаклыкның тагын берничә сәбәбен күрсәтеп киткәндә, болай дияр идем: мәктәпләрдә дәреслекләр иске, җитешми, методик* ***пособиелар*** *да аз; сәгатьләр саны барлык программаны да үзләштерергә мөмкинлек бирми, аннары күп татар мәктәпләрендә укучылар саны аз (күп укучылары олимпиадаларда сирәк катнашалар).* Яңарыш. *«Бала тугач бирелә торган* ***пособиены*** *алу өчен генә табылган бала ул», – дип әйтә ди әбисе*. Безнең гәҗит. *Ә инде* ***пособиедан*** *процент тотып калуга килгәндә, Федераль Закон буенча («Об исполнительном производстве», 69 маддә) ялгыз ата яки анага бирелгән пособие тотып калынырга тиеш түгел.* Татарстан яшьләре; *к.* **звание**.

**ПОСО́БИЯ** *и. ялг. 2009–2010 елларда хөкүмәт минималь хезмәт хакын, эшсезлек буенча* ***пособия*** *күләмен, пенсияләрне арттырып, халыкның кереме сизелерлек кимүгә юл куймый торды.* Татарстан яшьләре. *Күп вакытта балаларының* ***пособиясенә*** *яшәп килде, эчкечелеккә бирелде*. Өмет. *Пенсияләр,* ***пособияләр****, башка социаль түләүләргә 1 млрд 018 млн 665 мең сум акча юнәлдерелгән.* Якты юл; *дөр.:* **пособие**; *к.* **предприятия**.

**ПОТЕНЦИА́Л** *и.* Берәмлеккә тигез булган уңай корылманы чиксезлектән кырның билгеле бер ноктасына күчергәндә эшләнгән эш микъдары белән үлчәнә торган зурлык; берәр максат белән файдаланыла торган чаралар җыелмасы; берәр нәрсәнең көч-куәт дәрәҗәсе, мөмкинлекләре; *ялг.:* **потенциал аудитория, потенциал җинаятьче**. ***Потенциал*** *кан бирүчеләрнең яшь контингенты – медицина күрсәткече яхшы булган 18 дән 60 яшьлек гражданнар.* Идел таңнары. *Аның* ***потенциал*** *аудиториясе – 35 миллионнан артык телетамашачы.* Яңарыш. *Бизнес-платформа – ул бизнес-проект авторларын һәм* ***потенциал*** *инвесторларны он-лайн режимында берләштерергә мөмкинлек бирүче ресурс*. Идел таңнары; *чаг.:* **потенциаль**; *к.* **вокаль**.

**ПОТЕНЦИА́ЛЬ** *с.* Запаста булган, яшерен, эчке: **потенциаль көч**; *чаг.:* **потенциал**; *к.* **вокаль**.

**ПОТЕНЦИРЛА́У** *ф. ялг.; дөр.:* **потенциалын табу**; *к.* **реагирлау**.

**ПО́ЧЕРК** *и.* Почеркка, почеркы, почеркына; *ялг.:* **почергы, почергына**. *Графологлар фикеренчә, алар* ***почергына*** *карап кешегә аның холкы, хисләр дөньясы, хирыс яклары хакында сөйли ала һәм бу аңа үз гамәлләрен тиешле якка борып җибәрергә ярдәм итәчәк.* Сабантуй. *Һәр композиторның да үзенә генә хас үзенчәлеге, «****почергы****» бар һәм аннан качуы бик авыр.* Саба таңнары; *дөр.:* **почеркы**; *к.* **гибрид**.

**ПОШИ́** *и.* Пошига, пошие, пошиена; *ялг.:* **пошисы, пошисына**; *к.* **бигуди**.

**ПӨХТӘЛЕКЛЕ́** *с. ялг. Кияү бик* ***пөхтәлекле*** *безнең, өйдә дә чисталык, тәртип ярата, киемнәрен кая җитте шунда ташлап калдырмый.* Казан утлары; *дөр.:* **пөхтә**; *к.* **каллиграфчы**.

**ПРАВОСЛА́ВИЕ** *и.* Православиегә, православиесе, православиесенә; *ялг.:* **православиега, православиесы, православиесына**. *Чөнки без* ***православиега*** *мәҗүсилектән күчкәнбез.* Безнең гәҗит. ***Православиеда*** *да шундый ук ситуацияләр бар, ләкин баптистлар чиркәүгә килеп тәртип урнаштырмыйлар.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар; *к.* **звание**.

**ПРАВОСЛА́ВИЯ** *и. ялг.* ***Православия*** *руханилары үгетенә бирелеп, Аскал кахан Шәмси Тәбир мулланы монахлар хөкеменә бирә.* М. Хәбибуллин. *Христиан дине, бигрәк тә* ***православия*** *алтынга күмелде.* Татар, уян! *Бередә мөселман мәчете белән* ***православия*** *соборы янәшә тора.* Татар заманы; *дөр.:* **православие**; *к.* **предприятия**.

**ПРЕДОХРАНИ́ТЕЛЬ** *и.* Предохранительгә, предохранителе, предохранителенә, предохранительләр; *ялг.:* **предохранительга, предохранителена, предохранительлар**; *к.* **апрель**.

**ПРЕДПРИЯ́ТИЕ** *и.* Предприятиегә, предприятиесе, предприятиесенә; *ялг.:* **предприятиега, предприятиесы, предприятиесына**. *Пакетлап сату аерым шәхесләр һәм* ***предприятиелар*** *өчен эшләнгән.* Шәһри Казан. *2009 елда* ***предприятиенң*** *8 сөрү тракторы (Алтай, ДТ), 3 куәтле (1 Кировец, 2 Т – 150 К), 8 универсаль (Беларусь), техник культуралар өчен (рәт арасын сөрә торган) – 1 (Т – 70) трактор булган.* Википедия; *к.* **звание**.

**ПРЕДПРИЯ́ТИЯ** *и. ялг. – Беренче чиратта, – дип билгеләп үтте Идрисов, – **предприятиянең** автобус паркын тулыландырырга мөмкин булды: бүгенге көндә өч ПАЗ сатып алынды, ел ахырына кадәр яңа «Фиат»лар алып кайтырга планлаштырабыз.* Ютазы таңы. *Бу күләмдәге су белән промышленность **предприятияләреннән** тыш миллионлы Казан шәһәрен су белән тәэмин итәргә җитәр иде (тәүлегенә бер кешегә 43 литр су туры килә икән).* Биектау хәбәрләре. *Фабрика каршында мәктәп, клуб, көнкүреш хезмәте күрсәтү **предприятиясе** эшләп килә.* Гасырлар авазы.

Алынма сүзләрне төрләндергәндә татар теле кушымчалары сүзнең төп формасына, ягъни берлек сан, баш килештәге формасына ялгана. Бу очракта һәм шул типтагы башка сүзләрдә ***-е*** кушымчасы урынына ***-я*** язу аларның русчадагы күплек сан формасына ияреп язудан килеп чыккан ялгыш; *дөр.:* **предприятие**.

**ПРЕДСЕДА́ТЕЛЬ** *и*. Председательгә, председателе, председателенә, председательләр; *ялг.:* **председательга, председателена, председательлар**. *Төнлә генә түгел, көне буена да үзләрен йокламаган **председательга** карап утырырга мәҗбүр булды алар.* Р. Мөхәммәдиев. *Ашык-пошык суктырганнан соң җирдә калган бөртекләрне соңыннан мүк сыман куе уҗым булып шытып чыгуында исәпкә алсаң **председательның** ярты сүзенә су кушканлыгы бала-чагага да аңлашыла.* Ф. Дәүләтбаев; *к.* **апрель**.

**ПРЕМЬЕ́Р** *и*. Премьерга, премьеры, премьерына, премьерлар; *ялг.:* **премьергә, премьеренә, премьерләр**. *Әлеге мәхкәмә эше 25 май көнне **премьергә** каршы багышланган урам җыеннары вакытында ачылган иде.* «Азатлык радиосы» сайты; *к.* **лагерь**.

**ПРИВАТ-БҮЛМӘ́** *и. ялг. Монда **«приват-бүлмә»** дигән урыннар бар.* Безнең гәҗит; *дөр.:* **приват бүлмә**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ПРИВАТ-ТЕРКӘЛҮ́** *и. ялг. Ниһаять, 2014 елның сентябрендә «tatar» доменында **приват-теркәлү** башлау турында игълан ителде.* Википедия; *дөр.:* **приват теркәлү**; *к.* **онлайн-сервис**.

**ПРИ́НЦИПЧЫЛЫК** *и. ялг.; дөр.:* **принциплылык, принципларына тугры калу, принциплардан чыкмау, принципта тору, принципка бару, принципларга туры килү** һ.б.ш.; *к.* **каллиграфчы**.

**ПРИ́СТАНЬ** *и*. Пристаньга, пристане, пристанена, пристаньнар; *ялг.:* **пристаньгә, пристаненә, пристаньнәр**. *Шофер машинаны оста йөртә икән, юл начар дип тормадылар, **пристаньгә***

*килеп тә җиттеләр*. З. Мурсиев. *Аларны Дүртөйле халкы 5 майның кояшлы иртәсендә* ***пристаньдә*** *озатып кала*. Кызыл таң. *Барып җиткәч, Тәтешнең* ***пристаньгә*** *төшә торган баскычларын күреп, хәйран калдым*. Безнең гәҗит.

Рус теленнән һәм рус теле аркылы кергән алынмаларның ***-нь*** га беткәннәре төрләнгәндә тартым кушымчаларының алгы рәт вариантын ала: *пристане*. Калган кушымчаларның арткы рәт варианты ялгана: *пристанена, пристаньга*. ***-нь*** га тәмамланган ай исемнәре татар теленә күптәннән кергәнгә күрә, алар өлешчә үзләштерелгән һәм бу закончалыктан чыгарма булып тора: *июньгә, июненә, июне*; *к. ш. ук* **повесть**.

**ПРОБЛЕ́М** *и. ялг. Мин сезгә үземнең* ***проблем*** *турында язам*. Кәеф ничек? *83 процент тәртип саклау оешмаларындагы канунсызлыкны һәм башбаштаклыкны зур* ***проблем*** *дип таныды*. Матбугат.ру; *дөр.:* **проблема**; *к.* **игуан**.

**ПРОВИНЦИА́Л** *и*. Провинциядә яшәүче кеше; провинциядә яшәүчеләргә хас гадәтләре, сыйфатлары булган кеше, тар карашлы кеше; *ялг.:* **провинциал шәһәр, провинциал карашлар**. *Бу ачыш мине бер дә пошаманга төшермәде, чөнки мин «Энҗекәй»гә кергән яшь кешенең, күбрәк* ***провинциал*** *кешенең, гаҗәпләнгән, югалып калган һәм шул ук вакытта сокланулы карашы минем хезмәтем өчен бүләк булыр*. Р. Мирхәйдәров. *Димәк, бүгенге шартларда кешеләр үзләрен-үзләре провинциал ясый, үз-үзеңә бикләнүдән* ***провинциал*** *аң туа да инде*. Идел. *Германиянең төньягындагы бик матур* ***провинциал*** *шәһәр Людвигслуст мине үзенең архитектура матурлыгы белән әсир итте*. Идел таңнары; *чаг.:* **провинциаль**; *к.* **вокаль**.

**ПРОВИНЦИА́ЛЬ** *с*. Провинциядә яши, тора, эшли торган; беркатлы, хәйләсез; *чаг.:* **провинциал**; *к.* **вокаль**.

**ПРОВОКА́ЦИЯЛӘҮ** *ф. ялг. Моны мине* ***провокацияләү*** *өчен утырткannar булса кирәк дип шикләнде*. В. Нуруллин. *Бала тискәреләнә, зур игътибар таләп итә,* ***провокацияли****, үзе теләгәнне эшләтә*. Әлмәт таңнары. *Бүтән кешеләрне мәгънәсез әңгәмәгә җәлеп итү өчен, тролль төрттерә,* ***провокацияли****, сарказмлы шелтәләр ясый*. Ялкын; *дөр.:* **провокация ясау, провокациягә бару, котырту, өстерү** һ.б.ш.; *к.* **стимуллаштыру**.

**ПРОГРА́ММАЛАШТЫРУ** *ф. ялг*. Компьютерда, математик яки логик мәсьәләләрне чишү өчен махсус код ярдәмендә

программа төзү; компьютерларга, автомат станокларга һ.б.га программа бирү; *... Компьютерны эшләтү алымнары – бала-чага уены гына, аның әле тагын төпсез тирән бер фәнни-практик юнәлеше – **программалаштыру** дигән нәрсәсе бар бит...* Зөбәер Мифтахов; *дөр.*: **программалау**; *к.* **стимуллаштыру.**

**ПРОЕ́КТЛАШТЫРУ** *ф. ялг. Мөмкинлекләре чикле балалар гади мәктәпләрдә дә белем ала, әмма аларны төзегәндә лифт, тиешле киңлектәге коридор, бәдрәф бүлмәләре **проектлаштырылмаган**.* Кызыл таң. *Дөреслекне дәлилләү өчен, нормаларга таяну өстенә, дамбаны **проектлаштыру** һәм төзү чорында эшләнгән барлык документларны архивтан табып, аларны җентекләп тикшереп, аңлатмалар язып, төпле материал әзерләү кирәклеге көн тәртибенә килеп баса.* Мәдәни җомга; *дөр.:* **проектлау, проект төзү, проект әзерләү**; *к.* **стимуллаштыру**.

**ПРОМЫ́ШЛЕННОСТЬ** *и.* Промышленностька, промышленносте, промышленностена, промышленностьлар; *ялг.:* **промышленностькә, промышленностенә, промышленностьләр**. *И. Гаспралы моннан тыш җир эшкәртүне яхшырту, сәүдә һәм **промышленностьне** күтәрү өчен фәннәрне үстерүнең кирәклеге мәсьәләсенә дә йөзләрчә мәкалә һәм корреспонденция багышлаган.* Т. Биктимирова. *Инфляциянең көчәюе исә илнең **промышленностенә** сугачак, фонд базарында акцияләрнең тагын да арзанаюына китерәчәк, банк тармагында авырлыклар китереп чыгарачак.* Татарстан яшьләре; *к.* **повесть**.

**ПРО́ПУСКА** *и. ялг. Әйдә, сиңа да **пропуска** яздырып алып чыктым, миңа керәбез.* Казан утлары. *Теләгән кешеләрне **пропуска** белән чыгаргалаганнар*. Безнең мирас; *дөр.:* **пропуск**; *к.* **страза**.

**ПРОТЕЖЕ́** *и.* Протежега, протежесы, протежесына, протежелар; *ялг.:* **протежегә, протежесе, протежесенә, протежеләр**; *к.* **атташе**.

**ПРОТЕСТАНТЧЫЛЫ́К** *и. ялг. – Гарәп илләрендә дә традицион ислам белән **протестантчылык** – сәләфичелек арасында көрәш бара, – дип белдерде ул.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар; *дөр.:* **протестантлык**; *к.* **каллиграфчы**.

**ПРО́ФИЛЬ** *и.* Профильгә, профиле, профиленә, профильләр; *ялг.:* **профильга, профилена, профильлар**. *Ләкин, игътибар белән карасагыз, монда әле **профильда** сурәтләнгән йөзне дә күреп була*. Күрше; *к.* **апрель**.

**ПУ́ДЕЛЬ** *и*. Пудельгә, пуделе, пуделенә, пудельләр; *ялг.:* **пудельга, пуделена, пудельлар**. *Надия ап-ак **пудельны** кочаклады да: «Ярый әле, дус кызларымның планнары үзгәрде», – дип пышылдады*. Р. Мифтахова; *к.* **апрель**.

**ПЫЛА́У** *и.* Пылауга, пылавы, пылавына, пылаулар; *ялг.:* **пылауы, пылауына**. *Чарага игътибарны тупламыйча, безнең өчен әһәмиятле булган эшкә – элекке хәрби әзерлек укытучысы Роберт Хәмитовның көнчыгыш **пылауы** пешерү буенча мастер-классына тукталыйк.* Ютазы таңы. *Токмачлы аш пешерәм, Казан **пылауы**, өчпочмак...* М. Кәбиров; *к.* **билбау**.

**ПЮРЕ́** *и*. Пюрега, пюресы, пюресына, пюрелар; *ялг.:* **пюрегә, пюресе, пюресенә, пюреләр**. *Икенче кулында балалар өчен махсус әзерләнә торган кечкенә савытта җимеш **пюресе** иде.* З. Тимергалиев. *Өстенә майонез, вак итеп туралган укроп, лимон суты (кислотасы да ярый) һәм томат **пюресе** (теләгән кеше коньяк өсти ала) салып, әзерләнгән катнашмага коярга.* Өмет; *к.* **атташе**.

**РАДИО-ДӘРЕ́С** *и. ялг. Мәгълүматлы, тирән эчтәлекле булганга да, туган телебезнең чиксез матурлыгын вә байлыгын күрсәтә алганга да, тел каршында торган хәвефле проблемаларны ачып бирүдән курыкмаганга да бу **радио-дәресләр** дистә еллар инде үзенең рейтингын югары кимәлдә саклап килә.* Н. Гамбәр; *дөр.:* **радиодәрес**; *к.* **фото-альбом**.

**РАДИО-ЖУРНАЛИ́СТ** *и. ялг. Аларда композиторлар Исмай Шәмсетдинов, Фасил Әхмәтов, Наилә Зарипова, шагыйрь һәм үзешчән композитор Ләбиб Айтуганов, тәҗрибәле **радио-журналистлар** Эльза Гобәйдуллина, Нәсимә Әхмәтҗанова, Маһинур Җиһаншина һ.б.лар эшли.* Татар әдипләре; *дөр.:* **радиожурналист**; *к.* **фото-альбом**.

**РАДИО-КОМИТЕ́Т** *и. ялг. Армиядән кайткач, берникадәр вакыт Мәскәүдә татарча чыга торган «Коммунист» газетасында әдәби хезмәткәр, аннары, 1932 елдан башлап, Казанда Татарстан дәүләт нәшриятында редактор һәм Татарстан **радио-комитетында** әдәби хезмәткәр вазифаларын башкара.* Татар әдипләре; *дөр.:* **радиокомитет**; *к.* **фото-альбом**.

**РАДИО-ТАПШЫРУ́** *и. ялг. 1984–1985 елларда, Казан дәүләт университетында укыганда, шигырьләре белән сәхнәләрдә, әдәби **радио-тапшыруда** чыгыш ясый.* Кызыл таң; *дөр.:* **радиотапшыру**; *к.* **фото-альбом**.

**РАЗРЯ́Д** *и*. Разрядка, разряды, разрядына, разрядлар; *ялг.:* **разрятка, разряты, разрятына, разрятлар**. *Минә* ***разрятыңны*** *арттырырга дип тора идем*. А. Алиш; *к*. **гибрид**.

**РАСПИСА́НИЕ** *и*. Расписаниегә, расписаниесе, расписаниесенә; *ялг*.: **расписаниега, расписаниесы, расписаниесына**. ***Расписаниега*** *үзгәрешләр кертү планлаштырылмый*. Татар-информ. ***Расписаниеда*** *яңа Казан – Түбән Новгород электр поезды һәм күчеп утырмый торган Казан – Берлин поезды барлыкка килде.* Татар-информ; *к.* **звание**.

**РАСПИСА́НИЯ** *и. ялг. 1906 елның 10–13 августында ярым яшерен рәвештә үткәрелгән киңәшмәнең көн тәртибенә җәдит мәктәпләрендә уку-укыту өчен җаваплылык, мәктәпләрнең эчке тәртибе һәм дәресләрнең* ***расписанияләре*** *кебек сораулар куелуы бик вакытлы була.* Т. Биктимирова. *Автобусларның* ***расписаниясе*** *шул ук кала, аларны элекечә 3–4 минут аралыгы белән көтәбез.* Алабуга нуры; *дөр.:* **расписание**; *к.* **предприятия**.

**РАУШАНИ́** *с. ялг.:* **раушани көзге, раушани нур**; *дөр.:* **раушан көзгесе, раушан нуры**; *к.* **мәгълүмати**.

**РАФИНА́Д** *и*. Рафинадка, рафинады, рафинадына, рафинадлар; *ялг.:* **рафинатка, рафинаты, рафинатына, рафинатлар**; *к*. **гибрид**.

**РАФИНАТЛАТУ́** *ф. ялг. Яңа завод – «Нәфис-Биопродукт» май орлыгын тирәнтен эшкәртү буенча җитештерү комплексын төзүнең йомгаклау этабы, аңа шулай ук эксплуатациягә тапшырылган майларны* ***рафинатлату*** *заводы һәм шешәләрдә май, майонез һәм соуслар чыгару заводы да кирә.* «Рәсми Татарстан» порталы; *дөр.:* **рафинация, рафинировка, рафинация үткәрү, рафинация ясау, чистарту**; *к.* **стимуллаштыру**; *к. ш. ук* **гибрид**.

**РАЦИОНАЛЛАШТЫРУ́** *ф. ялг. Анда Татарстанның һәр районыннан уйлап табу,* ***рационаллаштыру*** *сәләтенә ия булган балалар катнаша.* Авыл офыклары. *«Татхимфармпрепараты» ААҖдә* ***рационаллаштыру*** *буенча еллык конкурска йомгаклар чыгарылды*. Татар-информ; *дөр.:* **рациональләштерү**.

**РӘССАМЧЫ́** *и. ялг. Танылган* ***рәссамчы*** *буласың килсә – бер адым яса!* Идел. *Ул әсәрләрендә табигатьне, образларны, күренешләрне чын* ***рәссамчы*** *кебек, беркемне дә кабатламыйча сурәтли белә.* Ватаным Татарстан. ***Рәссамчы*** *һөнәрен үзләштергән бу ханым менә инде утыз елдан артык балчыктан төрле әйберләр ясау белән шөгыльләнә.* Матбугат.ру; *дөр.:* **рәссам**; *к.* **каллиграфчы**.

**РӘССАМЧЫЛЫ́К** *и. ялг. Әнә бит, **рәссамчылык** инде канда: кая гына бармасын, этюднигын үзеннән калдырмаган.* Сөембикә. *Язучы-фантаст Адлер Тимергалинның кызы **рәссамчылык** эшен нәкъ менә китап бизәүдән башлаган икән, монда гаҗәпләнерлек әйбер дә юк кебек.* Шәһри Казан; *дөр.:* **рәссамлык**; *к.* **каллиграфчы**.

**РЕАГИРЛА́У** *ф. ялг. Ул кальций гидраты белән **реагирлашып**, водород бүлеп чыгара.* Төзү материаллары. *2-Нитро 2-метилбутан селте белән **реагирлашмый**.* Органик химия.

Татар телендә мондый сүзләрнең ясалыш моделе ***нигез+-лау***, бу очракта – ***реагир+лау***, ләкин татар телендә дә, рус телендә дә ***реагир*** сүзе юк, ***реакция*** алынмасы гына бар, кушымча шуңа кушылырга тиеш. Бу төр хаталарның барлыкка килү сәбәбе түбәндәгедән гыйбарәт. Рус телендә ***реагировать, маркировать, мульчировать*** кебек фигыльләр ясалганда исем суффиксы, кушымчасы төшеп кала, аның урынына фигыль суффиксы һәм кушымчасы ялгана: ***реакция → реаг+ир+ова+ть***. Татар телендә исә фигыль үз җирлегендә, үз чаралары ярдәмендә ясала һәм кушымчалар рус телендәге тулы нигезгә ялгана: ***реакция+ләү***; *дөр.*: **реакциягә керү, реакция күрсәтү, реакция бирү, реакцияләү**.

**РЕАГИРЛАШУ́** *ф. ялг. Майлар – глицеринның һәм югары карбон кислоталарының **реагирлашу** продукты.* Химия. *Беренчел амин, нитрит кислотасы белән **реагирлашып**, беренчел спирт (бирелгән очракта пропил спирты) һәм ирекле азот барлыкка китерә.* Органик химия: Күнегүләр һәм мәсьәләләр. *Ул кальций гидраты белән **реагирлашып**, водород бүлеп чыгара.* Төзү материаллары; *дөр.:* ***реакциягә керү, реакция күрсәтү, реакция бирү, реакцияләү***; *к.* **реагирлау**.

**РЕГЛА́МЕНТЛАШТЫРУ** *ф. ялг. Ләкин соңгы вакытта тагын бөтен нәрсәне үзәккә туплау, һәр эшне **регламентлаштыру** омтылышы өстенлек итә.* Р. Юныс. *Моңарчы әлеге норма берничек тә **регламентлаштырылмаган** иде, хәзер исә ул яңа кагыйдәләрдә урын алды.* Маяк; *дөр.:* **регламентлау, регламент кую, регламент билгеләү, регламентка салу**; *к.* **стимуллаштыру**.

**РЕГУЛИРЛА́У** *ф. ялг. Әмма ул кайбер төрләрнең артык күп үрчүенә китерә, мәсәлән, күк күгәрченнәр һәм каргасыман кошларның саны бүген **регулирлауны** таләп итә.* Фәнни Татарстан; *дөр.:* **регулировка ясау, көйләү**; *к.* **реагирлау**.

**РЕЗЮМЕ́** *и*. Резюмега, резюмесы, резюмесына, резюмелар; *ялг.:* **резюмегә**, **резюмесе**, **резюмесенә**, **резюмеләр**. ***Резюмегә*** *ихтирамлы, игътибарлы җавап – компаниягә өстәмә «плюс» ул.* Татар-информ. *Гариза бирүчегә* ***резюменең*** *структурасы, аны төзү тәртибе һәм эш бирүчеләрнең хезмәткәрләр кандидатураларына таләпләрен исәпкә алырга кирәк*. Татарстан.ру; *к.* **атташе**.

**РЕКЛА́М** *и. ялг. Аларда* ***реклам*** *бәяләре меңнән алып өч меңгә кадәр.* Шәһри Чаллы. *Республикада барлык элмә такталар, урам исемнәре, юл күрсәткечләре,* ***реклам*** *белдерүләре ике телдә язылырга тиеш.* Якты юл; *дөр.:* **реклама**; *к.* **игуан**.

**РЕКО́РД** *и*. Рекордка, рекорды, рекордына, рекордлар; *ялг.:* **рекортка, рекорты, рекортына**. *Без бит бу* ***рекортка****, барлык нечкәлекләрен истә тотып, бер ай алдан әзерләндек, – дип уртаклашты үз хисләре белән* ***рекорт*** *куючы дайвингларның берсе Максим Асхатов.* Шәһри Казан; *к.* **гибрид**.

**РЕЛЕ́** *и*. Релега, релесы, релесына; *ялг.:* **релегә, релесе, релесенә, релеләр**. *Коноваловка эшмәкәре Фларис Шакирҗанов авыл җыенында электр энергиясен экономияләү максатында урамдагы электр фонарьларына вакыт* ***релесе*** *кую тәкъдиме белән чыккан иде.* Минзәлә. *Соңгысын бәрәкәтлерәк тоту өчен яктырткычларның зур өлешен яндыру-сүндерү фотоэлемент яки вакыт* ***релесе*** *белән көйләнә.* Дуслык. *Ә менә* ***релене*** *саклау, автоматика һәм химия хезмәте «Сетевая компания» ААҖгә һәм «Генерирующая компания» ААҖгә күчерелде.* Татарстан Республикасы (Рәсми серверның архивы); *к.* **атташе**.

**РЕНТА́БЕЛЬЛЕ** *с. ялг. Халыкны халыкка санамаганлыкмы, Дәүләт думасының трибунасыннан министр буларак ачыктан-ачык: «Сез –* ***рентабельле*** *халык түгел», – дип әйтә ала*. Татар милләт календаре; *дөр.:* **рентабель**; *к.* **каллиграфчы**.

**РЕФО́РМАЛАШТЫРУ** *ф. ялг. 1991 елдан – идарәнең икътисад һәм авыл хуҗалыгын идарә итүне* ***реформалаштыру*** *бүлеге мөдире.* Г. Мөхәммәтшин. *Соңгы елларда без «Бәләкәч», «Киләчәк» программаларына зур игътибар бирәбез, мәктәпне* ***реформалаштыру*** *бара.* Казан утлары; *дөр.:* **реформалау, реформа ясау, реформа үткәрү**; *к.* **стимуллаштыру**.

**РЕЧЬ** *и*. Речька, рече, речена, речьлар; *ялг.:* **речькә, реченә, речьләр**. ***Речьләр*** *сөйләнде, җырлар җырланды, милли уеннар уйналды.* Шәһри Казан; *к.* **повесть**.

**РИДИКЮ́ЛЬ** *и.* Ридикюльгә, ридикюле, ридикюленә, ридикюльләр; *ялг.:* **ридикюльга, ридикюлена, ридикюльлар**; *к.* **апрель**.

**РИШЕЛЬЕ́** *и.* Ришельега, ришельесы, ришельесына, ришельелар; *ялг.:* **ришельегә, ришельесе, ришельесенә, ришельеләр**; *к.* **атташе**.

**РОЛЛ** *и.* Роллга, роллы, роллына; роллар; *ялг.:* **ролы, ролына, ролллар, роллылар**. *Бүген без **ролыларга** заказ бирергә уйладык.* Туган як. *Суши һәм **роллылар** – искиткеч!* Балтач районы порталы; *к.* **металл**.

**РОЯ́ЛЬ** *и.* Рояльгә, рояле, рояленә, рояльләр; *ялг.:* **рояльга, рояльны, роялена, рояльлар**. *Фестивальнең тагын бер үзенчәлеге: Наталья Ибраһимова, ак **рояльда** биеп, «Пианофрения» хореографик моно-спектакле белән шаккатырачак.* Татар-информ; *к.* **апрель**.

**РУЛЬ** *и.* Рульгә, руле, руленә, рульләр; *ялг.:* **рульга, рулена, рульлар**. – *Үзем утырам **рульга**, – диде ул, бәлешен арткы утыргычка куеп.* Р. Мөхәммәдиев. *Штрафлар системасы үзгәргәч, исерек килеш **рульга** утырсаң, машина йөртү таныклыгыңны гына алып калмаячаклар, бюджет файдасына 30 мең сум күләмендә штраф түләргә дә мәҗбүр итәчәкләр.* Сарман. *Республика юлларында исерек килеш **рульга** утырып барганнар җавапка тартыла тора: узган тәүлектә генә дә 35 шундый юл йөрү кагыйдәләрен бозучы эләккән.* Татар-информ; *к.* **апрель**.

**РУХАНИ́** *с. ялг. Халыкта **рухани** азыкка сусау бик көчәя һәм труппаның бөтен артистларына зур активлык күрсәтеп, нык җигелеп эшләргә туры килә.* Н. Таждарова. *Иҗтимагый тормышның шул дәвердәге **рухани** халәтен сәхнә аша тышка чыгарырга, аның хәрәкәт һәм таләпләрен җанландырып, халык алдына тәкъдим итәргә тырыша.* А. Әхмәдуллин. *Татар әдәбияты йогынтысында үскән бала **рухани** яктан баерак, өметлерәк, милли җанлы булу өстенә акыллырак та булачак, ди Исхакый.* Казан утлары; *дөр.:* **рухи**; *к.* **мәгълүмати**.

**САВЫГУ́** *ф.* Савыга, савыкты; *ялг.:* **сауыга, сауыкты**. *Киләчәге икеле, аяк өстенә бастыралырмы юкмы, **сауыкса** да әлдә билгесез, нинди ир булыр, я чыгар да китәр, мин сине яратмыйм диеп.* В. Ильясов. *Минем кулыма тапшырды, Фәсыйлә астай, **сауыктыр**, зинһар, дип.* Н. Гыйматдинова; *к.* **билбау**.

**САВЫ́М** *и.* Савымга, савымы, савымына, савымнар; *ялг.:* **сауымга, сауымы, сауымына**. ***Сауымы** күп булырга тиеш быел*. Туган як; *к*. **билбау**.

**САВЫ́Р** *и.* Савырга, савыры, савырына, савырлар; *ялг.:* **сауырга, сауыры, сауырына, сауырлар**. *Яшь ярымлы болан төсле атлаганда Ыспай, тигез **сауырлары** дер-дер килер.* К. Тинчурин; *к*. **билбау**.

**САВЫ́Т** *и.* Савытка, савыты, савытына, савытлар; *ялг.:* **сауытка, сауыты, сауытына, сауытлар**. *Кайбер көннәрне **сауыттагы** яза торган каралар да туңалар.* З. Зәйнуллин; *к*. **билбау**.

**САЙ** *с. ялг.:* **саерак**. *[Әсәрләр] Озын языла, мәгънә ягы **саерак**.* Р. Нуруллина; *дөр.:* **сайрак**; *к*. **бай**.

**САЛЯ́МИ** *и.* Салямига, салямие, салямиена, салямилар; *ялг.:* **салямигә, салямиенә, салямиләр**; *к*. **бигуди**.

**САМАВЫ́Р** *и.* Самавырга, самавыры, самавырына, самавырлар; *ялг.:* **самауырга, самауыры, самауырына, самаурлар; самауарга, самауары, самауарына, самауарлар**. *Туйларында мин дә булдым: йөз **самауыр** чәй эчтем, мең чүлмәк кымыз түктем, бик күп хикмәтләр күрдем*. Р. Батулла. *Мәгәр бер әйбер генә булмады – ул да булса капкач астына күкәй тезелгән сары **самауыр**!* Туганайлар. *Илшат Вәлиев **самауардан** чәй эчә.* bulmas.ru; *к*. **билбау**.

**САМОДЕРЖА́ВИЕ** *и*. Самодержавиегә, самодержавиесе, самодержавиесенә; *ялг.:* **самодержавиега, самодержавиесы, самодержавиесына**. *Автобиографик материалга нигезләнеп, төрмә көндәлеге рәвешендә язылган һәм патша **самодержавиесына** карата чиксез күралмау хисләре, аның асылын фашлау рухы белән сугарылган әсәр конкрет тарихи вакыт аралыгын – 1906–1907 елларны эченә ала.* Ф. Сәхаутдинова. *В.Д. Смирнов кандидатурасы **самодержавиеның** реакцион даирәләре өчен иң кулай була*. Гасырлар авазы. *Түмәннәр – XVII–XVIII гасырларда патша **самодержавиесының** христианлаштыру сәясәте аркасында, башлыча Тамбов губернасының Түмән өязеннән һәм Пенза губернасыннан Башкортстан җирләренә күченгән татарлар.* Википедия; *к*. **звание**.

**САМОДЕРЖА́ВИЯ** *и. ялг.* ***Самодержавиянең** дарлары, зинданнары, канлы якшәмбеләре генә баса, сыта алмаган рух барлыгын аңласын халык.* Р. Батулла. *Ләкин Россия **самодержавиясенең** рус булмаган халыкларга карата сәясәте бу хыялларны бер гасыр буена диярлек тоткарлый.* Гасырлар авазы. *Хөкүмәт органнары **самодержавиягә** каршы ачыктан-ачык сул лозунглар белән чыккан*

*«Таң йолдызы» газетасын һәм шул вакытта аның җаваплы редакторы Сәгыйть Рәмиевне эзәрлекли башлыйлар, соңыннан кулга да алалар.* Татар-информ; *дөр.:* **самодержавие**; *к.* **предприятия**.

**САҢА́КАЯКЛЫЛАР** *и. күпл. зоол. ялг.* Кысласыманнарның бер классы; *дөр.:* **саңагаяклылар**; *к.* **ишекалды**.

**САРГЫ́ЛТ-АК** *с. ялг.* ***Саргылт-ак****, җылы сөт җебе, уйнаклыйуйнаклый, калай бидрә кырыена «зең-зең... чыз-чыз...» кагылып, бидрә төбендәге парлы, күбекле сөт күләмен күз алдында үстерә бара.* Ф. Дәүләтгәрәева; *дөр.:* **саргылт ак**; *к.* **кызгылт-сары**.

**САРГЫ́ЛТ-АЛСУ** *с. ялг. Бу ашханә һәрвакыт пөхтәләп* ***саргылт-алсу*** *төскә буялган, текә түбәсе ачык яшелдән булыр иде.* Р. Мирхәйдәров; *дөр.:* **саргылт алсу**; *к.* **кызгылт-сары**.

**САРГЫ́ЛТ-ҖИРӘН** *с. ялг. Кызчыкның койрыкларга җыелган* ***саргылт-җирән*** *чәче, дөрестән дә, тузып киткән...* С. Гаффарова; *дөр.:* **саргылт җирән**; *к.* **кызгылт-сары**.

**САРГЫ́ЛТ-ЗӘҢГӘР** *с. ялг.* ***Саргылт-зәңгәр*** *телләрен ялт-йолт уйнатып, дәрт белән янган учак яктысында идәнгә җәйгән йомшак тиреләр өстенә кырын ятып сөяк кимергәндә, хуҗалар телендә «огненная вода», «огненная вода» дигән сүзләр дә ишетелеп киткәләде.* А. Хәсәнов; *дөр.:* **саргылт зәңгәр**; *к.* **кызгылт-сары**.

**САРГЫ́ЛТ-КАРА** *с. ялг. Сугышчы башын күтәрде, аның* ***саргылт-кара*** *йөзе яктырып китте.* Г. Әпсәләмов; *дөр.:* **саргылт кара**; *к.* **кызгылт-сары**.

**САРГЫ́ЛТ-КОҢГЫРТ** *с. ялг. Калган табакларга күз йөртеп чыкканда иң котын алганы шул булды: табынның кыл уртасында* ***саргылт-коңгырт*** *төскә кертелгән, менә-менә сикереп төшеп китәрдәй булып, чабышка әзерләнгән йөгерүчене хәтерләтеп чучка баласы ята.* К. Тимбикова; *дөр.:* **саргылт коңгырт**; *к.* **кызгылт-сары**.

**САРГЫ́ЛТ-КӨРӘН** *с. ялг. Учакка бу ошамады, ахры, ул төн йөзенә* ***саргылт-көрән*** *төстәге төтен болыты атты...* Г. Гыйльманов. *Нарат ябалдашларына ап-ак кар кунган,* ***саргылт-көрән*** *кәүсәләре уклау кебек төз үзләре.* Р. Кәрами; *дөр.:* **саргылт көрән**; *к.* **кызгылт-сары**.

**САРГЫ́ЛТ-КҮК** *с. ялг.* ***Саргылт-күк*** *төсендәге тунын да алыштырып өлгермәгән үзе.* Матбугат.ру; *дөр.:* **саргылт күк**; *к.* **кызгылт-сары**.

**САРГЫ́ЛТ-КЫЗЫЛ** *с. ялг. Безнең аңда кызулык – якты кояш,* ***саргылт-кызыл*** *ут белән, салкынлык исә – аксыл-зәңгәр боз белән бәйләнгән.* Ф. Хатипов; *дөр.:* **саргылт кызыл**; *к.* **кызгылт-сары**.

**САРГЫ́ЛТ-СОРЫ** *с. ялг. Хәзер инде алсу шәфәкъ нурлары бөтен офыкка таралып өлгергән, тузанлы тар юл да, Бохараның* ***саргылт-соры*** *ныгытма диварлары да җайдакка бик яхшы күренә иде.* Т. Әйди; *дөр.:* **саргылт соры**; *к.* **кызгылт-сары**.

**САРГЫ́ЛТ-ШӘМӘХӘ** *с. ялг. Тәбәнәк баганачыклардагы куыклы лампалар кабынып, койма буендагы зәңгәр чыршылар* ***саргылт-шәмәхә*** *төскә буялды.* Н. Гыйматдинова; *дөр.:* **саргылт шәмәхә**; *к.* **кызгылт-сары**.

**САРГЫ́ЛТ-ЯШЕЛ** *с. ялг. [Яран гөле] Нечкә генә* ***саргылт-яшел*** *тармак та җибәргән.* Н. Кәримова. *Әнә күк чите* ***саргылт-яшел*** *булып яктыра башлады, аннан соң алсуланып таң атты.* Р. Хәбибуллина; *дөр.:* **саргылт яшел**; *к.* **кызгылт-сары**.

**САУНД-ДИЗА́ЙН** *и. ялг. Студиянең вокал, инструменталь, электрон музыка, мастеринг,* ***саунд-дизайн*** *яздыру мөмкинлекләре бар, дип хәбәр итә ТР Театр әһелләре берлеге матбугат хезмәте.* Татар-информ; *дөр.:* **саунд дизайн**; *к.* **онлайн-сервис**.

**САУНД-ДИЗА́ЙНЕР** *и. ялг. Хәзер ул танылган режиссер командасында* ***саунд-дизайнер*** *булып эшли.* Татар-информ; *дөр.:* **саунд дизайнер**; *к.* **онлайн-сервис**.

**САУНД-ПРОДЮ́СЕР** *и. ялг. «Зиннур» проектының* ***саунд-продюсеры*** *мин.* Акчарлак. *Монысында инде ул башкаручы гына түгел, җыр авторы һәм* ***саунд-продюсер*** *буларак та танылу ала.* Матбугат.ру; *дөр.:* **саунд продюсер**; *к.* **онлайн-сервис**.

**САУНД-ПРОДЮ́СЕРЛЫК** *и. ялг.* ***Саунд-продюсерлык*** *голланд музыканты Михиль Холландерз белән эшләнәчәк.* Татар-информ; *дөр.:* **саунд продюсерлык**; *к.* **онлайн-сервис**.

**САУНД-ТРЕ́К** *и. ялг. Дженни Мэнниның билгеле кинофильмга язылган «Тень твоей улыбки»* ***саунд-трегы,*** *Арам Хачатурянның Лермонтовның «Маскарад» драмасына вальсы, Иоганн Себастьян Бахның оркестр белән виолончель өчен концерты һәм башка популяр симфоник әсәрләр яңгырады.* Кама ягы; *дөр.:* **саундтрек**.

Бу сүз чыгарма булып тора; *к.* **онлайн-сервис**.

**САШЕ́** *и.* Сашега, сашесы, сашесына, сашелар; *ялг.:* **сашегә, сашесе, сашесенә, сашеләр**; *к.* **атташе**.

**СӘБӘПЧЕЛЕ́К** *и. ялг. Татарда яхшылык яки яманлык гамәлнең **сәбәпчелек** канунына буйсынуына, аның хәерле яки яман нәтиҗәсе, әлбәттә, шуны эшләүчегә әйләнеп кайтачагына ниндидер язмыш кануны кебек итеп ышану бар.* Казан утлары. *Моңа аларның тәҗрибәләре, яңалыклары **сәбәпчелек** итә.* Авыл офыклары; *дөр.:* **сәбәп, сәбәплелек**, **сәбәп булып тору**; **сәбәп булу, сәбәпләр аркасында барлыкка килү** һ.б.ш; *к*. **каллиграфчы**.

**СӘДАКА́** *и. ялг.* Сәдакага, сәдакасы, сәдакасына. *Ә хәзергә минә хәер – **сәдака** булыр...* А. Гадел. *Бер елмаю да **сәдака** диләр.* Идел таңнары; *дөр.*: **садакага, садакасы, садакасына**.

**СӘЛӘТЛЕ́К** *и. ялг. Шул очракта гына көндәшлеккә **сәләтлек** сакланачак*. Кызыл таң. *Әңгәмә барышында яклар энергия чыгымнары, көндәшлеккә **сәләтлек** һәм технологияләрнең энергия нәтиҗәлелеге турында фикер алышты*. Ватаным Татарстан; *дөр.:* **сәләт**, **сәләтлелек**; *к*. **катлаулык**.

**СӘНГАТИ́** *с. ялг. Кешелекнең уртак **сәнгати** әсәрләрен киләчәккә илтү юлында җәмгыятьнең һәр тармагын, шул исәптән иҗтимагый оешмаларны да җәлеп итеп, фән эшлеклеләре, белгечләр белән эш итү зарурлыгын аңларга кирәк.* Татар әдипләре; *дөр.:* **сәнгать...-ы/-е, сәнгатьчә, сәнгатькә караган, сәнгать күзлегеннән, сәнгать ягыннан**; *к*. **мәгълүмати**.

**СӘҮДӘГӘРЧЕЛЕ́К** *и. ялг. Нәзирнекеләр һәм Габбасовлар Октябрь инкыйлабына кадәр **сәүдәгәрчелек** белән шөгыльләнгәннәр.* Р. Зарипов. *Авторларның фикере буенча, бу чаралар мөселманнар арасында **сәүдәгәрчелекне**, промышленностьне, игенчелекне үстерүдә ярдәм итәргә тиеш булып чыга.* Казан утлары; *дөр.:* **сәүдә, сәүдәгәрлек**; *к*. **каллиграфчы**.

**СӘҮДӘЧЕЛЕ́К** *и. ялг. **Сәүдәчелекнең**, эшмәкәрлекнең киң колач алуы мәгърифәтнең көчен, кадерен белүче байлар катламын күтәргән.* Казан утлары. ***Сәүдәчелектә** каршылыкларны юкка чыгару – мөһим бурыч булып тора.* Татар-информ; *дөр.:* **сәүдә, сәүдәгәрлек**; *к*. **каллиграфчы**.

**СЕКУ́НД** *и*. Секундка, секунды, секундына, секундлар; *ялг.:* **секунтка, секунты, секунтына, секунтлар**. *Озын **секунтлар** узды, хәсрәтле Фатыймага бу мизгелләр бер гомердәй озак тоелды.* Л.-Х. Таналин. *Шунысын да билгеләп китми булмый, Родион автомат сүтеп-җыюда 2 нче мәктәптән Илшат Хаҗетдиновны*

*3 **секунтка** узып, җиңү яулады.* Алга. *Америка галимнәре ачыклаганча, яраткан кешең белән кимендә 30 **секунт** кочаклашып тору организмда стресс гормоннарын киметә һәм кан басымын төшерә.* Шәһри Казан; *к.* **гибрид**.

**СЕНТЯ́БРЬ** *и.* Сентябрьдә, сентябре, сентябрендә, сентябрьләр; *ялг.:* **сентябрьда, сентябренда, сентябрьлар**. *1492 елдан башлап чиркәү кануннары нигезендә христианнар Яңа елны 1 **сентябрьда** бәйрәм итә башлый, ә башка дин тотучылар исә моңа буйсынмый.* Кызыл таң. ***Сентябрьның** 22 сендә Казанда Башкортстан мәдәният көннәре башланып китте.* Татар заманы. *Бүген **сентябрьның** 3 е булуга карамастан, Белем көне дәвам иттерелә, дип искәртте.* Татар-информ; *к.* **январь**.

**СИ́НТЕЗЛАШТЫРУ** *ф. ялг. Алар ферментлар барлыкка килү процессында катнаша, витаминнарны **синтезлаштыра**, аксым һәм минераллар алмашы күрсәткечен яхшырта.* Сабантуй. *Кызганычка, хәзер канны ясалма **синтезлаштырып** булмый, еш кына авыруның гомере донорга бәйле.* Шәһри Казан; *дөр.:* **синтезлау**; *к.* **стимуллаштыру**.

**СИРӘ́К** *с. ялг.:* **сирәгерәк**. *Кайда безнең кебекләр **сирәгерәк** икән?* Л. Шакирҗанова. *Колхозлар ызандаш булса да, хезмәттәшем белән **сирәгерәк** очрашылды.* Татар әдипләре; *дөр.:* **сирәгрәк**; *к.* **бай**.

**СИСТЕ́М** *и. ялг. – Хәзерге вакытта **систем** челтәрнең 20% тәрҗемә ителүен күрсәтә, – ди ул*. Казан утлары. *Бу **систем** тәрҗемәсе татар телендә инде кулланылышта бар, теләгән кешеләр куллана ала икән.* Мәйдан; *дөр.:* **система**; *к.* **игуан**.

**СКАНВО́РД** *и.* Сканвордка, сканворды, сканвордына, сканвордлар; *ялг.:* **сканвортка, сканворты, сканвортына, сканвортлар**; *к.:* **гибрид**.

**СКИФ** *и.* Скифка, скифы, скифына, скифлар; *ялг.:* **скифкә, скифе, скифенә, скифләр**. *--- хәзерге Алабуга төбәгендә борынгы **скифләр** шәһәре Гелон ---.* М. Хәбибуллин. *Күргәзмә бигрәк тә без татарлар өчен кадерле, чөнки анда төрледән-төрле экспонатлар аша **скифләр**, сарматлар, һуннар, кыпчаклар һ.б. халыкларның мәдәниятләре күрсәтелә*. Мәдәни җомга.

Алынма сүзләрдә, тамырдагы сузык алгы рәт авазы булса да, әйтелеше чыганак телдәгечә кала. Мәсәлән, татарчадагы *кит* (фигыль) белән алынма *кит* (диңгез хайваны) сүзләренең әйтелеше

төрле. Шуңа күрә кушымчаның да арткы рәт варианты кушыла; *к. ш. ук* **фин, кит, тир**.

**СКЛАД** *и.* Складка, склады, складына, складлар; *ялг.:* **склатка, склаты, склатына, склатлар**; *Колхоз* ***склатында*** *аркан бетмәгән.* Д. Салихов; *к.* **гибрид**.

**СЛА́НЦЫ** *и.* Сланцыга, сланцые, сланцыена, сланцылар; *ялг.:* **сланц, сланцы, сланцына, сланцлар; сланцысы, сланцысына; сланца, сланцасы, сланцалар**. *Өстенә караңгы төстәге куртка, соры ромблар төшерелгән караңгы төстәге кофта кигән, кечкенә козырёклы кепкадан (кепкасы булмаска да мөмкин), спорт трикосының балагы кара төстәге носки эченә кертелгән, аягында кара төстәге* ***сланцлар****.* Хезмәт даны. *Өстенә ак һәм кызыл төстәге материяне кушып тегелгән куе зәңгәр шорты кигән булган, гәүдәсе янында ярда ян-якта кара сызыклы ак футболка, металл прәшкәле кара төстәге бер сыңар* ***сланца*** *табылган.* Татар-информ; *к.* **шорты**.

**СМУ́ЗИ** *и.* Смузига, смузие, смузиена, смузилар; *ялг.:* **смузигә, смузиенә, смузиләр**; *к.* **бигуди**.

**СНАРЯ́Д** *и.* Снарядка, снаряды, снарядына, снарядлар; *ялг.:* **снарятка, снаряты, снарятына, снарятлар**. ***Снарятлар*** *яңгыры туктаганчы шул тәгәрмәчне башка кимәкче булып маташтым.* И. Кашфразыев; *к.* **гибрид**.

**СНОУБО́РД** *и.* Сноубордка, сноуборды, сноубордына, сноубордлар; *ялг.:* **сноубортка, сноуборты, сноубортына, сноубортлар**; *к.* **гибрид**.

**СОРА́У** *и.* Сораугa, соравы, соравына, сораулар; *ялг.:* **сорауы, сорауына**. *Шуңа күрә Шамилнең* ***сорауы*** *урынлы, әдәпсез түгел.* Безнең гәҗит. *Ахирәттә мәхшәр мәйданында Аллаһы Тәгаләнең беренче* ***сорауы****: «Үзең өчен намаз укыдыңмы, Минем өчен ураза тоттыңмы?» – булыр икән.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар; *к.* **билбау**.

**СОРГЫ́ЛТ-АК** *с. ялг. Авыру серкә ак яисә* ***соргылт-ак*** *лайла белән каплана.* Саба таңнары. *Тикшерү барышында ул кешенең тышкы өс киеменең ян кесәсеннән фольгага төрелгән* ***соргылт-ак*** *төстәге порошоксыман матдә табып алынган.* Татар-информ; *дөр.:* **соргылт ак**; *к.* **кызгылт-сары**.

**СОРГЫ́ЛТ-ҖИРӘН** *с. ялг. Йон капламы* ***соргылт-җирән*** *төстә, аркасында буй-буй биш кара-көрән сызык бар.* Википедия; *дөр.:* **соргылт җирән**; *к.* **кызгылт-сары**.

**СОРГЫ́ЛТ-ЗӘҢГӘР** *с. ялг. Тач шул үзе: ул* ***соргылт-зәңгәр*** *күзләре дисеңме, эре-эре сипкелләреме, саргылт-җирән чәчләреме, елмаеп торуымы.* Н. Көбәш; *дөр.:* **соргылт зәңгәр**; *к.* **кызгылт-сары**.

**СОРГЫ́ЛТ-КАРА** *с. ялг. Чөнки әле кичә кичен генә,* ***соргылт-карага*** *буялган дөньяны ап-ак итеп, кар явып киткән иде.* В. Нуруллин. *Хәйретдин Мортазаның шундый хәлдә булуына, аңардагы шундый зур үзгәрешкә гаҗәпсенергә яки куанырга да өлгермәде, горизонтта дошманның, җир төсле,* ***соргылт-кара*** *танклары күренделәр.* М. Яһудин; *дөр.:* **соргылт кара**; *к.* **кызгылт-сары**.

**СОРГЫ́ЛТ-КОҢГЫРТ** *с. ялг. Аның чәчләре* ***соргылт-коңгырт,*** *калын, дулкыннары эре.* М. Хуҗин; *дөр.:* **соргылт коңгырт**; *к.* **кызгылт-сары**.

**СОРГЫ́ЛТ-КӨРӘН** *с. ялг. Хатынның* ***соргылт-көрән*** *күзләреннән генә түгел, әле яшьлек матурлыгын югалтмаган аксыл йөзеннән дә, хәтта бөтен гәүдәсеннән дә бу минутта шатлык нуры сирпелә иде.* Р. Габделхакова; *дөр.:* **соргылт көрән**; *к.* **кызгылт-сары**.

**СОРГЫ́ЛТ-КҮК** *с. ялг. Әгәр бит тирегез аксыл я шәфталу төсендә, чәчегез алтынсу, алтынсу-көлсу, саргылт-көрән; күзегез зәңгәр,* ***соргылт-күк****, көрән, гәрәбә төсендә икән, димәк, сез Гүзәл Уразова, Ландыш Нигъмәтҗанова, Зөһрә Шәрифуллина кебек.* Матбугат.ру; *дөр.:* **соргылт күк**; *к.* **кызгылт-сары**.

**СОРГЫ́ЛТ-КЫЗЫЛ** *с. ялг. Мәсәлән* ***соргылт-кызыл*** *төс бирә торган кушылмаларны кушып сулар да эшлиләр, лимонадлар да, колбасага да, сосискаларга да кушалар.* Матбугат.ру; *дөр.:* **соргылт кызыл**; *к.* **кызгылт-сары**.

**СОРГЫ́ЛТ-САРЫ** *с. ялг. Шикәр кебек ап-ак кофта, шул кофтаның челтәрле нәфис якасыннан калкып чыккан мәрмәр муен, озынча алсу йөз, кояш нурында көнбагыш чәчәгедәй чагылган* ***соргылт-сары*** *каш-керфекләр, иңнәренә таралып төшкән алтын чәчләр...* Р. Габделхакова; *дөр.:* **соргылт сары**; *к.* **кызгылт-сары**.

**СОРГЫ́ЛТ-ЯШЕЛ** *с. ялг. Юк, аның* ***соргылт-яшел*** *күзләре мәченекедәй майланмаган иде.* Т. Нурмөхәммәтов. ***Соргылт-яшел*** *төстә икәнен генә абайлап калдым.* Татарстан яшьләре; *дөр.:* **соргылт яшел**; *к.* **кызгылт-сары**.

**СОСЛО́ВИЕ** *и.* Сословиегә, сословиесе, сословиесенә; *ялг.:* **сословиега, сословиесы, сословиесына**. *Хәер, «башкорт», «башкирец», «башкира»ның күпчелек очракта милләтне түгел, ә* ***сосло-***

***виены*** *күрсәтә торган билге икәненә әле иркенләбрәк тукталырбыз.* И. Шиһапов. *«Башкорт»* ***сословиесында*** *торсаң син димәк көчләп чукындырылмыйсың, налогны да күмәкләп җәмгыять белән түлисең, иң мөһиме – җир хуҗасы булып китәсең дигән сүз.* И. Хуҗин. *Һәрбер халыкның үз* ***сословиесы****, мәсәлән, татарларда ясаклылар һәм йомышлылар төркемнәре булган.* «Азатлык радиосы» сайты; *к.* **звание**.

**СОСЛО́ВИЯ** *и. ялг. Мәскәүдә урамга чыгучылар да урта* ***сословия*** *катламы*. Татар заманы. *Элекке вакытта типтәр* ***сословиясенә****, татарлардан тыш, чирмешләр, удмуртлар, мордва, чуашлар да кергән.* Википедия. ***Сословияләр*** *арасындагы өстенлекләр, чикләнгәнлекләр бетерелә.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар; *дөр.:* **сословие**; *к.* **предприятия**.

**СОЦИАЛ-ИКЪТИСАДИ́** *с. ялг. Аларны Арча муниципаль район башлыгы Илшат Нуриев кабул итте, сорауларына җавап бирде, районның* ***социал-икътисади*** *хәле турында сөйләде*. Безнең мирас. *Рейтинг исә авылга кертелгән инвестицияләр, авыл халкының эш белән тәэмин ителеше, шушындый гаилә фермалары санына һәм башка шундый* ***социал-икътисади*** *күрсәткечләргә карап төзелә*. Туган як; *дөр.:* **социаль-икътисади**; *к.* **либераль-икътисад**; *к. ш. ук* **вокаль**.

**СОЦИАЛ-КӨ́НКҮРЕШ** *с. ялг. 2013 елда авыл җирлегендә урнашкан торак пунктларның* ***социал-көнкүреш*** *хәле сизелерлек яхшырган.* Татар-информ; *дөр.:* **социаль һәм көнкүреш ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**СОЦИАЛЛАШУ́** *ф.* Социалистка әйләнү; социалистлар юнәлешенә якынлашу; *ялг.:* **җәмгыятьтә социаллаштырга тырышу**; *чаг.:* **социальләшү**.

**СОЦИАЛ-СЫЙНФЫ́Й** *с. ялг. Татар милли-азатлык хәрәкәте үзенең* ***социал-сыйнфый*** *юнәлеше белән бер төрле генә булмый.* С. Максуди; *дөр.:* **социаль-сыйнфый**; *к.* **либераль-икътисад**; *к. ш. ук* **вокаль**.

**СОЦИАЛЬЛӘШҮ́** *ф.* Җәмгыятьтә яшәргә өйрәнү, тормышка яраклашу; *ялг.:* **сәяси партия социальләшү**; *чаг.:* **социаллашу**.

**СОЦИАЛ-ЭКОНО́МИК** *с. ялг. Икенчедән,* ***социал-экономик*** *шартлар мондый интеллигенциянең эшен гаять кыенлаштыра.* Габдулла Тукайга багышланган Интернет-портал; *дөр.:* **социаль-экономик**; *к.* **либераль-икътисад**; *к. ш. ук* **вокаль**.

**СОЧИНЕ́НИЕ** *и*. Сочинениегә, сочинениесе, сочинениесенә; *ялг.:* **сочинениега, сочинениесы, сочинениесына**. *Һәр елны, язгы сынаулар алдыннан унынчы сыйныфларга укысыннар бу* ***сочинениены***... З. Зәйнуллин. *Мәктәптә укыган елларым күптән артта калган, ә яратып яза торган* ***сочинениелар*** *шөгыле сагындырды.* Р. Гаязетдин. *Киләсе уку елыннан мәктәпләрдә Бердәм дәүләт имтиханы урынына йомгаклау* ***сочинениесы*** *кирәргә мөмкин.* Сарман; *к.* **звание**.

**СОЧИНЕ́НИЯ** *и. ялг. Сайт үзендә бик күп татарча* ***сочинениялар*** *һәм иншалар туплаган.* Инша.ру. *Ә башка бер мәктәптә укучы берәр кыз, шул ук* ***сочинениясын*** *10 минутта язып, физикадан мисалны чишә алмыйча тилмерә.* Балтач районы порталы; *дөр.:* **сочинение**; *к.* **предприятия**.

**СӨЙЛӘМИЯ́Т** *и. ялг. Вузда телләр өйрәтү өлкәсендә яшәп килгән гомуми кимчелекләр – аны «ботарлап» өйрәтү,* ***сөйләмияткә*** *игътибар җитмәү, система төгәлсезлеге һ.б.* Р. Мөхиярова; *дөр.:* **сөйләм, сөйләмә стиль, сөйләм теле, гади сөйләм** һ.б.; *к.* **каллиграфчы**.

**СӨЯ́КАРА** *с. ялг.* Сөякләр арасында була торган; ике сөяк арасында кала торган; *дөр.:* **сөягара**; *к.* **ишекалды**.

**СТЕ́РЖЕНЬ** *и.* Стерженьга, стержене, стерженена, стерженьнар; *ялг.:* **стерженьгә, стерженենә, стерженьнәр**. *Монысына бик ышанасы килсә дә, шунсы шиккә сала: ай-һай, кибетләр шыр ялангач, кием-салым, кер порошогы, ручка* ***стерженьнәре*** *генә дә табам димә.* Д. Булатова. *«Басмасалар, 17 тиенлек* ***стерженең*** *әрәм булыр, аның каравы, буш вакытың калмас», – ди әдип.* Мәдәни җомга; *к.* **пристань**.

**СТИЛЬ** *и.* Стильгә, стиле, стиленә, стильләр; *ялг.:* **стильга, стилена, стильлар**. *Ал тасма киселгән, тантанада катнашучылар заманча* ***стильда*** *җиһазланган зур бина эченә үттеләр.* Авыл таңнары. *Иҗатында ул классик, традицион әдәби* ***стильны*** *саклый.* Википедия. *Бу* ***стильда*** *киенүче кызлар яки егетләр үз-үзләрен берничдән дә чикләмиләр һәм шуны әйтәсе килә, гламур стиле белән яшәүче яшүсмерләр безнең мәктәбебездә элегә юк.* Гимназия хәбәрләре; *к.* **апрель**.

**СТИ́МУЛЛАШТЫРУ** *ф. ялг. Баш миен электр белән* ***стимуллаштыру*** *ысулын хайваннарны өйрәткәндә актив куллана башлыйлар.* Б. Хаков. *Монда төп бурыч: укучы шәхесе үсешен – белем*

*бирүнең мәгънәсен һәм максатын, ә укучыларның активлыгын* ***стимуллаштыру***. Яңарыш. *Ә яңа системаның* ***стимуллаштыру*** *фонды бик кечкенә*. Кәеф ничек?

Алынма фигыльләрдә ***-лаш-*** форманты нигездә күрсәтелгән нәрсәгә тулысынча әверелү, шундый үзлек алуны белдерә. Мәс., **кристаллаштыру**, **абсолютлаштыру, абстрактлаштыру, абсурдлаштыру, авырлаштыру** һ.б.ш. Башка контекстларда бу аффиксны куллану дөрес түгел (*к.* Татар грамматикасы, Т. I, 2015: 324–328 б.). Еш кына ***-ла-*** аффиксы белән бутау күзәтелә, әмма аның мәгънәсе күпкә төрлерәк һәм нигездә күрсәтелгән эш-хәрәкәт башкару, берәр нәрсәгә билгеле тәэсир ясау һ.б.ш. (*к.* Татар грамматикасы, Т. I, 2015: 313–318 б.) мәгънәләрен белдерә. Кайбер нигезләрдән мондый фигыль формалары ясау гомумән дөрес түгел. Андый очракларда фигыльләр татар телендә киң кулланылган ***итү, ясау, салу, үткәрү, кую, эшләү, булу*** кебек күпсанлы ярдәмче фигыльләр белән ясала; *дөр.:* **стимуллау, стимул бирү, стимул булып тору**.

**СТИХИ́ЯЧЕЛЕК** *и. ялг. Шул ук вакытта автор большевистик аңлылык белән* ***стихиячелек*** *революцион дисциплина белән башбаштаклык, ачык бер максаты булган пролетариатның оешканлыгы белән бунтарьлык ирege арасында да көрәш баруын яктырта.* М. Маннурова. *Мәгариф министрлыгы татар мәктәпләрендә рус телендә укытыла торган параллель класслар төзүдәге башбаштаклыкны,* ***стихиячелекне*** *бетерү ягында.* Казан утлары; *дөр.:* **стихия ...-ы/-е, стихияле, стихиялелек**; *к.* **каллиграфчы**.

**СТРА́ЗА** *и. ялг. --- барлыгы 50 ләп битлек (бит өлеше күн, аннары латекс катламы һәм грим салынган,* ***стразалар****, каурыйлар белән бизәлгән) кулдан эшләнгән һәм киемнәре дә һәр артистның үлчәме алып тегелгән, битлекләре дә индивидуаль ясалган.* Татар-информ. *Мисал өчен, королева-ананың бер генә күлмәген бизәү өчен 1 меңнән артык ташлар һәм* ***стразалар*** *китте, ә Испания кунагы күлмәген бизәргә – 47 метр үтә дә юка шифон»*. Татар-информ.

Страз сүзенә ***-а*** кушымчасы рус теленнән кергән башка сүзләргә ияреп ялгыш рәвештә кушылган; *чаг.:* **банк, бланк**; *дөр.:* **страз**.

**СУБСИ́ДИЕ** *и. ялг. Аннары үз-үзеңне тәэмин итү программасы буенча бирелгән* ***субсидиегә*** *йорт куяннарын, савым кәҗәләр үрчетү буенча мини-ферма булдыралар*. Яңарыш.

Рус теленнән кергән ***-ия*** кушымчалы исемнәрне һәм ***-ие*** кушымчалы исемнәр арасында ялган аналогия аркасында килеп

чыккан хата; *дөр.:* **субсидия, субсидиясе, субсидиясенә, субсидияләр**; *чаг.* **предприятия**.

**СУПЕР-ӘБИ́** *и. ялг. Яшьлек ялкыны, кайнап-ургылып торган еллары узса да, ул яшәү мәгънәсенең тезгенен бушатмый, якты чырайлы, җылы күңелле мөлаем ханым, кадерле ана, сөекле **супер-әби**, хәрәкәтчән, эшлекле заман хатын-кызы, эчкерсез, ярдәмчел дус булып кала*. Ак калфак. *Ул быелгы **супер-әбиләрнең** иң яше, әле 54 яшен генә тутырган*. Якты юл; *дөр.:* **суперәби**; *к.* **фото-альбом**.

**СУПЕР-ГЕРО́Й** *и. ялг. Төп каһарман – **супер-герой**, аның яраткан кызы – беркатлы, гади*. Шәһри Казан. *Үрмәкүч кебек үрмәләп, кешеләрне коткаручы **супер-герой** турындагы фильмны балаларыбыз бертуктаусыз карарга әзер*. Татарстан яшьләре; *дөр.:* **супергерой**; *к.* **фото-альбом**.

**СУПЕР-ДИСКОТЕ́КА** *и. ялг. Таң атканчы ачык һавада **супер-дискотека**, күп кунаклар һәм җырчылар, конкурслар һәм бүләкләр, татарча камеди һәм позитив кәеф!.*. Тамаша; *дөр.:* **супердискотека**; *к.* **фото-альбом**.

**СУПЕР-ҖЫРЧЫ́** *и. ялг. Европаның **супер-җырчыларын** карарга барам дисәң – 2500–3000 сум*. Татарстан яшьләре; *дөр.:* **суперҗырчы**; *к.* **фото-альбом**.

**СУПЕР-ЙОЛДЫ́З** *и. ялг. «Кеше-дәвер» номинациясендә Николай Байбаковка, «Гражданлык вөҗданы» ордены кавалеры» номинациясендә Юрий Лужковка, --- **«Супер-йолдыз»** номинациясендә Людмила Гурченкога премия бирелде*. Татарстан Республикасы Рәсми серверның архивы; *дөр.:* **суперйолдыз**; *к.* **фото-альбом**.

**СУПЕР-КЛАССЛЫ́** *с. ялг. Техникасы да **супер-класслы** – «Мега-класс» комбайннарында эшлиләр*. Алга; *дөр.:* **суперкласслы, югары класслы**; *к.* **фото-альбом**.

**СУПЕР-КОМПЬЮ́ТЕР** *и. ялг. **Супер-компьютер** безгә дә килеп җитте*. Татарстан яшьләре; *дөр.:* **суперкомпьютер**; *к.* **фото-альбом**.

**СУПЕР-КУ́БОК** *и. ялг. Өстәл теннисыннан Европа чемпионнары **супер-кубогын** Казан шәһәрендә үткәрү буенча оештыру комитеты утырышы үткәрелде*. Татарстан Республикасы Хөкүмәте официаль порталы; *дөр.:* **суперкубок**; *к.* **фото-альбом**.

**СУПЕР-ПОПУЛЯ́Р** *с. ялг. Шулай итеп, июльнең эссе бер көнендә 30 **супер-популяр** йолдыз җыелышып, автобуска төяле-*

*шеп Казаннан чыгып китте.* Кәеф ничек?; *дөр.:* **суперпопуляр**; *к.* **фото-альбом**.

**СУПЕР-ПРИ́З** *и. ялг. 2013 нче елның I яртыеллыгына газе-табызга язылырга өлгермәүчеләрнең квитанцияләрен октябрь, ноябрь, декабрь айларында алып килергә өлгергән һәм киләсе елның 11 гыйнварына кадәр алып киләчәк язылучылар арасында уздырылачак уендагы биш* ***супер-призның*** *берсен алу мөмкинлеге бар.* Минзәлә; *дөр.:* **суперприз**; *к.* **фото-альбом**.

**СУПЕР-ПРОЕ́КТ** *и. ялг. 21 декабрьдә 18.30 сәгатьтә «Йолдызлар фабрикасы – 3»* ***супер-проектының*** *финалы башлана.* Татар-информ; *дөр.:* **суперпроект**; *к.* **фото-альбом**.

**СУПЕР-СТА́Р** *и. ялг. Бүгенге ярыш юкка гына* ***«Супер-стар»*** *дип аталмый.* Авыл офыклары; *дөр.:* **суперстар**; *к.* **фото-альбом**.

**СУПЕР-ТАМАДА́** *и. ялг.* ***«Супер-тамада»*** *Гамил Нур Яңа елда эшләүне шифаханәдә ял итүгә тиңли.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар; *дөр.:* **супертамада**; *к.* **фото-альбом**.

**СУПЕР-ТРЕ́НЕР** *и. ялг. – Бездә суперкоманда һәм* ***супер-тренерлар*** *эшли, – дип белдерде.* Татарстан яшьләре; *дөр.:* **супертренер**; *к.* **фото-альбом**.

**СУПЕР-ФӘННИ́** *с. ялг. Чөнки алар, буш урында нindидер* ***«супер-фәнни»*** *үзәк төзүгә караганда, акчаны берничә буын галимнәр төзегән һәм яшәүчәнлеген исбатлаган фәнни һәм гыйльми-җитештерү учреждениеләренең потенциалын үстерүгә тотыну күпкә отышлы, ди.* Кызыл таң; *дөр.:* **суперфәнни**; *к.* **фото-альбом**.

**СУПЕР-ФИНА́Л** *и. ялг.* ***Супер-финал*** *16–20 апрель көннәрендә Казанда уза.* Кайбыч таңнары; *дөр.:* **суперфинал**; *к.* **фото-альбом**.

**СУПЕР-ХИ́Т** *и. ялг. Араларында тамашачылар яратып өлгергән* ***супер-хитлар*** *урын алган: «Ярат әле», «Синсез», «Кыр казлары», «Алмагачлары».* Н. Галиев; *дөр.:* **суперхит**; *к.* **фото-альбом**.

**СУПЕР-ШОУ́** *и. ялг. Екатеринбург Дәүләт циркында Гия Эрадзеның «5 континент»* ***супер-шоу*** *премьерасы башланды.* Татар-информ. *Гомумән, «Йолдызлар фабрикасы» башка көннәргә караганда,* ***супер-шоу*** *булуы белән аерылып торды.* Кәеф ничек?; *дөр.:* **супершоу**; *к.* **фото-альбом**.

**СУПЕР-ЯҢА́** *с. ялг. Әлбәттә,* ***супер-яңа*** *җитештерү куәтләре, яңа автозаводлар яисә башка төр җитештерү мәйданнарын*

*булдыру базарында көндәшлек көчле*. Кызыл таң; *дөр.:* **суперъяңа, бик яңа, аеруча яңа, үтә яңа, бик алдынгы, нык алга киткән** һ.б.; *к.* **фото-альбом**.

**СУРӘТЛӘНЕЛҮ́** *ф. ялг. Ташбасмадагы Диюнең кул бармаклары карт чинар агачының ботакларына охшатылып **сурәтләнелсә,** бүтән басмалардагы Диюнеке адәм гәүдәсе кадәр итеп бирелә.* Ф. Яхин.

Ялгыш бер фигыльдә берьюлы ике юнәлеш кушымчасы ялгаудан гыйбарәт; *дөр.:* **сурәтләнү**.

**СУСА́У** *и.* Сусауга, сусавы, сусавына, сусаулар; *ялг.:* **сусауы, сусауына**. *Сиңа булган ташкын **сусауым** да, Мәхәббәттән иңгән теләктер*. В. Фатыйхов; *к.* **билбау**.

**СУФИ́** *и.* Суфига, суфие, суфиена; *ялг.:* **суфисы, суфисына**; *к.* **көрси**.

**СУФЛЕ́** *и.* Суфлега, суфлесы, суфлесына, суфлелар; *ялг.:* **суфлегә, суфлесе, суфлесенә, суфлеләр**; *к.* **атташе**.

**СУ́ШИ** *и.* Сушига, сушие, сушиена, сушилар; *ялг.:* **сушигә, сушисе, сушисенә, сушиләр; сушисы, сушисына**. *Республикабыз халкының күбесе милли ризыкны итальян пиццасына, американнарның гамбургерына һәм япон **сушисына** алыштырды.* Яңа гасыр; *к.* **бигуди**.

**СЫЕ́К-ЗӘҢГӘР** *с. ялг. **Сыек-зәңгәр** күзләрен мөлдерәмә итеп тутырып, гаять тә моңаеп, әллә нинди иләслек белән карады ул аңа*. М. Вәлиев; *дөр.:* **сыек зәңгәр**; *к.* **ачык-кызыл**.

**СЫЕ́К-ЗӘҢГӘРСУ** *с. ялг. Гади генә соры тактага беркетелгән **сыек-зәңгәрсу**, ком төсле, фил сөяге төсендәге рельефлар, бюстлар үзләренең композицион элементлары – алга чыгып торган якалары, кул-әгъзалары, чәч-түбәтәйләре ярдәмендә тирәлеккә бәйләнгәннәр.* Н. Гамбәр. *Сөләйман аның җиңеннән тотты, кәҗәләр ялый торган эре тоз төсендәге **сыек-зәңгәрсу** күзләрен өскә күтәрде*. Т. Галиуллин; *дөр.:* **сыек зәңгәр** яки **зәңгәрсу**; *к.* **куе-яшькелт**. ***Сыек*** компонентының төсне белдергән сүзләр белән язылышы турында *к.* **ачык-кызыл**.

**СЫЕ́К-КАРА** *с. ялг. Әле дә хәтеремдә, **сыек-кара** төстәге күлмәк иде ул*. Ялкын; *дөр.:* **сыек кара**; *к.* **ачык-кызыл**.

**СЫЕ́К-КӨРӘН** *с. ялг. **Сыек-көрән** төстәге пиджагын машинада юып әрәм иткән иде инде ул шулай*. Матбугат.ру; *дөр.:* **сыек көрән**; *к.* **ачык-кызыл**.

**СЫЕ́К-КРИСТАЛЛ** *с. ялг. Даими эшләп торган* ***сыек-кристалл*** *панельле олы телевизорына, моның барчагыз өчен дә әһәмияте бар, тыңлагыз дигән кыяфәт чыгарып, Гали Даутович көч бирә.* Ф. Яхин. *Республиканың икътисади һәм инвестиция потенциалын һәм аның үсеш юнәлешләрен күрсәтә торган видеоматериаллар* ***сыек-кристалл*** *плазмалы экраннарда күрсәтеләчәк.* Татар-информ; *дөр.:* **сыек кристалл ...-ы/-е, сыек кристаллы**.

**СЫЕ́К-КЫЗЫЛ** *с. ялг. Башта ул бала урындыгын* ***сыек-кызылга*** *буяган иде, аннары ул төсне яратмыйча акка буяп куйды.* А. Вәлиева; *дөр.:* **сыек кызыл**; *к.* **ачык-кызыл**.

**СЫЕ́К-САРГЫЛТ** *с. ялг. Рус теле укытучысы гадәтенчә өстенә ак кофта, кара юбка кигән, кыска,* ***сыек-саргылт*** *чәчләрен күпертеп, тырпайтып куйган иде.* Н. Фәттах; *дөр.:* **сыек сары** яки **саргылт**; *к.* **куе-яшькелт**.

***Сыек*** компонентының төсне белдергән сүзләр белән язылышы турында *к.* **ачык-кызыл**.

**СЫЕ́К-САРЫ** *с. ялг. Кызыгырлык әллә ние юк,* ***сыек-сары*** *төстәге әчкелтем-төчкелтем эчемлек.* С. Сөләйманова; *дөр.:* **сыек сары**; *к.* **ачык-кызыл**.

**СЫЕ́К-ШӘМӘХӘ** *с. ялг.* ***Сыек-шәмәхә*** *төстәге тукыма эзли-эзли кермәгән кибете калмады.* Кызыл таң; *дөр.:* **сыек шәмәхә**; *к.* **ачык-кызыл**.

**СЫЕ́К-ЯШЕЛ** *с. ялг. Ягъфәр автобустан төшеп калды да, --- инде суык куырып, түмгәк иткән* ***сыек-яшел*** *калдык-постыкка игътибарын, карашын юнәлтәсе килмәстән ары таба – авыл очыннан бирегә таба сигезенче санынча торган йорт-җире тарафына атлый бирде.* Ә. Гаффар; *дөр.:* **сыек яшел**; *к.* **ачык-кызыл**.

**СЫЛТА́У** *и.* Сылтауга, сылтавы, сылтавына, сылтаулар; *ялг.:* **сылтауы, сылтауына**. *Ире таба тизрәк* ***сылтауын***. Ф. Дәүләтгәрәева; *к.* **билбау**.

**СЫМА́Н** *бәйл. ялг.:* **сыманырак**. *Ул пәринең тавышы да сәер, бичә тавышы* ***сыманырак*** *иде.* З. Мурсиев; *дөр.:* **сыманрак**; *к.* **бай**.

**СЫНА́У** *и.* Сынауга, сынавы, сынавына, сынаулар; *ялг.:* **сынауы, сынауына**. *– Аллаһы Тәгаләнең* ***сынауы*** *инде бу, Талиб туган,* ***сынауы*** *төрле кешене төрлечә сыный инде... тәкъдиргә язылган булса, бернәрсә эшләп булмый.* Рәсим хәзрәт Хәбибулла сайты; *к.* **билбау**.

**ТА́БЕЛЬЛЕ** *с.* Табеле булган; табель рәвешендә эшләнгән; *ялг.:* **табельле пистолет, табельле корал**. *Ул эш бүлмәсендә **табельле** пистолеттан башына аткан*. Ватаным Татарстан.

Хаталы куллану «табельное оружие» сүзтезмәсен ялгыш рәвештә эчтәлегеннән түгел, формасыннан чыгып тәрҗемә итү нәтиҗәсендә барлыкка килгән; *дөр.:* **табельдә теркәлгән корал, табель буенча каралган корал**.

**ТАБИБЧЫЛЫ́К** *и. ялг. **Табибчылык** гыйлемен белмәгән кешенең дәвасыннан зур зыян гына күрергә мөмкин*. Й. Дәүләтшин; *дөр.:* **табиблык**; *к.* **каллиграфчы**.

**ТАБИГЫ́Й** *с. ялг.:* **табигыерак, табигыерәк, табигыйрәк**. *Ә бит моңа кадәр бездә җитештерелгән авыл хуҗалыгы продуктлары **табигыерак**, экологик чистарак булулары белән аерылып тордылар һәм без бу өстенлеккә нәкъ менә артык зур булмаган фермаларда ирешеп килдек*. Р. Шәрәфиев; *дөр.:* **табигыйрак**; *к.* **бай**.

**ТАВЫ́К** *и.* Тавыкка, тавыгы, тавыгына, тавыклар; *ялг.:* **тауыкка, тауыгы, тауыгына, тауыклар**. – *Сикереп торды да парта өстендәге, теге әтәч белән **тауык** төшкән түгелми торган фарфыр кара сауытын алды да җеппәрде миңа шуның белән*. З. Зәйнуллин. ***Тауык** дигәннән, атаңа әйтергә кирәк әле, **тауык** суеп бирсен...* Л. Лерон; *к.* **билбау**.

**ТАВЫ́Ш** *и.* Тавышка, тавышы, тавышына, тавышлар; *ялг.:* **тауышка, тауышы, тауышына, тауышлар**. *Ә КПРФка **тауышын** биргән кешеләр турында әйкәндә, аларга аңлашылды дияргә була, бандитлар капитализмының киләчәге юк икәнлеге*. Безнең гәҗит. *Зиннур Бикмәт тауы өстеннән агылган көзге саргылт болытларга карап әтисен **тауышсыз** гына тыңлап утырды да, табигать тарафыннан бирелгән үҗәтлеген күрсәтте ---*. З. Зәйнуллин; *к.* **билбау**.

**ТАНЫ́П-БЕЛҮ** *ф. ялг. Әмма танып-белү гомумиләштерү-**абстракцияләүдән** гайре була алмый*. Ф. Яхин; *дөр.:* **танып белү**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ТА́У** *и.* Тауга, тавы, тавына, таулар; *ялг.:* **тауы, тауына**. *Питер армиясенә тупларны, менәтерә, безнен шул Бакырбаз **тауыннан** алганнар*. Р. Батулла. *Азмы-күпме барганнардыр, кояш батышына Оло Бөгдә **тауына** килеп җитәләр*. В. Ильясов. *Мәгълүм закон буенча «а» хәрефеннән соң «у» хәрефе һич языла алмый, чөнки ул чагында ике генә түгел, өч сузык аваз янәшә булып чыга: **тауы**, бауы*. Фән һәм тел. *Әйтик, Саескан тавындагы Чулман күперенә*

*керү юлында юл күрсәткечтә «Саескан **тауы**» дип язып куелган һәм ул инде күптән тора.* Безнең гәҗит; *к.* **билбау**.

**ТӘВӘККӘЛЧЕЛЕ́К** *и. ялг. дөр.:* **тәвәккәллек**; *к.* **каллиграфчы**.

**ТӘЙМИ́Н** *и. ялг. Шуңа күрә Сергач ТВ бер төркем татарны эш белән **тәймин** итү урынына, касета куйдыра да, булды шуның белән.* М. Миначев. *«Бүгенгесе көндә меңнән артык этиәни чиратта тора, бу юнәлеш өстендә эшлисе, балалар бакчасы белән **тәймин** итү өстендә эшлисе бар», – дип конференциядә чыгыш ясый мәгариф эшләрен оештыручы олуг бер татар түрә.* Р. Абдуллина; *дөр.:* **тәэмин**.

**ТӘЙСИ́Р** *и. ялг. Бу яшь кеше миндә бик яхшы **тәйсир** калдырды, укымыш, аңлы егет, милли аң, милли горурлык хисләре дә аңа ят түгел.* М. Миначев. *Теге хәбәрләр укучыларның берсе «тәэсир» диясен «**тәйсир**» дип кенә җиббәрә.* Ә. Хәсәнов. *Әстерхан чикләвеген куллану организмдагы «яхшы» холестеринның күләмен арттыра, ә менә «начар» холестеринны киресенчә кысрыклап чыгара, ә бу исә йөрәк эшчәнлегенә уңай **тәйсир** итә.* Сәхнә; *дөр.:* **тәэсир**.

**ТӘРӘККЫЙПӘРВӘРЧЕЛЕ́К** *и. ялг.; дөр.:* **тәрәккыйпәрвәрлек**; *к.* **каллиграфчы**.

**ТӘРҖЕМӘИ́** *с. ялг.:* **тәрҗемәи текст, тәрҗемәи сүзлек.** ***Тәрҗемәи** репертуар белән милли сәхнә барлыкка килә алмавы кебек, милли рухы булмаган мөхәррирләр тарафыннан язылган пьесалар да милли сәхнәне барлыкка китерә алмый.* Г. Исхакый. *Инҗилнең **тәрҗемәи** тәфсирләре дә шул юлдан китә.* И. Әмирхан. *Фондта **тәрҗемәи**, аңлатмалы, ике һәм күп телле сүзлекләр урын ала, – диде ул.* Сәхнә; *дөр.:* **тәрҗемә ...-ы/-е, тәрҗемәле, тәрҗемә ителгән, тәрҗемәдәге** һ.б.; *к.* **мәгълүмати**.

**ТӘРҖЕМӘИ-ХӘ́Л** *и.* Берәр кешенең үткән тормыш юлының, эшчәнлегенең тасвирламасы; биография; *дөр.:* **тәрҗемәи хәл**.

**ТӘТИ́** *и.* Тәтигә, тәтие, тәтиенә; *ялг.:* **тәтисе, тәтисенә**; *к.* **әби**.

**ТӘЭМИНАТЛА́Р** *и. күпл. ялг. Акча җәлләп арзанлы программа **тәэминатларыннан** файдаланып, без аларга ярдәм итәбез.* Кызыл таң. *Җирле үзидарә органнары муниципаль берәмлекләрнең сайлау комиссияләре аппаратлары хезмәткәрләренең матди һәм социаль тәэминаты (шул исәптән медицина, шифаханә-курорт, торак-көнкүреш, пенсия һәм башка төрле **тәэминатлар**) буенча кирәкле чаралар күрә.* Татарстан Республикасы Сайлау кодексы;

*дөр.:* **тәэминат, тәэмин ителеш, тәэмин итү чаралары, тәэмин итү хезмәтләре** һ.б.; *к.* **мәгълүматлар**.

**ТӘЭСОРАТЛА́Р** *и. күпл. ялг. Кардәшләребез юлда хәзрәтләрнең вәгазьләрен тыңлап, уңай* ***тәэсоратлар*** *алып, өйләренә арып-талып, ләкин канәгать төс белән кайтып керде.* Алабуга нуры. *Бусы соңгы араларда еш булып, күп кешеләр белән аралашып йөрүдән алган* ***тәэсоратларым*** *иде.* Татарстан яшьләре; *дөр.:* **тәэсир, тәэсорат, тәэсирләр** һ.б.; *к.* **мәгълүматлар**.

**ТЕАТРА́Л** *и.* Театр яратучы, театр һәвәскәре; *ялг.:* **театрал вуз, театрал чара**, **театрал позага басу**. *Башкалабызда 13–17 июнь көннәрендә IV «Нәүрүз» Халыкара* ***театрал*** *белем бирү форумы узды*. Шәһри Казан; *чаг.:* **театраль**; *к.* **вокаль**.

**ТЕАТРА́ЛЬ** *с.* Театрга бәйләнешле; театр эшенә, сәнгатенә караган; *чаг.:* **театрал**; *к.* **вокаль**.

**ТЕКСТИ́ЛЬ** *и.* Текстильгә, текстиле, текстиленә, текстильләр; *ялг.:* **текстильга, текстилена, текстильлар**. *Пыялага, пластикага һәм* ***текстильга*** *әлегә ихтыяҗ юк югын, әмма әз генә өмет бар: Васильево пыяла заводы яңа төр продукция эшләп чыгаруга күчсә, пыяла калдыкларын ала башларга мөмкин.* Яшел Үзән; *к.* **апрель**.

**ТЕЛӘСӘ́-КАЙДА** *а. ялг. Раушания* ***теләсә-кайда*** *теләсә-кем булып эшләсә дә, нәкъ урынында булачак*. М. Хәйруллина; *дөр.:* **теләсә кайда**; *к.* **әллә-кайда**.

**ТЕЛӘСӘ́-КАЙСЫ** *а. ялг. Компьютерны да, ноутбукны да махсуслашкан кибетләрдә генә түгел, ә* ***теләсә-кайсы*** *гипермаркетта яки аппаратура сатучы сәүдә үзәгендә табарга була.* Д. Сәфәров. *Монда студентларга* ***теләсә-кайсы*** *өлкәдә комплекслы тикшеренү үткәрелә.* Р. Закирова. *Бер кеше генә хәлне үзгәртә алмый, әгәр без бердәм булып күмәкләшеп тотынсак,* ***теләсә-кайсы*** *эшне хәл итәргә сәләтлебез, – дип уртаклашты Ислам хәзрәт.* Э. Фатыйхова; *дөр.:* **теләсә кайсы**; *к.* **әллә-кайда**.

**ТЕЛӘСӘ́-КАЙЧАН** *а. ялг. Ике йорт аша гына дөнья күргән Соня таң туды исә килеп җитәр, төн булуга карамастан, ишек ачтырыр,* ***теләсә-кайчан*** *чәен дә, мәен дә таптырыр.* Ә. Галиева. *Таһир абый безгә ялтыратып юылган һәм* ***теләсә-кайчан*** *юлга кузгалырга әзер торучы өч машинаны да күрсәтте әле.* Э. Фатыйхова; *дөр.:* **теләсә кайчан**; *к.* **әллә-кайда**.

**ТЕЛӘСӘ́-КЕМ** *а. ялг. – Ниһаять, чистарачакбыз, шәһәр яшелләнәчәк һәм матур булып үсеп утырган агачларны да* ***теләсә-кем,***

*теләсә-ничек кисмәячәк, димәк?* Н. Сафиуллина; *дөр.:* **теләсә кем**; *к.* **әллә-кайда**.

**ТЕЛӘСӘ́-НИ** *а. ялг. «Шәрык» клубына теләсә-кем йөри, теләсә-кем **теләсә-ни** сөйли башлады.* Э. Фатыйхова; *дөр.:* **теләсә ни**; *к.* **әллә-кайда**.

**ТЕЛӘСӘ́-НИНДИ** *а. ялг.* Нинди дә булса; кайсыдыр, кайсы да булса. *Аның ярдәмендә без **теләсә-нинди** рус белән аралашырлык һәм танылган рус язучыларының әсәрләрен укып аңларлык дәрәҗәдә булдык.* С. Шакиров. *Ул **теләсә-нинди** бушлыкны тутыра алыр сыман.* Э. Ибраһимова. ***Теләсә-нинди** серне сыйдыра иде, тота белә иде.* М. Әмирханов; *дөр.:* **теләсә нинди**; *к.* **әллә-кайда**.

**ТЕЛӘСӘ́-НИЧЕК** *а. ялг. Ниһаять, чистарачакбыз, шәһәр яшелләнәчәк һәм матур булып үсеп утырган агачларны да теләсә-кем, **теләсә-ничек** кисмәячәк, димәк?* Н. Сафиуллина; *дөр.:* **теләсә ничек**; *к.* **әллә-кайда**.

**ТЕЛӘСӘ́-НИШЛӘТҮ** *ф. ялг. – Барыбер утырмыйм мин ул комбайнга, **теләсә-нишләтсеннәр**, – дип кычкырып калды ул алар артыннан.* Кызыл таң; *дөр.:* **теләсә нишләтү**; *к.* **әллә-кайда**.

**ТЕЛӘСӘ́-НИШЛӘҮ** *ф. ялг. Хәер, уены **теләсә-нишләсен**, тик Ленар гына терелә күрсен иде.* Татарстан яшьләре. *Хәзер халык теләсә кая барып **теләсә-нишләп** йөрергә гадәтләнгән.* Кәеф ничек? *Буага да халыкка керергә рөхсәт бирәм, су керсеннәр, **теләсә-нишләсеннәр**.* Безнең гәҗит; *дөр.:* **теләсә нишләү**; *к.* **әллә-кайда**.

**ТЕ́ЛБИСТӘЧЕЛЕК** *и. ялг.; дөр.:* **телбистәлек**; *к.* **каллиграфчы**.

**ТЕРӘ́Ү** *и.* Терәүгә, терәве, терәвенә, терәүләр; *ялг.:* **терәүе, терәүенә**; *к.* **билбау**.

**ТЕРРОРЛЫ́К** *и. ялг. Америка хәрби һава көчләренең кечкенә Вьетнамны пыран-заран китереп ташлавы Нью-Йоркта булган **террорлык** гамәленнән кечкенәмени, Буш әфәнде?* Р. Батулла. ***Террорлык** актлары илебездә дә, чит илләрдә дә күзәтелә.* Шәһри Казан.

Татар телендә түбәндәге сүзләр бар, һәм алар шушы мәгънәләргә туры килә: ***террор*** – күренеш, ***террорчы*** – шуның белән шөгыльләнүче, ***террорчылык*** – шундый эшчәнлек. ***Террорлык*** сүзе ***террор+лык*** моделе белән ясалган, андый модель телдә бар, ләкин бу очракта яңа мәгънә китереп чыгармый, ***террорлык*** сүзенең мәгънәсе ***террор*** сүзенең мәгънәсенә генә кайтып кала; *дөр.:* **террор, террорчылык, терроризм**; *к.* **каллиграфчы**.

**ТЕ́СТЛАШТЫРУ** *ф. ялг.* --- *канны вирус инфекцияләре маркерларына* ***тестлаштыру*** *сыйфаты яхшырган һәм 100 дән артык медицина һәм лаборатория җайланмасы эксплуатациягә тапшырылган*. «Мәйдан» журналы. *4 нче сыйныфларны бердәм дәүләт имтиханы технологиясе буенча* ***тестлаштыру*** *нәтиҗәләре укучыларның рус теле һәм математикадан яхшы хәзерлеген күрсәткән.* «Маяк» газетасы; *дөр.:* **тестлау;** *к.* **стимуллаштыру**.

**ТЕФТЕ́ЛИ** *и.* Тефтелига, тефтелие, тефтелиена; *ялг.:* **тефтелигә, тефтелиенә**. *Подлива әзерләү: томат соусын су белән кушып, тоз һәм специяләр өстәргә,* ***тефтелиләр*** *өстенә сибеп 10 минут томалап пешерергә.* Туганайлар. *«Бушлай туклануучылар» өстәлендә (6 сум 10 тиен күләмендәге субсидиягә туклануучылар),* ***тефтелидән*** *кала, шул ук ризыклар бар иде.* novoshishminsk.ru; *к.* **бигуди**.

**ТИМРӘ́Ү** *и.* Тимрәүгә, тимрәве, тимрәвенә, тимрәүләр; *ялг.:* **тимрәүе, тимрәүенә**; *к.* **билбау**.

**ТОМА́-СУКЫР** *с. ялг. Бер кызым Бәләбәйдә, ул тумыштан* ***тома-сукыр***. Өмет; *дөр.:* **тома сукыр**; *к.* **чем-кара**.

**ТОМА́-ТОМАНА** *с. ялг. Соң, мөхтәрәм коллегалар, Думада утыручыларның эш-гамәлләре ачык күрсәтте – барысы да алар* ***тома-томана*** *бит.* Н. Әхмәдиев; *дөр.:* **тома томана**; *к.* **чем-кара**.

**ТОМА́-ЮККА** *рәв. ялг.*; *дөр.:* **тома юкка**; *к.* **чем-кара**.

**ТОМА́-ЯТИМ** *с. ялг. Зарема бердәнбер якын кешесе – туган абыйсы белән икәү* ***тома-ятим*** *калды*. И. Диндаров. *Биш яшендә* ***тома-ятим*** *калып, 12 яше тулгач үз тамагын үзе туйдыру өчен Чистай каласына күчкән ---*. Мәдәни җомга; *дөр.:* **тома ятим**; *к.* **чем-кара**.

**ТО́М-КАРА** *с. ялг. Күрше баярның нәрсәләре сатылганын ишеткәч, атын җиктереп чапты да, ни уй беләндер, шуннан җигүле көенчә, бик огъля көймә, ызбруй белән* ***том-кара*** *ике ат алып кайтты.* Г. Ибраһимов; *дөр.:* **том кара**; *к.* **чем-кара**.

**ТО́М-СУКЫР** *с. ялг. Безнең урамда* ***том-сукыр*** *бер карчык яши, шуның янына барып йөри ул*. Матбугат.ру; *дөр.:* **том сукыр**; *к.* **чем-кара**.

**ТОННЕ́ЛЬ** *и.* Тоннельгә, тоннеле, тоннеленә, тоннельләр; *ялг.:* **тоннельга, тоннелена, тоннельлар**. *Моннан тыш, шәһәрдә 30 җир асты кичүендә, тагын төзелә торган дүртесендә һәм Н. Ершов урамындагы* ***тоннельда*** *22 насоска ревизия ясала.* Татар-информ. *Күрше, 1351 метр озынлыктагы сул яктагы* ***тоннельда***

*«Сөембикә» тоннель уза торган комплексы эшли.* Казан мэриясенең рәсми порталы; *к.* **апрель**.

**ТӨБӘ́КАРА** *с. ялг. Җыенның «**төбәкара**» дигәне исә хаклы: Пенза, Волгоград, Мордовия вәкилләре дә чыгыш ясады.* А. Ибраһим. *«Звезда Поволжья» баш мөхәррире Казандагы **Төбәкара** клиник-диагностик үзәктә, йөрәк авырулары бүлегендә ята.* Б. Тимерова; *дөр.:* **төбәгара**; *к.* **ишекалды**.

**ТӨГӘ́Л** *с. ялг.:* **төгәлерәк**. *XVIII гасыр азагыннан XX гасыр башына (**төгәлерәк**, 1913 елга) кадәр дәверне үз эченә алган беренче өлешнең исемен шулай дип атарга да мөмкин.* Матбугат.ру. *Ул инде үзенең элеккеге шахтасында урын алачак, **төгәлерәк** әйтсәк, үзәк хастаханә фойесында.* Йолдыз; *дөр.:* **төгәлрәк**; *к.* **бай**.

**ТӨШЕНКЕЛЕ́** *с. ялг. Дөрес, әлеге баскыч асылда рухның җимерелүен чагылдыра, ягъни ул – күңел **төшенкеле** этабы.* И. Нуруллин; *дөр.:* **төшенке**; *к.* **каллиграфчы**.

**ТРУСЫ** *и.* Трусыга, трусые, трусыена, трусылар; *ялг.*: **трусысы, трусысына**.

**ТУННЕ́ЛЬ** *и.* Туннельгә, туннеле, туннеленә, туннельләр; *ялг.:* **туннельга, туннелена, туннельлар**. *Оптимист: «Мин **туннельның** теге башында ут күрәм».* Өмет. *Һөҗүмнәрдән берсе Мисыр чигенә якын Рәфахтагы **туннельлардан** берсенә юнәлдерелгән.* «Азатлык радиосы» сайты; *к.* **апрель**.

**ТУРНЕ́** *и.* Турнега, турнесы, турнесына, турнелар; *ялг.:* **турнегә, турнесе, турнесенә, турнеләр**; *к.* **атташе**.

**ТУ́ФЛИ** *и.* Туфлига, туфлие, туфлиена; *ялг.:* **туфлигә, туфлиенә, туфлисе, туфлисенә**. *Кемдер шәһәргә озаграк күнегә, ә кемдер икенче көнне үк әти-әнисе җибәргән акчага модалы кием алып, тырнагын буяп, биек үкчәле **туфлигә** күчә.* Өмет. *Ә менә яшь килен белән биергә теләсәң, кәләшнең түгәрәк уртасына куелган **туфлиенә** бер-ике «кыштырдый торган» акча салырга кирәк икән.* Ватаным Татарстан; *к.* **бигуди**.

Татар телендә ***туфли*** сүзенең фонетик үзләштерелгән варианты буларак ***түфли*** сүзе дә бар. Сүзнең һәр ике варианты бер үк дәрәҗәдә актив кулланыла. Ләкин аларның парадигмасы аерыла, ***туфли*** – барлык кушымчалары – арткы рәт, ***түфли*** – алгы рәт; *чаг.:* **түфли**.

**ТУЫ́П-ҮСКӘН** *с.* Туган һәм үскән (йорт, авыл, як тур.). ***Туып-үскән*** *җирләрдән көчләп аеру кеше йөрәгенә шулай гомере*

*буе төзәлмәс яра-җәрәхәт сала торгандыр шул инде.* М. Хәсәнов. *Язучының ачышларын аңлау, фәлсәфәсенә төшенү өчен **туып-үскән** туфрагына аяк басу, **туып-үскән** йортын күрү кирәк, диләр.* Т. Галиуллин. *Яшь чакта, мәхәббәттән исергән бер төндә, **туып-үскән** өен дә буташтырганы бар иде аның.* Ф. Җамалетдинова; *дөр.:* **туып үскән**; *к.* **либераль-иктисад**.

**ТҮГӘРӘ́КАВЫЗЛЫЛАР** *и. күпл. зоол. ялг.* Саңаксыз умырткалылар төркеме; *дөр.:* **түгәрәгавызлылар**; *к.* **ишекалды**.

**ТҮЗЕМЧЕЛЕ́К** *и. ялг.; дөр.:* **түземлек**; *к.* **каллиграфчы**.

**ТҮТИ́** *и.* Түтигә, түтие, түтиенә; *ялг.:* **түтисе, түтисенә**. *Тик аннан кайткач каты авырый ул, ясин да чыгалар үзенә, шуннан Ходайның рәхмәте белән савыга һәм Үчкә авылында туып, яшь ярымлык чагыннан ук әбисе Майтап, бабасы Тимеркәй, Зәйтүнә **түтисе** Йөзекиннәрдә тәрбияләнеп, бик яшьли үгез, ат җигеп, җир эшенә хирыс булып үскән Мөнир исемле егеткә кияүгә чыга.* Ватаным Татарстан. *Гөлсинә шәһәрдә **түтисе** янында яшәргә торып калды, ничектер үзеннән-үзе килеп чыкты бу.* Өмет; *к.* **әби**.

**ТҮФЛИ́** *и.* Түфлигә, түфлие, түфлиенә, түфлиләр; *ялг.:* **түфлига, түфлиена, түфлилар, түфлисе, түфлисенә**; *чаг.:* **туфли**; *к.* **гәләфи**.

**ТЫЙНАКЛЫ́** *с. ялг. Бәхәсләшкәндә, үзеңне **тыйнаклы** итеп тотарга кирәк.* Р. Абдуллина. *Дөрес, әдәпле вә **тыйнаклы** атабыз Адәм, оят саклап, янәдән 300 буена анабыз Хавага якын килми әле.* Казан утлары; *дөр.:* **тыйнак**; *к.* **каллиграфчы**.

**УГЛЕВО́Д** *и.* Углеводка, углеводы, углеводына, углеводлар; *ялг.:* **углевотка, углевоты, углевотына, углевотлар**; ***к*. гибрид**.

**УКЛА́У** *и.* Уклауга, уклавы, уклавына, уклаулар; *ялг.:* **уклауы, уклауына**. – *Син, кемкәем! – дип дәште аңа Вәсбиҗамал карчык, – **уклауыңны** оныттың бит.* Л. Лерон; *к.* **билбау**.

**УЛЬТРА-КЫСКА́** *с. ялг. «Татарстан» каналыннан гайре (ул күбрәк озын һәм **ультра-кыска** дулкында эшли), бездә FM дулкынында бүтән мондый уйчан, моңлы радио юк иде.* Татарстан яшьләре. *1960–1980 елларда радио һәм телевидениенең материаль-техник базасы тагын да ныгый, --- **ультра-кыска** дулкыннарда эш тотрыклы үсеш ала.* Википедия; *дөр.:* **ультракыска**; *к.* **фото-альбом**.

**УЛЬТРА-МО́ДАЛЫ** *с. ялг. Яшьләр генә кия торган **ультрамодалы** бүрек.* Д. Булатова; *дөр.:* **ультрамодалы**; *к.* **фото-альбом**.

**УЛЬТРА-ТАВЫ́Ш** *и. ялг. Ул **ультра-тавыш** белән тикшерүче табиб белгечлеге үзләштерә.* Биектау хәбәрләре; *дөр.:* **ультратавыш**; *к.* **фото-альбом**.

**УЛЬТРА-ФИОЛЕ́Т** *и. ялг. Кояш белән Җир арасында ай кереп, **ультра-фиолет** нурларны безгә җиткерми – кояш тотылу күренеше барлыкка килә.* «Азатлык радиосы» сайты; *дөр.:* **ультрафиолет**; *к.* **фото-альбом**.

**УЛЬТРА-ШӘМӘХӘ́** *с. ялг. Стратосфера катламындагы озон космостан килүче зарарлы **ультра-шәмәхә** нурларны, радиацияне тоткарлый һәм тереклекне алардан саклый.* Белем. ру. *Тагын бер алым ул суны төптән чыгарган вакытта **ультрашәмәхә** нурлары аша үткәрәбез.* Кызыл таң; *дөр.:* **ультрашәмәхә**; *к.* **фото-альбом**.

**УЛЬТРА-ЯШЕ́Л** *с. ялг. Моңарчы күз күрмәгән начеслар, ялтыравык чәч кыстыргычлары, **ультра-яшел** яки кура җиләге төсендәге дредлар, көдрәләрне йә шомарталар, йә спираль итеп урыйлар.* Сөембикә; *дөр.:* **ультраяшел**; *к.* **фото-альбом**.

**УНИВЕРСА́Л** *и. ялг.* Төрле-төрле белгечлекләргә ия булган кеше; *ялг.:* **универсал дару, универсал эш коралы, универсал машина**. *Кешеләре дә тормыш-көнкүрештә ни кирәк булса, шуны уз кулы белән «әтмәли» торган **универсал** куллы крестьяннар түгел, һәркайсы укып, һөнәр-белем алып үскән белгечләр: шоферлар, механизаторлар, бакчачылар, терлекчеләр, сыер савучылар.* Казан утлары. *Гомумән, һәр биеклеккә сикерүче **универсал** спортчы була ала.* Кызыл таң; *чаг.:* **универсаль**; *к.* **вокаль**.

**УНИВЕРСА́ЛЬ** *с.* Күпьяклы, һәрнәрсәне белүче; күптөрле максатлар өчен яраклы, төрле функцияләр башкара торган; *чаг.:* **универсал**; *к.* **вокаль**.

**УҢАЙ** *с. ялг.:* **уңаерак**. *Нидер сайлаганда әйтелә торган сүз – бусы **уңаерак**, алырга була.* Матбугат.ру; *дөр.:* **уңайрак**; *к.* **бай**.

**УҢЫШЛЫКЛА́Р** *и. күпл. ялг. Хәзер «**уңышлыклар**» тели башладылар, юкса элек кешегә «уңышлар» тели идек.* Татарстан яшьләре. *Әлбәттә, миңа болар турында сөйләү уңайсыз, әмма сүз күзгә күренеп торган **уңышлыклар** турында бара.* Ватаным Татарстан; *дөр.:* **уңышлар, уңыш теләү, уңышка ирешү, уңышларга ирешү**; *к.* **каллиграфчы**.

**УРЫ́П-ҖЫЮ** *ф. ялг. **Урып-җыю** күптән тәгәлләнде.* Р. Батулла. *Байрасның ай буе кайтканы юк, аны кайсыдыр авылга*

*көзге* ***урып-җыюга*** *җибәргәннәр, ахры*. З. Кадырова; *дөр.:* **урып җыю**; *к.* **либераль-икътисад**.

**УТРА́У** *и.* Утрауга, утравы, утравына, утраулар; *ялг.:* **утрауы, утрауына**. *Русиянең Баш мөфтие, Үзәк Диния нәзарәте рәисе Тәлгат Таҗетдингә Сахалин* ***утрауы*** *татарлары исеменнән зур рәхмәт.* Татар заманы. *Бүреләр Хәлимне үлемнән коткарып калгач, ул шул сихерчеләр* ***утрауы*** *тирәсендәге урманнарда көннәр-атналар буена адашып йөри.* Ф. Урманчеев; *к.* **билбау**.

**УЧИ́ЛИЩЕ** *и.* Училищега, училищесы, училищесына; *ялг.:* **училищегә, училищесе, училищесенә**. *Яхья хыяллана иде, өметләнә иде, бичара, Акмәчеттә (Симферопольдә) татар балалары өчен музыка* ***училищесе*** *ачам, дип планнар кора иде.* Р. Батулла. *Ринат, һөнәрчелек* ***училищесе*** *тәмамлап, токарь булып киткән, яшьтән сайлаган һөнәренә тугры булып калган.* Туган як. *Ләкин музыкаль* ***училищегә*** *укырга алырлар микән, дигән шик бар иде.* Татар заманы; *к.* **атташе**.

**УЧРЕЖДЕ́НИЕ** *и.* Учреждениегә, учреждениесе, учреждениесенә; *ялг.:* **учреждениега, учреждениесы, учреждениесына**. *Ул* ***учреждениены*** *карап чыкканнан соң, шәхси сораулар буенча сак астындагыларны кабул итте.* Татар-информ. *Республика программасында, санитария бүлмәләре, кабинетара ишекләрен яңартуга чыгымнар кермәгәндә,* ***учреждениены*** *ремонтларга 8 миллион сум акча каралган.* Intertat.ru; *к.* **звание**.

**УЧРЕЖДЕ́НИЯ** *и. ялг. Бер яктан, шундый «кабала»га капкан бичара халык кызганыч, икенче яктан, суд карары нигезендә кредит* ***учрежденияләренең*** *мәнфәгатьләрен кайгырту – безнең бурыч*. Татарстан яшьләре. *Югары квалификацияле кадрлар әзерләүдә 130 елдан артык тәҗрибәсе булган вузның күп санлы коллективы исеменнән гомумбелем мәктәпләрен, башлангыч, урта һөнәри белем* ***учрежденияләрен*** *тәмамлаучыларны имтиханнарны, йомгаклау аттестациясен лаеклы үтүләрен телим һәм университетыбызга укырга чакырам!* Безнең гәҗит; *дөр.:* **учреждение**; *к.* **предприятия**.

**ҮЛЧӘ́Ү** *и.* Үлчәүгә, үлчәве, үлчәвенә, үлчәүләр; *ялг.:* **үлчәүе, үлчәүенә**. *Һәрбер кеше үз* ***үлчәүе****, үз тәлинкәсенә салып карый, үз мөмкинлегеннән чыгып кына фикерли ала*. Матбугат.ру. *Мәсәлән, вакыт* ***үлчәүе*** *(календарь төзү, көн озынлыгы һәм намаз вакы-*

*ты билгеләүе), --- Ай һәм Кояш тотылулар мизгелләрен хисаплау*. Википедия; *к.* **билбау**.

**ҮТӘ-МАТУ́Р** *с. ялг. Син бүген **үтә-матур***. Казан утлары; *дөр.:* **үтә матур**; *к.* **чем-кара**.

**ҮТӘ-ҮТКЕ́Н** *с. ялг. Үз фикерләренә тәңгәл булган информатив фәнни цитаталардан ясалган **үтә-үткен** цитата-мәкаләләре дә аз түгел*. М. Гайнетдин; *дөр.:* **үтә үткен**; *к.* **чем-кара**.

**ҮТӘ-УСА́Л** *с. ялг. Гаҗәп тә түгел, **үтә-усал** кешеләр күп шул хәзер*. Кызыл таң; *дөр.:* **үтә усал**; *к.* **чем-кара**.

**ҮТӘ-ЯВЫ́З** *с. ялг. Аны кул астындагыларына карата **үтә-явыз** булган дип сөйлиләр*. Матбугат.ру; *дөр.:* **үтә явыз**; *к.* **чем-кара**.

**ФАКСИ́МИЛЕ** *и*. Факсимилега, факсимилесы, факсимилесына, факсимилелар; *ялг.:* **факсимилегә, факсимилесе, факсимилесенә, факсимилеләр**. *Ягъни Татарстан Милли китапханәсендә тупланган борынгы әдәби ядкярләрнең кулъязма текстларын гамәлдәге татар хәрефләрендә транскрипцияләп, махсус мәкаләләр язып, аларны **факсимилеләре** белән «Татар археографиясе» сериясендә нәшер итә башлады*. Р. Исламов. *Гамәшев эшләгән **факсимилесен** дә үзе илтергә теләмәде, Нина Ахуновнага биреп җибәрде*. Х. Камалов. *Китапта бу ике әсәрнең хәзерге татар язуына күчерелмәсе, хәзерге татар әдәби теленә юлга-юл күчерелмәсе, файдаланылган кулъязманың **факсимилесе** һәм тасвирламасы бирелгән*. Гасырлар авазы; *к.* **атташе**.

**ФАРСИ́** *с. ялг. Шулай бер көн **фарси** патшасы, үз вәзиренә нигәдер ачуы килеп, аны төрмәгә яптыра*. Кәеф ничек? *Скифлар дип грек, Византия һәм **фарси** авторлар һуннарны, төркиләрне һәм татарларны атаганнардыр дип әйтергә була.* И. Хуҗин.

Татар телендә *фарси* сүзе юк. Ул русчада гына бар һәм «фарсы теле» мәгънәсендә кулланыла: *Он хорошо знает фарси* «Ул фарсы телен әйбәт белә»; *дөр.:* **фарсы**; *к. ш. ук* **мәгълүмати**.

**ФАСА́Д** *и*. Фасадка, фасады, фасадына, фасадлар; *ялг.:* **фасатка, фасаты, фасатына, фасатлар**; *к.* **гибрид**.

**ФӘКЫЙРЬЧЕЛЕ́К** *и. ялг. Вә начар тереклек вә **фәкыйрьчелек** адәмнәр хакы кушылган яхшы тереклек вә байлыктан олырактыр.* Кәлилә вә Димнә; *дөр.:* **фәкыйрьлек**; *к.* **каллиграфчы**.

**ФӘННИ-ҖИТЕШТЕРҮ́** *с. мәгъ. ялг. 1971 елның сентябреннән Казандагы В.И. Ленин исемендәге **фәнни-җитештерү** берләшмәсендә (элекке дары заводы) чыга торган күптиражлы «Ленинчы»*

*газетасында әүвәл хәбәрче, аннары 1974–1990 елларда редактор вазифаларын башкара*. Татар әдипләре. *Хезмәт юлын Казан «Медфизприбор» **фәнни-җитештерү** предприятиесендә инженер-конструктор булып башлый.* Балтач энциклопедиясе; *дөр.:* **фән һәм җитештерү**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ФӘННИ-МӘГАРИ́Ф** *с. мәгъ. ялг. Анда К. Насыйриның әдәби һәм **фәнни-мәгариф** эшчәнлеге турында кыскача сөйләнелә, шул исәптән галимнең татар фольклорын җыюга керткән өлеше турында да искәртелә.* Г. Рәхим; *дөр.:* **фән һәм мәгариф ...-ы/-е, фән һәм мәгарифкә кагылышлы, фән һәм мәгариф өлкәсендәге**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ФӘННИ-МӨХӘРРИРЛЕ́К** *и. ялг. Болардан тыш Ф. Яхинның борынгы төрки-татар әдәбияты ядкәрләрен текстологик яктан басмага әзерләү юнәлешендә алып барган нәтиҗәле **фәнни-мөхәррирлек** эшчәнлеген дә аерым әйтеп үтәргә кирәк.* Татар әдипләре; *дөр.:* **фәнни мөхәррирлек, фән һәм мөхәррирлек ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ФӘННИ-НӘШРИЯ́Т** *и. ялг. Галимнәрнең хезмәтләрен басмага әзерләү һәм аларны нәшер итүне тизләтү өчен, дирекция институтның үз **фәнни-нәшрият** бүлеген һәм «Фикер» нәшриятын булдырды.* Татар әдипләре; *дөр.:* **фәнни нәшрият ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ФӘННИ-ОЕШТЫРУ́** *с. мәгъ.ялг. Г. Ибраһимов исемендәге Тел, әдәбият һәм тарих институтының әдәбият секторы җитәкчесе буларак, Н. Юзиев татар әдәбиятының тарихын язу, әдәби мирасны барлау һәм матбугатка бастырып чыгару буенча күп төрле **фәнни-оештыру** эшләре алып бара.* Татар әдипләре. *2002 елның көзеннән Татарстан Фәннәр академиясенең **фәнни-оештыру** бүлегендә әйдәп баручы белгеч.* Татар әдипләре; *дөр.:* **фәнни эшчәнлек һәм оештыру ...-ы/-е; фән һәм оештыру ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ФӘННИ-ТЕ́ХНИКА** *и. ялг. Ярминкә партнерлары: Россия Инновацияләренең регионнары ассоциациясе; «РОСНАНО» ААҖ; «Россия венчур компаниясе» ААҖ; **фәнни-техника** өлкәсендә кече оешмаларга ярдәм күрсәтү фонды --- һ.б.* ivf.tatarstan.ru; *дөр.:* **фән һәм техника; фән, техника ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ФӘННИ-ТИКШЕРЕНҮ́** *с. мәгъ. ялг. Шуңа күрә соңгы дистә ел эчендә аның иҗаты төрле дәрәҗәдәге **фәнни-тикшеренү***

*эшләренең объектына әверелде.* Ә. Мотыйгуллина. *Уңышлы дип табылган **фәнни-тикшеренү** эшләре район, республика күләмендә үткәрелә торган төрле бәйгеләргә җибәрелде.* Г. Гәрәева. *Мәктәп реформалары, БДИ, сәләтле балаларны олимпиадаларга, конкурсларга, **фәнни-тикшеренү** конференцияләренә хәзерләү буенча да фикерләрем бар.* Р. Зарипов; *дөр.:* **фәнни тикшеренү ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ФӘННИ-ФАНТА́СТИКА** *с. мәгъ. ялг. А. Расих **фәнни-фантастика**, маҗара жанрларында да уңышлы эшләвен дәвам иттерә.* Татар әдипләре; *дөр.:* **фәнни-фантастик, фәнни фантастика ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ФӘННИ-ХЕЗМӘТКӘ́Р** *и. ялг. 1990 еллардан башлап «Экология» фәнни-техник үзәгендә өлкән **фәнни-хезмәткәр** вазифасын башкарып, Ык елгасы бассейнында 17 экологик экспедицияләр оештыра.* Татар әдипләре; *дөр.:* **фәнни хезмәткәр**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ФӘННИ-ЭЗЛӘНҮ́** *с. мәгъ. ялг. Бу көннәрдә финалистлар командалары өчен Рус географик җәмгыятенең Алексей Леонов исемендәге су асты **фәнни-эзләнү** отряды тарафыннан мастер-класслар, интеллектуаль уеннар һәм мәшһүр россияле полярник Владимир Чуков белән очрашу оештырылачак.* Кайбыч таңнары; *дөр.:* **фәнни эзләнү ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ФЕВРА́ЛЬ** *и.* Февральгә, феврале, февраленә, февральләр; *ялг.:* **февральга, февралена, февральлар**. *Күргәзмә 15 **февральга** кадәр эшләячәк.* Казан утлары. *14 **февральны** барлык мәхәббәтне татып караган затлар бәйрәм итә.* Әлмәт таңнары; *к.* **апрель**.

**ФЕДЕРА́Л** *и.* Федерация үзәк хакимияте вәкиле; *ялг.:* **федерал хөкүмәт, федерал оешма**. ***Федерал** каналлар аны шартлаткыч ясауда гаебен таныды дисә дә, ул үзе моны кире какты.* «Азатлык радиосы» сайты. *Сер түгел, соңгы елларда татар теле, гомумән татарлык Мәскәүдәге **федерал** хөкүмәт тарафыннан көчле басым астында калды.* Мәдәни җомга. *Яңа **федерал** законга бәйләп, үз киләчәген бу предприятие ничегрәк күзаллый?* Туган як; *чаг.:* **федераль**; *к.* **вокаль**.

**ФЕДЕРА́ЛЬ** *с.* Федерация булып торган; федерациягә мөнәсәбәтле; *чаг.:* **федерал**; *к.* **вокаль**.

**ФЕОДА́Л** *и.* Феодализм чорында крепостной крестьян хезмәтен эксплуатацияләүче эре җир биләүче сыйныф һәм аның бер

вәкиле; *ялг.:* **феодал тәртип, феодал мөнәсәбәт**. *Мәскәү, нигездә, **феодал** тәртип белән яшәүче бу мөселман илендә марксизм урнаштырып моның, чыннан да, шулай булуына ышандырып булачак дип исәпли.* Н. Акмал. *Бату хан тарафыннан Харәземдә һәм Караханилар дәүләтләрендә, нигездә, кыймак кабиләләреннән оешкан татарларның җиңел генә буйсындырылуы, аларның череп таркалган **феодал** дәүләтләр мәнфәгатьләре белән яшәмәгәнлекләрен күрсәтә.* М. Әхмәтьянов. *Газиз фән дөньясына сыенган төрле кызылавызлар басымы астында Бакудан Кабарда-Балкар автономиясенә күчеп китәргә мәҗбүр була, бер ел чамасы анда эшли; шул кыска вакыт эчендә «Кабарда-Балкариядә **феодал** мөнәсәбәтләр тарихына материаллар» дигән хезмәтен язып өлгерә.* Әдипләребез; *чаг.:* **феодаль**; *к.* **вокаль**.

**ФЕОДА́ЛЬ** *с.* Феодализмга хас; *чаг.:* **феодал**; *к.* **вокаль**.

**ФЕХТОВА́НИЕ** *и.* Фехтованиегә, фехтованиесе, фехтованиесенә; *ялг.:* **фехтованиега, фехтованиесы, фехтованиесына**. *Башкортстандагы танылган татар спортчысы, тәҗрибәле рапирачы Реналь Ганиев Германиянең Бонн шәһәрендә рапирада **фехтованиеның** «А» классында уздырылган халыкара турнирда уңышлы чыгыш ясап, бронза медаль яулады.* Татар-информ; *к.* **звание**.

**ФЕХТОВА́НИЯ** *и. ялг. **Фехтования** буенча үсмерләр арасында Кореяда үткән дөнья чемпионатында безнекеләр алдынгы иде.* «Яңа гасыр» телерадиокомпаниясе сайты; *дөр.:* **фехтование**; *к.* **предприятия**.

**ФИКРИ́** *с. вар. Институтта укыган елларда Роза тышкы яктан гына түгел, рухи һәм **фикри** яктан да бик нык үзгәреп кайткан икән.* В. Нуруллин. --- *романнары әдип иҗат колачының **фикри** һәм сәнгати яктан һаман киңәя, тирәнәя баруы турында сөйлиләр.* М. Әмирханов; *дөр.:* **фикер ягыннан, фикер күзлегеннән, фикердәге**; *к.* **мәгълүмати**.

**ФИЛЕ́** *и.* Филега, филесы, филесына, филелар; *ялг.:* **филегә, филесе, филесенә, филеләр**. *Балык **филесе** калын кебек тоелса, рулетка начар төрелер дигән шик туса, аны нечкәрәк итеп бүлергә кирәк.* Intertat.ru. *Юылган алмаларны өстенә балык **филесе** (ите), дөге, 1 башлы суган, 1–2 каты итеп пешерелгән йомырка, 2 аш кашыгы атланмай яки маргарин, тоз, төелгән кара борыч, петрушка салабыз.* Ватаным Татарстан; *к.* **атташе**.

**ФОЙЕ́** *и.* Фойе, фойесы, фойесына, фойелар; *ялг.:* **фойе, фойесе, фойесенә, фойеләр**. *Кызыл тасма киселгәннән соң кешеләр **фойегә** үтте һәм кемнәрдер «аһ» итте, кемнәрдер сөбханалласын әйтте, бәгъзеләре телсез калып баш чайкады, әмма сокланмаган кеше калмады.* З. Мурсиев. *Ресторанда, отель **фойесендә** кунаклар тыз-быз килә, диварлар тышында өч миллионлы шәһәр кайный, тик алар мине бар дип тә белми.* Казан утлары. *Менә хәзер клубның иркен **фойесендә** күмәкләшеп физик күнекмәләр ясый башлаячакбыз.* Кызыл таң. *Совет утырышы башланыр алдыннан Рөстәм Миңнеханов район хакимияте **фойесе** һәм залда оештырылган күргәзмәне дә карады.* Зәй офыклары; *к.* **атташе**.

**ФО́РВАРД** *и.* Форвардка, форварды, форвардына, форвардлар; *ялг.:* **форвартка, форварты, форвартына, форвартлар**. *«Чистокровный английский» токымы булган Реприза белән Фор-Мен (чын ир-егет, дигәнне аңлата) **Форварт** (һөҗүм итүче) кушаматлы тай бүләк итеп калдырган иделәр*. Матбугат.ру; *к.* **гибрид**.

**ФО́ТА** *и. ялг.* **Фотага, фотасы, фотасына**. *Әлеге **фоталарны** почтасына җибәреп беренче сыйныф баласының иң яхшы фотосурәте бәйгесендә катнаша аласыз.* Биектау хәбәрләре. ***Фотаң** һаман миндә саклана.* Ф. Дәүләтбаев. ***Фотада** 2007 елгы Мәскәү Кремлендә алып барылган казу эшләре вакытында табылган туз язуы.* Татар, уян!; *дөр.:* **фото, фотога, фотосы, фотосына**.

**ФОТАППАРА́Т** *и. ялг. Фотограф көне уңаеннан Чирмешәннең туган як тарихы музеенда оештырылган чара кунакларына электкеге, уникаль **фотаппаратларны** тотып карарга да мөмкинлек бирделәр.* Безнең Чирмешән. *Шул ук көнне өнемдә дә шул кеше **фотаппарат** эзләп йөрде!* Авыл офыклары. *Татарстаннан 14 яшьлек фермер Илсур Мөнихов махсус бүләк – цифрлы **фотаппарат** алды*. Татар-информ; *дөр.:* **фотоаппарат**; *к.* **фото-альбом**.

**ФОТО-АЛЬБО́М** *и. ялг. Гомәр абыйның заводта узган еллары турында исә, **фото-альбомнарын** һәм төрле елларда бүләкләнгән Мактау грамоталарын карый-карый, өенә кергәч сөйләштек.* Яшел Үзән.

***Радио-, фото- мега-, поли-, авто-*** кебек алынма аффиксоидлар һәрвакыт кушылып языла; *дөр.:* **фотоальбом**.

**ФОТО-АППАРА́Т** *и. ялг. Су керә торган урында **фото-аппаратлар**, видеокамералар, кәрәзле телефоннар юк.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар; *дөр.:* **фотоаппарат**; *к.* **фото-альбом**.

**ФОТО-БӘЙГЕ́** *и. ялг. Төбәкара «Идел-хаҗ» хаҗ үзәге «Синең Мәккәгә илтүче юлың» исемле **фото-бәйге** игълан итә.* Казан мэриясенең рәсми порталы; *дөр.:* **фотобәйге**; *к.* **фото-альбом**.

**ФОТО-БЕЛЕШМӘ́** *и. ялг. Мондагы сыман, коридорларда бик зәвыклы, сыйфатлы, эчтәлекле күргәзмә плакатлар, **фото-белешмә** почмаклар тагын кемдә генә бардыр?* Безнең Чирмешән; *дөр.:* **фотобелешмә**; *к.* **фото-альбом**.

**ФОТО-ДОКУМЕ́НТ** *и. ялг. «Таң атканда» күргәзмәсендә революциядән соң татар хатын-кызлары хәрәкәте тормышы хакында, тарихи вакыйгалар **фото-документлар**, архив материаллары аша яктыртыла.* Казан утлары; *дөр.:* **фотодокумент**; *к.* **фото-альбом**.

**ФОТО-ЖУРНАЛИ́СТ** *и. ялг. Нәтиҗәдә, бай мәгълүматлы, студентларга **фото-журналист** белгечлеген алырга ярдәм булган «Заманча журналистика нигезләре» басмасы дөнья күрә.* Darelfөnүn; *дөр.:* **фотожурналист**; *к.* **фото-альбом**.

**ФОТО-ЗО́НА** *и. ялг. Музей ишегалдында Казан рестораторлары фудкорт әзерли, урамда кышкы уеннар оештырыла – кунаклар кар атып уйный, кар ныгытмасы төзи ала, **фото-зона** һәм чыршы базары да эшли.* Мәйдан; *дөр.:* **фотозона**; *к.* **фото-альбом**.

**ФОТО-ИСТӘЛЕ́К** *и. ялг. Герой-шагыйрь Муса Җәлилнең **фото-истәлекләрен** 30 елдан бирле саклаучы мемориаль альбом музейның иң кадерле экспонатларыннан санала.* Казан утлары; *дөр.:* **фотоистәлек**; *к.* **фото-альбом**.

**ФОТО-КА́РТОЧКА** *и. ялг. Миндә истәлек булып калган **фото-карточкалар** бар.* Безнең гәҗит. *Дустымның да авыр туфрагы җиңел булсын, хушыгыз, – дип **фото-карточканы** Мөсәбихага тоттырды.* Өмет; *дөр.:* **фотокарточка**; *к.* **фото-альбом**.

**ФОТО-КО́НКУРС** *и. ялг. «Сөю чишмәсе» сәхифәсе «Мин яратам» дигән темага **фото-конкурс** игълан итә.* Яңарыш. *Берничә атна элек газетабызның сайтында «Иң мәхәббәтле пар» дип аталган **фото-конкурс** игълан иткән идек.* Кайбыч таңнары; *дөр.:* **фотоконкурс**; *к.* **фото-альбом**.

**ФОТО-КРО́СС** *и. ялг. Командалар «визитка-презентация» һәм **«фото-кросс»** тәкъдим итте, «экспресс-газета» чыгарды.* Идел таңнары; *дөр.:* **фотокросс**; *к.* **фото-альбом**.

**ФОТО-КҮРГӘЗМӘ́** *и. ялг. Ул татар йортлары архитектурасын өйрәнү буенча **фото-күргәзмә** әзерли.* Кәеф ничек? *Бирелә то-*

*варыңның* ***фото-күргәзмәсен*** *дә оештырырга була, реклама тарату да кыен түгел*. Darelfønyn; *дөр.:* **фотокүргәзмә**; *к.* **фото-альбом**.

**ФОТО-КҮЧЕРМӘ́** *и. ялг. Директоры Гөлшат Хафизовна Кисамбаева, фонд мөдире Александра Ивановна Солодимова һәм музей коллективы мине бередәге материаллар белән таныштырдылар, Тукай тарихына бәйле булган рәсемнәрнең* ***фото-күчермәләрен*** *бирделәр.* Габдулла Тукайга багышланган интернет-портал; *дөр.:* **фотокүчермә**; *к.* **фото-альбом**.

**ФОТО-ПОЗИ́ЦИЯ** *и. ялг. Монда матбугат конференцияләре, трибуналарда эш урыннары, микс-зоналар,* ***фото-позицияләр****, массакүләм матбугат чаралары вәкилләре өчен ял итү урыннары, интервью өчен бүлмәләр каралган.* 2013 Универсиадасы блогы; *дөр.:* **фотопозиция**; *к.* **фото-альбом**.

**ФОТО-ПОРТРЕ́Т** *и. ялг. Стендта Хәйдәр Бегичев, Роза Хәбибуллина, Зәйнәп Шәрифуллина, Халидә Бегичевалар* ***фото-портретлары*** *куелган*. М. Миначев. *Аның затлы биографиясе, ил алдындагы хезмәтләре, фән, сәнгать, әдәбият дөньясындагы казанышлары мактальп зур гына мәкалә һәм чибәр кешегә бик тартым итеп эшләнелгән* ***фото-портреты*** *да куелган иде.* Татар электрон китапханәсе; *дөр.:* **фотопортрет**; *к.* **фото-альбом**.

**ФОТО-РӘСЕ́М** *и. ялг. Аңа сүз бирелгәч, ул, гадәттәгечә, чараның әһәмиятен билгеләп, оештыручыларга рәхмәт белдерде һәм Ә. Патршинаның җырлар җыентыгы китабын сыйфатлырак итеп, тулыландырып,* ***фото-рәсемнәр*** *өстәп, зуррак шрифт белән кабат бастырырга --- дигән тәкъдимнәр кертте.* Яңарыш. *Килгән кунакларны җиде буынлык шәҗәрә һәм* ***фото-рәсемнәр*** *белән республиканың атказанган төзүчесе Хаҗинур белән Фирдәвес Шәйдуллиннар таныштырды*. Кызыл таң; *дөр.:* **фоторәсем**; *к.* **фото-альбом**.

**ФОТО-РЕЛЕ́** *и. ялг. – 70 ваттлы бу лампочкалар барысы да* ***фото-реле*** *режимында эшли, ягъни үзләре сүнә, үзләре кабына, – ди Яңа Кади авыл җирлеге башлыгы Мингәрәй Әминов.* Безнең Чирмешән; *дөр.:* **фотореле**; *к.* **фото-альбом**.

**ФОТО-РЕПОРТА́Ж** *и. ялг. Бүген узган елның театраль Сабан туеннан* ***фото-репортаж*** *тәкъдим итәбез*. karievteatr.ru; *дөр.:* **фоторепортаж**; *к.* **фото-альбом**.

**ФОТО-СӘЯХӘ́Т** *и. ялг. «Мәгариф» һәм «Гаилә һәм мәктәп» журналлары редакциясе «Татмедиа» акционерлык җәмгыяте*

*белән берлектә «Мәгариф: заман буйлап **фото-сәяхәт**» дип аталган фотосурәтләр конкурсы игълан итә*. Мәгариф. *Бу мәктәп укучылары өчен бик кызыклы **фото-сәяхәт**, – ди музей җитәкчесе.* Intertat.ru; *дөр.:* **фотосәяхәт**; *к.* **фото-альбом**.

**ФОТО-СÉРИЯ** *и. ялг. Никола Куперус (Nicola Kuperus) чыгарган кызык **фото-серия**, күбесенчә, хатын-кызлар аякларына багышланган*. Күрше; *дөр.:* **фотосерия, фоторәсемнәр сериясе**; *к.* **фото-альбом**.

**ФОТО-СÉССИЯ** *и. ялг. Һәммәсе **фото-сессиягә** әзерләнеп килгән кебек тоелды*. Өмет. *Кичә вакытында оештырылган **фото-сессия** Яшел Үзән тамашачылары өчен тагын бер күңелле яңалык булды.* Татар-информ; *дөр.:* **фотосессия**; *к.* **фото-альбом**.

**ФОТО-СУРӘ́Т** *и. ялг. Аларның истәлекле бүләкләрен, алар белән төшкән **фото-сурәтләрне** без кадерләп саклырбыз, аларның теләкләрен үтәрбез, якташ язучыларыбыз белән без һәрвакыт горурланырбыз*. Идел таңнары. *Юлбашчының барельефы урнаштырылган, районның зур казанышлары белән данлы кешеләренең **фото-сурәтләре** урын алган.* Туган як; *дөр.:* **фотосурәт**; *к.* **фото-альбом**.

**ФОТО-ХӘБӘРЧÉ** *и. ялг. Ул монда башта **фото-хәбәрче** буларак эшләгән, ләкин соңыннан монда калырга карар кыла һәм үзенең сәяхәт ширкәтен ачып җибәрә*. «Азатлык радиосы» сайты; *дөр.:* **фотохәбәрче**; *к.* **фото-альбом**.

**ФОТО-ШЕДÉВР** *и. ялг. Иң гади фотоаппарат белән дә **фото-шедеврлар** төшерергә мөмкин.* Darelfønyn; *дөр.:* **фотошедевр**; *к.* **фото-альбом**.

**ФОТО-ШО́П** *и. ялг. **«Фото-шоп»** программасы белән бәлки төзәтеп булыр.* Ф. Яхин; *дөр.:* **фотошоп**; *к.* **фото-альбом**.

**ФРА́У** *и.* Фрауга, фрауы, фрауына; *ялг.:* **фравы, фравына**; *к.* **ноу-хау**.

**ФУНКЦИОНА́Л** *и.* Вектор киңлегендә билгеләнгән сан функциясе; функцияләрнең барлыгы; *ялг.:* **функционал мөмкинлекләр, функционал җиһаз**. *Турнирга барлык клиентлар төркемнәре, барлык **функционал** юнәлешләр дә җәлеп ителәчәк.* 2013 Универсиадасы блогы. *Мин үзем антиквар безделушкалар түгел, **функционал** предметлар алу яклы*. Матбугат.ру; *чаг.:* **функциональ**; *к.* **вокаль**.

**ФУНКЦИОНА́ЛЬ** *с.* Функциягә бәйләнешле, мөнәсәбәтле; функцияләре булган, файдалы, кирәкле; *чаг.:* **функционал**; *к.* **вокаль**.

**ХАҖИ́** *и.* Хаҗига, хаҗие, хаҗиена, хаҗилар; *ялг.:* **хаҗисе, хаҗисенә, хаҗиләр; хаҗисы, хаҗисына**. *Ул Коръән Истанбул **хаҗисы** Фулад бине Мөхәммәд-Салих тарафыннан 1105 ел һиҗридә (1693–1694 елларда) күчерелеп тәмамланган булган.* Батырша җитәкчелегендәге баш күтәрү һәм XVIII йөз татар җәмгыятендә иҗтимагый-мәдәни торыш (Фәнни-гамәли конференция материаллары). *Дөньяның төрле почмакларыннан **хаҗиләр** килә, гриппияртүчеләр дә күп була.* Хезмәт даны; *к.* **көрси**.

**ХАЙВАНИ́** *с. ялг. Кайберләрегезнең икешәр гаиләсе, кайберләрегез **хайвани** тормыш белән яши.* А. Нәҗми. *Әлеге **хайвани** авaздан иләсләнеп киттем.* З. Мәхмүди. *Ихлас күңелдән сөя белмәгән, мәхәббәтнең нәрсә икәнен аңламаган бәндә хатын-кызга бары тик **хайвани** инстинкт белән карый икән, аны инде алтынга манып алсаң да чын кеше булалмый.* З. Мурсиев; *дөр.:* **хайван ...-ы/-е, хайваннарча, хайваннарга хас, хайваннарныкы кебек**; *к.* **мәгълүмати**.

**ХАЛЫ́ГАРА** *с. ялг. **Халыгара** белгечләр җыелмасы Вьетнамның көньягында кәлтәләрнең яңа төрен тапкан.* Күрше; *дөр.:* **халыкара**.

**ХАЛЫ́К** *и. ялг.:* **халыгы**. *Ханлык 118 ел яши, башка йөзләр белән катнашмыйча үз эчендә үзе, булган **халыгы** белән катнашып, үткән 118 ел эчендә 25 мең кешедән 1916 елны 250 меңгә җитә ---.* В. Ильясов. *Кытай шуның белән миллиардлаган **халыгын** туйдыра, ә бездә-демографик кризис.* Татарстан яшьләре; *дөр.:* **халкы**; *к.* **милек**; *чаг.:* **зәвык**.

**ХӘРБИ-АВИА́ЦИЯ** *с. ялг. 1936 елда Совет армиясенә алына һәм 1940 елда Оренбургта **хәрби-авиация** училищесын тәмамлый.* Яңарыш; *дөр.:* **хәрби авиация ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ХӘРБИ-ДИҢГЕ́З** *с. ялг. Ә унөч яшьлек Миләүшә **хәрби-диңгез** флотында хезмәт иткән егетен көтмәгән дә, хәзер исә, исерек ир белән өч бала үстереп азаплана икән.* И. Сәйфуллин. *«**Хәрби-диңгез** училищелары да бар, укырга теләк кенә кирәк!» – дип белдерә хәрби комиссар.* Кызыл таң; *дөр.:* **хәрби диңгез ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ХӘРБИ-ИНЖЕНЕ́Р** *с. мәгъ. ялг. Хәзер ул премьер-министр кул куйган карар буенча инженер гаскәрләре маршалы А.И. Прошляков исемендәге Төмән югары **хәрби-инженер** команда училищесы.* Яңарыш; *дөр.:* **хәрби инженер ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ХӘРБИ-ИНЖЕНЕРЛЫ́К** *с. ялг. 1963 елда Калининград **хәрби-инженерлык** училищесын, 1972 һәм 1981 елларда Мәскәүдә ике хәрби академия тәмамлый.* Татар әдипләре; *дөр.:* **хәрби инженерлык ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ХӘРБИ-ЙӨ́К** *с. ялг. **Хәрби-йөк** пароходы дигәннәре шактый зур гына кораб булып чыкты.* В. Имамов; *дөр.:* **хәрби йөк ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ХӘРБИ-КЫ́Р** *с. ялг. Озакламый Самарага инде генерал-майор П. Мансуров кул астындагы **хәрби-кыр** командалары да килеп җитә*. В. Имамов. *Якташыбыз алты әсирдән торган төркем белән Украинаның Черкас өлкәсендәге Слободской районына **хәрби-кыр** ныгытмалары төзергә озатыла.* Татар әдипләре; *дөр.:* **хәрби кыр ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ХӘРБИ-ПЕХО́ТА** *с. ялг. Омск **хәрби-пехота** училищесын тәмамлаган*. Яңарыш. *1939 елда гаскәри хезмәткә алына һәм, Бөек Ватан сугышының беренче көннәрендә үк **хәрби-пехота** мәктәбенә җибәрелеп, 1941 елның ахырында аны тәмамлап чыга ---*. Татар әдипләре; *дөр.:* **хәрби пехота ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ХӘРБИ-СПО́РТ** *с. ялг. «Патриот» республика үзәге Татарстан Хәрби комиссариаты һәм Яшьләр эшләре спорт һәм туризм министрлыгы белән берлектә «Аҗаган 2013» **хәрби-спорт** уеннарын шул бурычны тормышка ашыру максатында оештыра.* Кайбыч таңнары; *дөр.:* **хәрби спорт ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ХӘРБИ-СТРАТЕ́ГИЯ** *с. ялг. «Криоцептрон»га киләсе айда **хәрби-стратегия** мәсьәләләре чишү йөкләнәсе бит.* А. Тимергалин; *дөр.:* **хәрби стратегия ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ХӘРБИ-ТАБИ́Б** *с. ялг. Россиянең үзәк **хәрби-табиблар** комиссиясе фаразларына караганда, 2010 елда илдә демографик хәлне исәпкә алып, армия сафларына яраклы булганнар 600–700 мең кешегә кыскарырга мөмкин.* Кәеф ничек?; *дөр.:* **хәрби табиб**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ХӘРБИ-ФЕОДА́Л** *с. ялг. Хан **хәрби-феодал** югары катламга буйсынуга әләгә*. Б. Хәмидуллин. *Шул ук вакытта ханның үзенең, аның угланнарының, бәкләр бәгенең, карачи бинең, әмирнең, янә дә **хәрби-феодал** башлыкларның сакчы гаскәре булмыйча калмаган.* Р. Фәхретдинов; *дөр.:* **хәрби-феодаль ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ХӘРБИ-ҺАВА́** *с. ялг. КК составына Коры җир Гаскәрләре, **Хәрби-һава** көчләре һәм Хәрби-Диңгез Флоты; аерым төрләрдән –*

*Космик, һава десанты гаскәрләре һәм РВСН (стратегик билгеләнү буенча ракета гаскәрләре); хәрби идарәнең үзәк органнары; Кораллы Көчләр Тылы керә.* Л. Закиров. *Ул Гагарин исемен йөрткән **хәрби-һава** академиясен, ә соңыннан финанс-икътисад институтының читтән торып уку факультетын тәмамлый.* Я. Шәфыйков; *дөр.:* **хәрби һава ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ХӘРБИ-ЭЗЛӘНЎ** *с. ялг. Музей экспозициясе нигезен ТР Милли музее, «Кар десанты» һәм «Ватан» **хәрби-эзләнү** оешмалары, «Хәтер» китабы редакциясе, Бөек Ватан сугышы ветераннарының республика оешмасы һәм сугышта катнашучыларның шәхси архивларындагы мемориаль әйберләр тәшкил итә.* Кәеф ничек?; *дөр.:* **хәрби эзләнү ...-ы/-е**; *к.* **либераль-икътисад**.

**ХӘЯТИ́** *с. Шул мизгелдә аның эчкә баткан күз төпләрендә --- адәм балалары күңеле төпкелендә ячеренеп ята торган кешелек-лелек гәүһәрләре, **хәяти** самимилек балкып киткәндәй тоелды.* С. Поварисов. *Ягъни бу намәләр кешене дөнья мәшәкатьләреннән, **хәяти** ләззәтләрдән ваз кичеп, бары тик Илаһка табынып яшәргә өнди.* Р. Батулла; *дөр.:* **хәят ...-ы/-е, хәяттагы, тормыш ...-ы/-е, тормышчан, тормыштагы**; *к.* **мәгълүмати**.

**ХЕЗМӘТИ́** *с. ялг. Моннан тыш, әле түрәләрнең **хезмәти** тотышының типовой кодексы да эшләнергә тиеш.* Кәеф ничек? *Сирәк-мирәк кенә **хезмәти** сәфәрләргә чыксалар да, аларның часте ябык була, хезмәттән азат вакытларда ялга чыгу кебек мөмкинлек әләкми.* Татар-информ. *– Минем **хезмәти** тормышым, – дип яза Халитов үзенең тәрҗемәи хәлендә, – 1928 елда Казанның М. Вахитов исемендәге сабын кайнату заводында кара эшче булып башланды...* Шәһри Казан; *дөр.:* **хезмәт ...-ы/-е, эш ...-ы/-е, хезмәттәге, хезмәткә караган, хезмәткә кагылышлы, эш буенча**; *к.* **мәгълүмати**.

**ХИ́ППИ** *и.* Хиппига, хиппие, хиппиена; *ялг.:* **хиппигә, хиппиенә**. *Кояшта янган, чәчләре тузган, – **хиппинең** нәкъ үзе.* Казан утлары; *к.* **бигуди**.

**ХЛОРОФИ́ЛЛ** *и.* Хлорофиллга, хлорофиллы, хлорофиллына, хлорофиллар; *ялг.:* **хлорофилы, хлорофилына, хлорофилллар**. *Әллә аның **хлорофилы** шәмәхә-кызыл төстәме?* Х. Ширмән. *Гөмбәләрнең фотосинтез процессын тәэмин итүче пигменты – **хлорофилы** булмый, ягъни алар – гетеротрофлар.* Биология; *к.* **металл**.

**ХОДА́Й** *с. вар. Ләкин бик* ***ходаи*** *кеше иде, мескен*. Ш. Камал; *дөр.:* **Ходай ...-ы/-е**; *к.* **мәгълүмати**.

**ХОЛЫ́К** *и. ялг.:* **холыгы**. *Авыл егетләре дә күк күзле, җирән чәчле кызга күз ташлагаладылар, ләкин аларны Нүршәнең кире* ***холыгы*** *чигендерде*. Яңарыш. *Һәркемгә үз* ***холыгы*** *яхшы күренер*. Мәкаль; *дөр.:* **холкы**; *к.* **милек***; чаг.:* **зәвык**.

**ХЫЯЛЫ́Й** *с. ялг.:* **хыялыерак**. *Тагын да* ***хыялыерагы*** *сорауның колачын нык киңәйтте: – Юк, менә бөтен-бөтен-бөтен тараканнарның да тәпиләре хәтле елга җитәме АТТӘ?* Р. Бәдри; *дөр.:* **хыялыйрак**; *к.* **бай**.

**ҺӘ́Р-БАРЧА** *а. ялг. Ил-көннәребезгә иминлек,* ***һәр-барчабызга*** *җан тынычлыгы насыйп булсын!* Бөгелмә авазы; *дөр.:* **һәрбер** яки **барча**.

**ҺӘ́Р-БЕР** *а. ялг. – Мә сиңа, әнчек, мә тагы... – ди Хәйрүш* ***һәр-бер*** *сукканы саен*. Л.-Х. Таналин. *Ә хәзер, ни булса шул булыр, ындыр табагына кереп* ***һәр-берегез*** *берәр уч борчак алыгыз*. Татарстан яшьләре. *Авылда урта мәктәпне тәмамлагач* ***һәр-бер*** *авыл егете төсле ул да район үзәгендәге һөнәри белем бирү йортына укырга кереп тракторчы – машинист белгечлегенә өйрәнеп кайта*. Авыл офыклары.

Беренче компоненты ***һәр, һич*** һәм ***бер*** сүзләре, икенче компоненты сорау алмашлыклары булган кушма билгеләү һәм юклык алмашлыкларында компонентлар һәрвакыт кушылып языла; *дөр.:* **һәрбер**.

**ҺӘ́Р-ВАКЫТ** *а. ялг. Аның сүзен* ***һәр-вакыт*** *кем дә булса дөресли иде...* Р. Батулла. *Русия тарихын язган кайбер галимнәр дә адвокатларча эш йөртә: урысларның гамәлләрен* ***һәр-вакыт*** *дөрес, кануный, зарурый дип табып, мәңгелек кимлек кәсафәте саклаган татарларны вәхшигә, һәр мәсьәләдә хаксызга чыгарып куя*. Р. Зарипов; *дөр.:* **һәрвакыт**; *к.* **һәр-бер**.

**ҺӘ́Р-ДАИМ** *а. ялг. Ә иң олы максат, иң үрнәк тормыш ул – илгә, җиргә, җәмгыятькә* ***һәр-даим*** *кирәкле булу, кешеләрне сөендереп яшәү*. Туган як; *дөр.:* **һәрдаим**; *к.* **һәр-бер**.

**ҺӘ́Р-КАЙДА** *а. ялг. Фәнзаман абый,* ***һәр-кайда*** *синең карашыңны эзлим, таба гына алмыйм*. Туган як; *дөр.:* **һәркайда**; *к.* **һәр-бер**.

**ҺӘ́Р-КАЙСЫ** *а. ялг. Ул сыйфатларның* ***һәр-кайсын*** *бар халыкта да табарга мөмкин.* Т. Әйди. *Батырларның* ***һәр-кайсы*** *югары бәягә лаек иде.* Матбугат.ру; *дөр.:* **һәркайсы**; *к.* **һәр-бер**.

**ҺӘ́Р-КАЙЧАН** *а. ялг. Миңнегали Фәйзи улы һәрвакытта да һәм **һәр-кайчан** да тормышны, Туган илне һәм кешеләрне ярата, хөрмәт итә торган намуслы, әдәпле кеше булган һәм шулай булып кала да.* Биектау хәбәрләре; *дөр.:* **һәркайчан**; *к.* **һәр-бер**.

**ҺӘ́Р-КЕМ** *а. ялг. Бу фикер рус кешесе тарафыннан әйтелә: «**һәр-кемгә** үз динендә торырга кирәк».* Ф. Ислаев. *Билгеле, анысы **һәр-кемнең** шәхси эше.* Татарстан яшьләре; *дөр.:* **һәркем**; *к.* **һәр-бер**.

**ҺӘ́Р-НӘРСӘ** *а. ялг. Галәм гадәттә бар булган **һәр-нәрсәне**: матдә һәм энергия, планеталар, йолдызлар, галактикалар һәм галактикаара бушлыкны үз эченә ала.* Кызыл таң. *Аю, билгеле инде, эшнең төбен-асылын уйламый, **һәр-нәрсәне** өстән генә күрә.* Әкият; *дөр.:* **һәрнәрсә**; *к.* **һәр-бер**.

**ҺӘ́Р-ТӨРЛЕ** *а. ялг. Элек биредә начар күрүчеләр генә шөгыльләнсә, хәзер **һәр-төрле** инвалид балалар һәм өлкәннәр, коляскада гына хәрәкәт итүчеләр дә килә.* Кызыл таң; *дөр.:* **һәртөрле**; *к.* **һәр-бер**.

**ҺӘ́Р-ХӘЛДӘ** *а. ялг. Бу дуслык нәрсәдән башлангандыр, әйтүе кыен, **һәр-хәлдә** күңел уртаклыгы, хисләр сафлыгы, яшьлек юлларының янәшәлеге аларны бер-берсенә якынайткан булырга тиеш.* Татарстан яшьләре. ***Һәр-хәлдә** нәкъ Украинадагы һәм Кырымдагы хәл-вакыйгалардан соң алар безгә карата санкцияләр кабул итте.* Кызыл таң; *дөр.:* **һәрхәлдә**; *к.* **һәр-бер**.

**ҺӘ́Р-ЧАК** *а. ялг. Сабыр булыйк **һәр-чак** бер-беребезгә.* Р. Багаутдинов. *Сиңа карап сокланьсыннар, дошманнар көнләшсеннәр, **һәр-чак** шат күңелле бул, авырлыклар килгәндә мине искә ал.* Матбугат.ру; *дөр.:* **һәрчак**; *к.* **һәр-бер**.

**ҺИ́Ч-БЕР** *а. ялг. Дөреслектә, Мин – Аллаһ, Миннән башка **һич-бер** хак Илаһ юк, Миңа гыйбадәт кыл һәм Мине искә алу өчен намаз торгыз!* Туган як; *дөр.:* **һичбер**; *к.* **һәр-бер**.

**ҺИ́Ч-КАЙДА** *а. ялг. Парашют белән сикергәндәге кебек хискичерешләрне башка **һич-кайда** тоя алмыйсың.* Туган як; *дөр.:* **һичкайда**; *к.* **һәр-бер**.

**ҺИ́Ч-КАЙСЫ** *а. ялг. Укучыларның **һич-кайсы** җавап бирмәде.* Туган як; *дөр.:* **һичкайсы**; *к.* **һәр-бер**.

**ҺИ́Ч-КАЙЧАН** *а. ялг. «Һәр эшеңне, гамәлеңне, улым, бисмилла белән башла, начар гадәтләреңне бетер, рәнҗетелгәннәргә булыш, юк өчен дә көймә-янма, кеше өлешенә нәфсеңне сузма, **һич-кайчан** масайма».* Татарстан яшьләре; *дөр.:* **һичкайчан**; *к.* **һәр-бер**.

**ҺИ́Ч-КЕМ** *а. ялг. Әмма бу чикмән һәм җилән буй-буй нәрсәдән булмый, элгәре җиләнне, чикмәнне әдепле итеп тегәләр иде; инде бу елда әдепле җилән, әдепле чикмән **һич-кемдә** юк.* Гыйлем проекты. *Сынык ипи аңа **һич-кем** бирмәде.* Матбугат.ру; *дөр.:* **һичкем**; *к.* **һәр-бер**.

**ҺИ́Ч-НИ** *а. ялг. Хәзерге заман яшьләренә **һич-ни** кирәк түгел.* Туган як; *дөр.:* **һични**; *к.* **һәр-бер**.

**ҺИ́Ч-НИНДИ** *а. ялг. Бу юлысы эт **һич-нинди** каршылык күрсәтмәде.* Матбугат.ру; *дөр.:* **һичнинди**; *к.* **һәр-бер**.

**ҺИ́Ч-НИЧЕК** *а. ялг. **Һич-ничек** алдармын димә аны, булса да булыр икән шундый уяу.* Кызыл таң; *дөр.:* **һичничек**; *к.* **һәр-бер**.

**ЦЕ́МЕНТЛАШТЫРУ** *ф. ялг. Бу – чуен конструкцияләрнең калын булуы белән дә, чуен тутыкканда анда хасил булган металл нигезле феррит-перлит продуктларын графит кисәкчәләре **цементлаштыру** белән дә аңлатыла.* Төзү материаллары; *дөр.:* **цементлау**; *к.* **стимуллаштыру**.

**ЦУНА́МИ** *и.* Цунамига, цунамие, цунамиена; *ялг.:* **цунамигә, цунамиенә, цунамиләр**. *Шуңа күрә Тын Океанда **цунамиләр** дә күбрәк*. Википедия; *к.* **бигуди**.

**ЧА́ЛТ-АЯЗ** *с. ялг. Бүгенге көн кебек **чалт-аяз**, алар күңеле кебек чиста, саф.* Д. Каюмова; *дөр.:* **чалт аяз**; *к.* **чем-кара**.

**ЧА́ЛТ-ТИГЕЗ** *с. ялг. Аның бер ягы – **чалт-тигез**, ялтыравык көмеш белән йөгертелгән.* Ф. Яхин; *дөр.:* **чалт тигез**; *к.* **чем-кара**.

**ЧАРША́У** *и.* Чаршауга, чаршавы, чаршавына, чаршаулар; *ялг.:* **чаршауы, чаршауына**. *Исеңдәме, күктә йолдыз тулган, Төн **чаршауы** безне ураган.* Татар-информ; *к.* **билбау**.

**ЧАСТЬ** *и.* Частька, часте, частена, частьлар; *ялг.:* **частькә, частенә, частьләр**. *Эчке эшләр органнарына почта, телеграф, гомуми кулланудагы мәгълүмати системалар һ.б. юллар белән кергән хәбәрләр тиешле кагыйдәләр буенча теркәлә һәм кичекмәстән дежур **частькә** юллана.* Өлки хәбәрләре. *Әгәр элекке солдатлар начар шартлар, «бабайлык»тан зарланса, Виталий **частьне** ташлап китүен сәяси сәбәп белән аңлата.* Безнең гәҗит. *Февраль революциясе кызган көннәрне ул үзенең хезмәт иткән **частенә** әйләнеп кайта.* Гасырлар авазы; *к.* **повесть**.

**ЧӘНТИ́** *и.* Чәнтигә, чәнтие, чәнтиенә; *ялг.:* **чәнтисе, чәнтисенә**; *к.* **әби**.

**ЧЕБИ́** *и*. Чебигә, чебие, чебиенә; *ялг.:* **чебисе, чебисенә**; *к.* **гәләфи**.

**ЧЕ́М-АК** *с. ялг. Сездә дә нәкъ бездәге кебек икән аның* ***чем-ак*** *чәчәкләре!..* А. Гыйләҗев. ***Чем-ак****, кып-кызыл, фирүзәдәй зәңгәр килешә иде аңа.* М. Маликова; *дөр.:* **чем ак**; *к.* **чем-кара**.

**ЧЕ́МКАРА** *с. ялг. Аның матур,* ***чемкара*** *түгәрәк күзе ачык килеш ялтырап тора иде.* Ф. Садриев. ***Чемкара*** *күзләре курку белмичә, кыю карыйлар.* З. Зәйнуллин; *дөр.:* **чем кара**; *к.* **чем-кара**.

**ЧЕ́М-КАРА** *с. ялг.* ***Чем-кара*** *кашлы, ябык, ач яңаклы, ачык карашлы сөйкемле ир, милиция хезмәткәрләренә хас булганча, һәрчак пөхтә, матур итеп киенә, итекләре көзгә кебек ялтырап тора.* Д. Бүләков. *Аның каршында баягы* ***чем-кара*** *чәчле, кара күзле шәфкать туташы басып тора иде.* З. Мәхмүди. *Сөләйман, нур чәчеп торган* ***чем-кара*** *күзләрен Нуриягә төбәп, моңсу гына елмаеп куйды: – Я, бар, бурычыңны онытма.* Р. Габделхакова; *дөр.:* **чем кара**.

Асыл сыйфатлар белән килеп аларның артыклык дәрәҗәсен ясый торган ***җете, дөм, тома, шыр, шыгрым, чалт***, ***чем*** һ.б.ш. кисәкчәләр һәрвакыт аерым языла. Моның сәбәбе – аларның, башка кисәкчәләрдән аермалы буларак, мәгънәләре һәм функцияләре белән мөстәкыйль сүзләргә якынрак торуында. Аларның кулланылышы бер сүз белән генә чикләнмәскә дә мөмкин, мәсәлән, ***шыр тиле, шыр ялангач***. Хәтта башка сүз төркеме белән дә килә алалар: ***шыр ялган, шыр дала***. Ялгыш сызыкча аша язу очраклары исә кисәкчәләрнең башка төркеменә: асыл сыйфатларны бер иҗеккә кадәр кыскартып, аларга *п, м* тартыклары ялгап ясалган һәм шул сыйфатлар белән генә килә торган ***ап-, кып-, зәп-, кап-*** һ.б.ш. язылышына иярү нәтиҗәсендә барлыкка килә. Бу кисәкчәләр һәрвакыт сызыкча аша языла: ***ап-ак, зәп-зәңгәр*** һ.б.ш. Алар мәгънәләре һәм функцияләре белән кушымчаларга якын торалар. Һәр ике төргә караган кисәкчәләрнең сөйләм телендә шактый киң таралган фонетик вариантлары (мәс., *чөм кара, чым кара, япь-яшел* һ.б.ш.) язма тел өчен шулай ук стилистик хата булып тора.

**ЧЕРКИ́** *и*. Черкигә, черкие, черкиенә; *ялг.:* **черкисе, черкисенә**. *Аның һәр* ***черкисе*** *гүяки тургай, Әгәр төртсә, бар каныңны суыргай.* Мәҗлиси; *к.* **эби**.

**ЧИБӘ́Р** *с. ялг.:* **чибәрерәк**. *Егет аның былтыргыга караганда да* ***чибәрерәк****, мөлаемрәк икәнлеген күрде.* А. Нәҗми; *дөр.:* **чибәррәк**; *к.* **бай**.

**ЧИ́ПСЫ** *и.* Чипсыга, чипсые, чипсыена, чипсылар; *ялг.:* **чипс, чипсы, чипсына; чипсысы, чипсысына; чипса, чипсасы, чипсалар**. *Һәрхәлдә, кока-кола, фри бәрәңгесе,* ***чипслар****, майонез, конфет-прәннекләр бирмәссез дип уйлыйм*. Э. Фатыйхова. *Русия хөкүмәте «зыянлы» ашамлыклар арасына әлегә пальма мае, газлы су,* ***чипс*** *һәм электрон тәмәкене кертте.* Мәйдан. *Кибеткә, ипи алырга керү белән балагыз тәм-томнар, газлы су,* ***чипсалар*** *киштәләренә ташланып, сездән әйбер сатып алуыгызны таләп итәме?* Сәхнә; *к.* **шорты**.

**ЧОЛГА́У** *и*. Чолгауга, чолгавы, чолгавына, чолгаулар; *ялг.:* **чолгауы, чолгауына**. *Иң элек ул* ***чолгауын*** *чишеп казыкка элеп куйды*. Кызыл таң; *к.* **билбау**.

**ЧӨ́М-КАРА** *с. ялг. Нинди йомышыгыз төште? – дип каршылады, машинка артыннан калкынып,* ***чөм-кара*** *чәчле, зифа буйлы бер кызый.* Татар-информ; *дөр.:* **чем кара**; *к.* **чем-кара**.

**ЧЫ́М-КАРА** *с. ялг. Ишек янында ябык кына чырайлы, кыскартып киселгән кап-кара бөдрә чәчле,* ***чым-кара*** *күзле бер кыз бала басып тора иде.* Н. Яһудин; *дөр.:* **чем кара**; *к.* **чем-кара**.

**ШАНСОНЬЕ́** *и.* Шансоньега, шансоньесы, шансоньесына, шансоньелар; *ялг.:* **шансоньегә, шансоньесе**, **шансоньесенә, шансоньеләр**; *к.* **атташе**.

**ШАССИ́** *и*. Шассига, шассие, шассиена; *ялг.:* **шассигә, шассиенә; шассисы, шассисына**. *КАМАЗ* ***шассиендә*** *җыелучы «НефАЗ» автобусы эченә кереп үк карады, автомашиналарның газда эшләү мөмкинлеге белән бик нык кызыксынды.* «Азатлык радиосы» сайты. *Рәсми мәгълүматларга караганда, очкычның* ***шассисына*** *зыян килгән.* «Азатлык радиосы» сайты. *Гыйнвар аенда КАМАЗның төп конвейеры җитештерүнең көнлек темпыннан чыкмады – 180 йөк автомашинасы яки* ***шассисын*** *чыгарып торды, бу темп февраль аенда да сакланачак.* Intertat.ru; *к.* **бигуди**.

**ША́У** *и*. Шауга, шавы, шавына, шаулар; *ялг.:* **шауы, шауына**. *Тәгәрмәчләр тыкылдавы, машиналар* ***шауы*** *Рөстәмнең тавышын басып китә иде.* М. Кәбиров. *«Мега» комплексында үткән алу-сату* ***шауына*** *иптәш кыз белән без дә эләктек*. Татарстан яшьләре. *--- татар-мөселманнар өчен ислам дине талбишегe саналган Болгарда куеласы һәйкәл – сын мәсьәләсе* ***шауы*** *тынырга җыенмый*. Татар-информ; *к.* **билбау**.

**ШАЯРТУЧЫЛЫ́К** *и. ялг., дөр.:* **шаярту, шаянлык**; *к.* **каллиграфчы**.

**ШӘМӘХӘ́-КЫЗГЫЛТ** *с. ялг. Ерак офыкта,* ***шәмәхә-кызгылт*** *төскә кереп, кояш бата.* Р. Баттал; *дөр.:* **кызгылт шәмәхә**; *к.* **ачык-кызыл**.

**ШӘФКАТЬЧЕЛЕ́К** *и. ялг. Әдәбият, сәнгать, мәдәният эшлеклеләренең дә* ***шәфкатьчелеге****, нигездә, сүздә генә кала.* robertminnullin.ru; *Аларның* ***шәфкатьчелеге*** *сүздә генә бит.* Кызыл таң; *дөр.:* **шәфкать, шәфкатьлелек**; *к.* **каллиграфчы**.

**ШИМПАНЗЕ́** *и.* Шимпанзега, шимпанзесы, шимпанзесына, шимпанзелар; *ялг.:* **шимпанзегә, шимпанзесе, шимпанзесенә, шимпанзеләр**; *к.* **атташе**.

**ШИНЕ́ЛЬ** *и.* Шинельгә, шинеле, шинеленә, шинельләр; *ялг.:* **шинельга, шинелена, шинельлар**. *Газиз* ***шинельны*** *кайсы яктан төймәләсен, винтовканы яки автоматны пирамидага ничек куясын, иртәнге «подъем» командасында ятагыңнан сикереп төшкәч иң башта нәрсә киясен яхшы белә.* Әдипләр; *к.* **апрель**.

**ШОКОЛА́Д** *и.* Шоколадка, шоколады, шоколадына, шоколадлар; *ялг.:* **шоколатка, шоколаты, шоколатына, шоколатлар**. *Абрикосовлар гаиләсе йорты Бабаевский* ***шоколаты*** *ярдәме белән истә калачак.* Күрше; *к.* **гибрид**.

**ШО́РТЫ** *и.* Шортыга, шортые, шортыена, шортылар; *ялг.:* **шорт, шорты, шортысы, шортысына, шортлар; шорта, шортасы, шорталар; шортый, шортыйсы, шортыйлар**. *Зур шәһәрләрдә дә, авылларда да ике бармак арасына кыстырылган баулы башмаклар һәм кыска ыштаннар (****шортлар****) кию гадәти хәлгә әйләнде.* Ислам – татарлар һәм мөселманнар. *Кием формасы – футболка һәм* ***шортлар***. Сарман. *Башында гәзит эшләпә, өстендә җиңсез күлмәк һәм* ***шорт****, яланаягында сандал.* М. Яһудин. *Алар янына* ***шорта****, модалы футболка кигән кара күзлекле яшь ир керә.* А. Гадел. *Дискотекадагы сыман,* ***шорта****-майкалы яшьләр дә күп.* Кәеф ничек? *Футболка – 1500 сум, каеш – 1000, эчке кием (****шортый****) – 500 сум.* «Азатлык радиосы» сайты.

Чыганак телдә күплек санда гына кулланган һәм шуның кушымчасы белән кергән алынма сүзләр татар телендә гади нигез итеп карала һәм төрләнгәндә татар кушымчалары алып төрләнә. Яңа алынмалар фонетик яктан үзләштерелми, сүз ахырында килгән сузык кыскармый, чыганак телнең сан кушымчасы да саклана.

**ШОССЕ́** *и.* Шоссега, шоссесы, шоссесына, шосселар; *ялг.:* **шоссегә, шоссесе, шоссесенә, шосселәр**. *Теләге булган һәр кеше видеофиксация үзәгенә килеп – ул Уфаның Индустриаль* ***шоссесендә*** *урнашкан – үзенең гаебен исбатлый торган дәлилләр белән таныша ала.* Өмет; *к.* **атташе**.

**ШО́У** *и.* Шоуга, шоуы, шоуына; *ялг.:* **шовы, шовына**. *Татьяна Морозова (Татьяна Василий кызы Морозова) – кино актеры, «Comedy Woman»* ***шовы*** *катнашучысы*. Википедия; *к.* **ноу-хау**.

**ШОУБИ́ЗНЕС** *и. ялг.* ***Шоубизнес*** *законнары шундый ки, үзләрен күрсәтү өчен нинди генә адымга бармыйлар.* Intertat.ru. ***Шоубизнес*** *дөньясында әле күптән түгел генә кайный башласа да, Түбән Кама районының Нариман авылы кызы инде тамашачының күңелен яуларга да өлгерде.* Шәһри Казан; *дөр.:* **шоу-бизнес**; *к.* **шоу-мен**.

**ШОУ-ВУ́МЕН** *и. ялг. Зәмирә Рәҗәпова – татар эстрадасындагы танылган алып баручы да, үзенчәлекле тавышлы җырчы да, режиссер да, сценарий язу остасы да, шагыйрә дә,* ***шоу-вумен*** *да, улына аның өчен җан атып торучы әни дә, иренә хәстәрлекле хатын да, әнисе өчен иң ныклы терәк-таяныч та*. Кызыл таң. *«TATAR RADIOSI» ди-джее һәм танылган* ***шоу-вумен*** *Гөлназ Сәфәрова кияүгә чыкты*. Матбугат.ру; *дөр.:* **шоувумен**; *к.* **шоу-мен**.

**ШОУ-МЕ́Н** *и. ялг. Казанлылар өчен әлеге бәйрәм* ***шоу-мен*** *Тимур Родригез, «Сомоцветы» ансамбле чыгышы һәм зур салют белән истә калачак*. Шәһри Казан. *«Рәвешләр» көлке театрының репетицияләрен дә шунда гына үткәрер идек, – ди танылган* ***шоу-мен****, юморист*. Сөембикә; *дөр.:* **шоумен**.

***Шоу***- сүзе кушма сүзләрнең беренче компоненты булып килгәндә, рус телендә ясалып шуннан алынганга яки рус теле үрнәгендә ясалганга күрә, шундагы шикелле сызык аша языла. Чыгарма булып торган ***шоумен, шоувумен, шоуман, шоумания*** сүзләре кушылып языла.

**ШӨЛДИ́** *и.* Шөлдигә, шөлдие, шөлдиенә, шөлдиләр; *ялг.:* **шөлдисе, шөлдисенә**; *к.* **әби**.

**ШПИОНЧЫЛЫ́К** *и. ялг. Ул еллардагы хулиганлык,* ***шпиончылык*** *турында китаплар да яздылар бит инде.* Сөембикә; *дөр.:* **шпионлык**; *к.* **каллиграфчы**.

**ШТА́ПЕЛЬ** *и.* Штапельгә, штапеле, штапеленә, штапельләр; *ялг.:* **штапельга, штапельны, штапелена, штапельлар**; *к.* **апрель**.

**ШТУКАТУРЧЫЛЫ́К** *и. ялг.* ***Штукатурчылык*** *эше булсынмы, малярлыкмы, берсеннән дә куркып тормадылар.* Матбугат.ру; *дөр.:* **штукатурлык**; *к.* **каллиграфчы**.

**ШЫГРЫ́М-ТУЛЫ** *с. ялг. Тамашачы мәсьәләсенә килгәндә, зал* ***шыгрым-тулы*** *иде.* Татар заманы. *Тамаша залы буп-буш, әмма Рәшидә Туйсина, әйтерсең дә,* ***шыгрым-тулы*** *зал алдында чыгыш ясый.* Кызыл таң; *дөр.:* **шыгрым тулы**; *к.* **чем-кара**.

**ШЫ́Р-АЧЫК** *с. ялг. Бәҗәнәкләр Тын дәрья эргәсенә барып җитүгә үк Саркел атлы каланы кулга төшергәннәр. Хәзер шул куна тактасы шикелле* ***шыр-ачык*** *далада да әллә каян бүрәнәләр илә ак таш табып, кирмән диварларын ныгыталар икән.* В. Имамов; *дөр.:* **шыр ачык**; *к.* **чем-кара**.

**ШЫ́Р-СӨЯК** *с. ялг. Әмма монысы инде бөтенләй әрсезлек иде, үлемгә ошамады, ахрысы, ул шундук көлүен сүндерде дә,* ***шыр-сөяк*** *чыраен ачу белән ыржайтып, Мусаның тезенә китереп типте.* Казан утлары; *дөр.:* **шыр сөяк**; *к.* **чем-кара**.

**ШЫ́Р-ТИЛЕ** *с. ялг. Туя белмәс ач күз,* ***шыр-тиле***. В. Хәйдәрова; *дөр.:* **шыр тиле**; *к.* **чем-кара**.

**ШЫ́Р-ТОМАНА** *с. ялг. Саналган гамәлләрнең «вак» милләтләрне эретеп бетерү, юкка чыгару һәм ахыр чиктә «гомумроссиянин» әвәләү, укмаштыру өчен кылынган мәкер икәнен хәзер инде* ***шыр-томана*** *гына аңламас та, дөм-сукырлар гына күрмәс.* Мәдәни җомга; *дөр.:* **шыр томана**; *к.* **чем-кара**.

**ШЫ́Р-ХӘЕРЧЕ** *с. ялг. Аннары... аннары, корыган агач кәүсәсе шикелле шыр-ялангач,* ***шыр-хәерче*** *бәндәне мәңге аерылмас кара күләгәсе эзәрлекләп йөргән сыман, аның сырхавы да бар бит.* В. Имамов; *дөр.:* **шыр хәерче**; *к.* **чем-кара**.

**ШЫ́Р-ШӘРӘ** *с. ялг. Бәхәссез, Чулпаным, бер генә дин дә* ***шыр-шәрә*** *урында тумаган, ләкин диннәр турында бәхәсләшүне мәгънәсез шөгыльгә саныйм мин.* М. Хәбибуллин. *Мәскәү, Казан һәм башка калаларны чик-чамасыз бүселдереп, болай да кешесез иксез-чиксез ил биләмәләрен нинди максаттан чыгып, кем өчен дип тагын да бушаталар,* ***шыр-шәрә*** *калдыралар икән?* Татарстан яшьләре; *дөр.:* **шыр шәрә**; *к.* **чем-кара**.

**ШЫ́Р-ЯЛАНГАЧ** *с. ялг. Кияү дигәнең Нияз кебек ярлы булса, кызы* ***шыр-ялангач*** *өйгә килен булып төшсә...* Д. Каюмова. *Бу кибет киштәләренең* ***шыр-ялангач*** *вакыты ---.* Татарстан яшьләре; *дөр.:* **шыр ялангач**; *к.* **чем-кара**.

**ШЫ́Р-ЯТИМ** *с. ялг. --- дала уртасында тырпаеп утырган йомрытау шикелле **шыр-ятим** калган малай-шалай, йорт-лапасы янган хәерчеләр, кыяфәтләренә күз ташларга да куркыныч гарип-горабалар.* В. Имамов; *дөр.:* **шыр ятим**; *к.* **чем-кара**.

**ЫРМА́У** *и.* Ырмауга, ырмавы, ырмавына, ырмаулар; *ялг.:* **ырмауы, ырмауына**; *к.* **билбау**.

**ЫСПА́Й** *с. ялг.:* **ыспаерак**. *Кала халкы **ыспаерак** инде, Матуррак торыш-килеше.* Г. Сафин; *дөр.:* **ыспайрак**; *к.* **бай**.

**ЫШАНУЧЫЛЫ́К** *и. ялг. Ул иҗадиятта интернационалчылык, коллективизм, өметлелек, батырлык, коллектив көченә **ышанучылык** тойгылары белән тирән сугарылуын алам.* М. Җәлил. *Безем һәр сүземезә **ышанучылыклары** безем өчен файдалы да ---.* Г. Ибраһимов; *дөр.:* **ышанучанлык**, **ышану, ышаныч, ышанганлык**; *к.* **каллиграфчы**.

**ЭКСПРЕСС-АНА́ЛИЗ** *и. ялг. **Экспресс-анализ** күрсәткәнчә, суда кислород кирәгенчә.* Матбугат.ру; *дөр.:* **экспресс анализ**; *к.* **саунд-трек**.

**ЭКСПРЕСС-АНАЛИЗА́ТОР** *и. ялг. --- яңа кабул итү-диагностика бүлегенә 2,5 миллион сумга югары класслы портатив ультратавыш сканеры, --- канга **экспресс-анализатор**, күчмә рентген аппараты һәм җитди авыруларны йөртү өчен каталка кайтартылды.* Кайбыч таңнары; *дөр.:* **экспресс анализатор**; *к.* **саунд-трек**.

**ЭКСПРЕСС-ВИКТОРИ́НА** *и. ялг. Шул сәбәпле «Казан 2013» Башкарма дирекциясенең мәгариф учреждениеләре һәм коммерцияле булмаган оешмалар белән эшләү департаменты вәкилләре укытучылар өчен «Универсиада дәресе» темасына лекция үткәрде, шулай ук студентлар уеннарына багышланган **экспресс-викторина** оештырды.* 2013 Универсиадасы блогы; *дөр.:* **экспресс викторина**; *к.* **саунд-трек**.

**ЭКСПРЕСС-ДИА́ГНОЗЛАУ** *и. ялг. Рәхимҗан Тимерханов күрү дәрәҗәсен **экспресс-диагнозлау** инновацион приборын күрсәтте.* Кызыл таң; *дөр.:* **экспресс диагностика**; *к.* **саунд-трек**.

**ЭКСПРЕСС-ДИАГНО́СТИКА** *и. ялг. Шушы бала тудыру йортында сабыйлар реанимациясе бүлеге, **экспресс-диагностика** лабораторияләре бар.* Яңарыш; *дөр.:* **экспресс диагностика**; *к.* **саунд-трек**.

**ЭКСПРЕСС-ҖИТКЕРҮ́** *и. ялг. Шулай ук Мәскәү белән Санкт-Петербург арасында йөкне **экспресс-җиткерү** хезмәтен*

*башкара.* 2013 Универсиадасы блогы; *дөр.:* **экспресс җиткерү**; *к.* **саунд-трек**.

**ЭКСПРЕСС-КУ́РС** *и. ялг. Бер-ике ай эчендә шундый катлаулы телне ничек өйрәнеп булсын ди, мондый* ***экспресс-курс*** *кемгә кирәк*? Саба таңнары. *Быел хәтта удмурт телен өйрәнү буенча* ***экспресс-курс*** *та оештырылган*. Кызыл таң; *дөр.:* **экспресс курс**; *к.* **саунд-трек**.

**ЭКСПРЕСС-ЛАБОРАТО́РИЯ** *и. ялг. 120 урынга тәгаенләнгән биш катлы бинада заманча җиһазландырылган кабул итү, вакытыннан алда туган балалар, йөкле хатын-кызлар, бала тудыру, дәвалау, УЗИ, неонаталь блок,* ***экспресс-лаборатория****, операция, гинекология һәм башка бүлекләр бар*. Кызыл таң; *дөр.:* **экспресс лаборатория**; *к.* **саунд-трек**.

**ЭКСПРЕСС-СЕ́ССИЯ** *и. ялг. Муниципаль районның үсеш стратегиясе программасының максаты, бурычы, этаплары һәм башка теркәгечләрен аңлатканнан соң,* ***экспресс-сессиядә*** *катнашучылар эшчәнлекнең төрле юнәлешләре буенча биш төркемгә бүленде*. Идел таңнары; *дөр.:* **экспресс сессия**; *к.* **саунд-трек**.

**ЭКСПРЕСС-ТЕ́СТ** *и. ялг. Әлеге план нигезендә мәктәпләрдә белем алучы 300 укучы һәм Кайбычтагы 135 нче һөнәр училищесыннан 78 курсант наркологик* ***экспресс-тест*** *узачак*. Кайбыч таңнары; *дөр.:* **экспресс тест**; *к.* **саунд-трек**.

**ЭКСПРЕСС-ТЕСТЛАШТЫРУ́** *и. ялг. Республикабызның «СПИД» үзәге белгечләре сүзләренчә,* ***экспресс-тестлаштыру*** *вакытында авыру очракларының ачыклануы еш күренеш түгел*. Мәйдан. *Һәм инде алар арасында кисәтүсез* ***экспресс-тестлаштыру*** *уздырачаклар*. Безнең Чирмешән; *дөр.:* **экспресс тестлау**; *к.* **саунд-трек**.

**ЭКСПРЕСС-ТҮЛӘ́Ү** *и. ялг. Аннан соң абонентның* ***экспресс-түләү*** *картасыннан үз номерына акча күчерә аламы-юкмы икәнлеген белешә, бер сәгать эчендә күрсәтелгән суммага теләсә-кайсы номиналдагы* ***экспресс-түләү*** *картасын әзерләргә кирәклеген һәм, җиңүченең персональ номерын теркәү һәм бирү өчен, тагын бер тапкыр шалтыратырга кирәклеген аңлата*. Сарман; *дөр.:* **экспресс түләү**; *к.* **саунд-трек**.

**ЭКСПРЕСС-ЫСУ́Л** *и. ялг. Травма очрагы булганда* ***экспресс-ысул****, әлбәттә, рентген*. Өмет; *дөр.:* **экспресс ысул**; *к.* **саунд-трек**.

**ЭМА́ЛЬ** *и.* Эмальгә, эмале, эмаленә, эмальләр; *ялг.:* **эмальга, эмалена, эмальлар**. *Бүген Казан ратушасында директоры Анна Романова журналистларга шәһәр мэрының көмеш, алтын, кыйммәтле ташлар һәм төсле* ***эмальдан*** *ясалган вазифа билгесе турында сөйләде.* Татар-информ. *Шулар уңаеннан Иран Ислам Республикасы Парламенты әгъзасы, табибә – хирург Шахла Миргалуйе җитәкчелегендәге делегация составында --- каллиграф (тәзхиб) һәм агачтан уеп әйбер ясау остасы Зөһрә Кавиани һәм* ***эмальга*** *рәсем төшерү остасы Нәргес Могани Казанга килгән иде.* Татар-информ; *к.* **апрель**.

**ЭПИЗО́Д** *и.* Эпизодка, эпизоды, эпизодына, эпизодлар; *ялг.:* **эпизотка, эпизоты, эпизотына, эпизотлар**; *к.* **гибрид**.

**ЭТЮ́Д** *и.* Этюдка, этюды, этюдына, этюдлар; *ялг.:* **этютка, этюты, этютына, этютлар**; *к.* **гибрид**.

**ЮМАРТЧЫЛЫ́К** *и. ялг.; дөр.:* **юмартлык**; *к.* **каллиграфчы**.

**ЮРА́У** *и.* Юраугa, юравы, юравына, юраулар; *ялг.:* **юрауы, юрауына**. *Әбисенең* ***юрауы*** *дөрес булып чыкмады*. Татар-информ; *к.* **билбау**.

**ЯБЫ́КОРЛЫКЛЫЛАР** *и. күпл. бот. ялг.* Югары төзелешле орлыклы үсемлекләрнең бер бүлеге, чәчәклеләр; *дөр.:* **ябыгорлыклылар**; *к.* **ишекалды**.

**ЯВУ́** *ф.* Ява, яуды; *ялг.:* **яуа, яуып**. *Яңгыр* ***яуып*** *үтсә, шәһәр урамнары үзләре дә кечкенә диңгезләргә әйләнә.* Татарстан яшьләре; *к.* **билбау**.

**ЯВЫ́З** *и. мәгъ.* Явызга, явызы, явызына, явызлар; *ялг.:* **яуызга, яуызы, яуызына**. *Тик җибәрмә яннарына бер* ***яуызны***. В. Ильясов; *к.* **билбау**.

**ЯВЫ́М** *и.* Явымга, явымы, явымына, явымнар; *ялг.:* **яуымга, яуымы, яуымына**. *Март башында республикада* ***яуым*** *күп булды.* Википедия; *к.* **билбау**.

**Я́КОРЬ** *и.* Якорьга, якоре, якорена, якорьлар; *ялг.:* **якорьгә, якоренә, якорьләр**. *Башта салны* ***якорьгә*** *куярга уйлаган идем, аннан соң, чуртым булсынмыни балыкка дип, яттым да йоклadым.* Н. Әхмәдиев; *к.* **лагерь**.

**ЯЛКА́У** *и. мәгъ.* Ялкауга, ялкавы, ялкавына, ялкаулар; *ялг.:* **ялкауы, ялкауына**. – *Нишләп ятасың, шәһәр* ***ялкауы****! – дигәч кенә көчкә сөйрәлеп юынырга чыгып киттем.* М. Кәбиров. *Ничек түзә диген мескен хатын Шигырь яза торган* ***ялкауын****?* Ф. Дәү-

ләтгәрәева. *Әйтик Достоевскийның «Җинаять һәм җәза»сындагы уңай образ – Раскольников фактта эш сөймәс хөрәсән* ***ялкауы*** *бит*. Рөстәм Зарипов блогы; *к.* **билбау**.

**ЯМА́У** *и.* Ямауга, ямавы, ямавына, ямаулар; *ялг.:* **ямауы, ямауына**. ***Ямауы*** *сүтелгән кием кигән кебек инде ул*. Г. Сафина; *к.* **билбау**.

**ЯНВА́РЬ** *и.* Январьга, январе, январенда, январьлар; *ялг.:* **январьгә, январендә, январьләр**. *25* ***январьгә*** *кадәр узачак беренче этапта фикерләр җыела, аннан соң иң күп тавыш җыйган биш көрәшче арасында тагын бер «көрәш» булачак*. Идел. *5* ***январьдә*** *башланып, 20 сендә төгәлләнәчәк узышларда быел 53 илдән 459 спортчы катнашырга җыена*. Шәһри Казан.

Рус теленнән һәм рус теле аркылы кергән алынма сүзләрнең **-рь** га беткәннәрен төрләндергәндә III зат тартым кушымчасының алгы рәт варианты кушыла. Ләкин аннан соң килгән кушымчаларда яки башка категорияләр белән төрләндергәндә, арткы рәт кушымчалары ялгана. **-ть, -шь, -сь, -зь, -чь** ларга беткән сүзләр дә шул ук закончалыкка буйсына.

Ай атамалары исә татар теленә күптәннән кергәнгә күрә, алар фонетик яктан күбрәк үзләштерелгән, шуңа күрә **-рь** га тәмамланган ай атамаларының күпчелегенә III зат тартым кушымчасының гына түгел, аннан соң килгән кушымчаларның да алгы рәт варианты ялгана. **Январь** сүзе генә традиция буенча арткы рәт кушымчаларын саклый һәм чыгарма булып тора; *чаг.* **лагерь, повесть**.

**Я́РЫМАТАУ** *и.* Ярыматауга, ярыматавы, ярыматавына, ярыматаулар; *ялг.:* **ярыматауы, ярыматауына**; *к.* **билбау**.

**Я́РЫМУТРАУ** *и.* Ярымутрауга, ярымутравы, ярымутравына, ярымутраулар; *ялг.:* **ярымутрауы, ярымутрауына**; *к.* **билбау**.

**Я́У** *и.* Яуга, явы, явына, яулар; *ялг.:* **яуы, яуына**. --- *дошман* ***яуы*** *ерак, ә хан әле шәһәрдән бик ерак китеп өлгермәгәндер, Йылу, хан гаскәрен җитәр дә, ханга бар булган хәлне сөйләр.* В. Ильясов; *к.* **билбау**.

**ЯФРА́КАШАРЛАР** *и. күпл. зоол. ялг.* Катыканатлы бөҗәкләрнең иң зур семьялыкларыннан берсе; *дөр.:* **яфрагашарлар**; *к.* **ишекалды**.

**ЯШЬ** *с. ялг.:* **яшерәк**. *Мин яшәдем бу дөньяда озак: Бер – картырак булып үземнән, Бер –* ***яшерәк*** *булып үземнән...* Л. Шагыйрьҗан; *дөр.:* **яшьрәк**; *к.* **бай**.

**ЯШЬКЕ́ЛТ-ЗӘҢГӘР** *с. ялг. Мин монда чишмәдән нәкъ сиңа охшаган сары чәчле,* ***яшькелт-зәңгәр*** *күзле бер кечкенә генә малай алып кайткан идем, Өлфәт.* В. Нуруллин; *дөр.:* **яшькелт зәңгәр**; *к.* **ачык-кызыл**.

**ЯШЬКЕ́ЛТ-КАРА** *с. ялг. Бу хатын җирән чәчен сыерчык канатыдай ялтырап торган* ***яшькелт-карага*** *буяп йөргәнгәме, аны кобра дип йөртәләр иде ---.* Н. Көбәш; *дөр.:* **яшькелт кара**; *к.* **ачык-кызыл**.

**ЯШЬКЕ́ЛТ-КОҢГЫРТ** *с. ялг. Мөслим – буйга сөлектәй, ак йөзле, ялбыр чәчле, сер бөркелгән* ***яшькелт-коңгырт*** *күзле чибәр егет.* З. Мурсиев; *дөр.:* **яшькелт коңгырт**; *к.* **ачык-кызыл**.

**ЯШЬКЕ́ЛТ-КӨРӘН** *с. ялг. Хатынның* ***яшькелт-көрән*** *күлмәгенә өрәңге яфрагы килеп кунган иде.* К. Булатова; *дөр.:* **яшькелт көрән**; *к.* **ачык-кызыл**.

**ЯШЬКЕ́ЛТ-КЫЗЫЛ** *с. ялг. Манарасы кыек, бакыр ае сазлык эченнән сөйрәп алган сыман* ***яшькелт-кызыл***. В. Имамов; *дөр.:* **яшькелт кызыл**; *к.* **ачык-кызыл**.

**ЯШЬКЕ́ЛТ-САРЫ** *с. ялг. Әмма ул бик ерак китә алмады, урам чирәмендә үлән чемчеп йөргән* ***яшькелт-сары*** *каз бәбкәләре тезелешеп аның артыннан иярделәр.* Г. Гыйльманов; *дөр.:* **яшькелт сары**; *к.* **ачык-кызыл**.

**ЯШЬКЕ́ЛТ-СОРЫ** *с. ялг. Чөнки аның күзләре дә юбкасы белән пардан –* ***яшькелт-соры****, һәм алардан эчке моң белән өртелгән рәхимле нур бөркелеп тора иде.* В. Нуруллин; *дөр.:* **яшькелт соры**; *к.* **ачык-кызыл**.

**ЯШЬКЕ́ЛТ-ШӘМӘХӘ** *с. ялг. --- орлыклык бәрәңге утыртулар, җир астыннан борау кебек боргалана-боргалана* ***яшькелт-шәмәхә*** *үсентеләрнең борынлап чыгуын көтүләр, аннан аларны якты күздән үткәзеп, чүпләрен утап, ике, өч, теләсәләр, көчләреннән килсә, ун кат китмән белән эшкәртеп, йомшартып, төпләрен күмдереп чыгулар!..* А. Хәлим; *дөр.:* **яшькелт шәмәхә**; *к.* **ачык-кызыл**.

**ЯШЬТИ́** *и.* Яшьтигә, яшьтие, яшьтиенә; *ялг.:* **яшьтисе, яшьтисенә**; *к.* **әби**.

ЭЧТӘЛЕК


Кереш сүз . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 3

Сүзлекнең төзелеше турында . . . . . . . . . . . . . . . . . 7

Әдәбият исемлеге . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 10

Шартлы кыскартылмалар . . . . . . . . . . . . . . . . . . .11

Татар алфавиты . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 12

Сүзлек . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . . 13

Справочное издание

**Сабитова Ильгамия Исламутдиновна**
**Сафина Эльвира Ирфатовна**
**Тагирова Фяридя Инсановна**

**СЛОВАРЬ ТРУДНОСТЕЙ**
**ТАТАРСКОГО ЯЗЫКА**
(на татарском языке)

Корректор *А.А Давлетова*
Компьютерная верстка *Н.Т. Абдуллиной*

Подписано в печать 28.11.2019.
Формат 60×84$^{1}/_{16}$. Бумага офсетная. Гарнитура Times New Roman
Печать офсетная. Усл. печ. л. 10,7. Уч.-изд. л. 9,0. Тираж 1000 экз. Заказ

Оригинал-макет подготовлен
в Институте языка, литературы и искусства им. Г. Ибрагимова АН РТ
420111, Казань, ул. К. Маркса, 12

Издательство Академии наук Республики Татарстан
420111, Казань, ул. Баумана, 20